# САДЫЙКОВ Р.Х.

## Казан - 2014 ел

---

### МОҢ АГА

Челтери чишмә, челтери
Нидер әйтә ул, көйли;
Күп гасырлык эч серләрен –
Килгән кешегә сөйли.

Күп гасырлар элек монда
Егетләр, кызлар йөргән;
Аларның моңлы җырлары –
Чишмә хәтеренә сеңгән.

Челтери чишмә, челтери
Бушата эч серләрен,
Суын алган яшь кызларның
Елмаюлы йөзләрен.

Елмаеп карап торуын
Егетләрнең дә аңа,
Җырлыйлар һәм шат уйныйлар
Җиткәнгә кадәр таңга.

Һәр чишмәнең челтерәве
Җир ана кыңгыравы,
Монда кабат яшьләр йөри –
Булмасын соңгылары.

Челтери чишмә, челтери
Ул үзенчә моңлана,
Син төшен аның серенә
Тик, барырга соңлама!
Әкрен генә моң ага...

## МАЙНЫҢ БЕРЕСЕ

Бүген бит искечә майның да
Җитте чын дөресе – бересе,
Яхшыга ышанып, кешеләр –
Елмаеп йөриләр күбесе.

Көне дә бик матур – кояшлы
Чәчәктә шомыртлар – сиреннәр,
Алмагач чәчәктә утыра –
Сокланып пышылдый иреннәр.

Син дә күр, табигать бик матур
Сайрыйлар бит җирдә кошлар да,
Һава саф, чирәмнәр ямь-яшел
Килә гел йөрисе тышларда.

Кешеләр, без күрик һәм белик
Болар бит барысы да безнеке,
Таптамыйк, сындырмыйк – үстерик
Киләчәк буыннар – сезнеке!

## МАЙ УРТАСЫ

Бүген бит майның уртасы
Табигать тә яшәрде,
Урман-кырлар, су буйлары
Җибәрмиләр яшьләрне.

Бик матур, чиста табигать
Саф һава таратыгыз,
Табигатьнең бар кошын да
Саклагыз, яратыгыз!

Ялан-аяк уйнап-көлеп
Болыннарда йөрегез,
Табигатьнең – сәламәтлек
Икәнлеген белегез!

## ТУГАН ТЕЛЕҢНЕ ОНЫТМА!

Гимназиям, гимназиям
Авырлыкны җиңә – атлый,
Уңышлары бик күп аның
Алга бара, йоклап ятмый.

Ул ныгыта тамырларын
Үсеп чыга үсентеләр,
Гимназиябезне яклап –
Үз көчләрен күп керттеләр.

Үсентеләрнең дә хәзер
Ботаклары үсә – ныгый,
Динен, телен яратмаган –
Төшеп кала, шунда корый.

Син дә, дустым, ялгыш уйлап
Телең-динеңне корытма,
Дөнья күләм көчкә ия
Туган телеңне онытма!

## ЗУР ТОРМЫШКА БАСАРСЫЗ!

Бүген беренче имтихан
Язалар туган телдән,
Ачып салалар ак биткә –
Белемнәрен – бар белгән.

Ашыкмыйча, каушамыйча
Уйлап фикер йөртегез,
Ялгышкан дусларыгызны
Калдырмагыз – этегез!

Тырыш һәм уңган булсагыз

Булыр белемнәрегез,
Алда сезне көтеп торыр
Бәхетле көннәрегез!

Алган белемнәрегезгә
Сез нәтиҗә ясарсыз,
Аттестатны тотып кулга –
Зур тормышка басарсыз!

## БОЗАУ БУЛМАСКА!

Дөньялар текә-түгәрәк
Әйләнә дә әйләнә,
Эшне аңлый белмәгәннәр
Бәйләнә дә бәйләнә.

Кирәкми аларга ныклык
Ышаныч һәм дөреслек,
Күңелләрендә бары тик –
"Җимерергә" хиреслек.

Тырышып һәм намус белән
Эшләгәнгә карамый,
Үзгәртәләр ялтырауга
Дөреслекне барламый.

Алар аңларга теләми
Бу бит кыска ялтырау,
Яшеренгән артларына
Инде кылган калтырау.
Булмаска кирәк – бозау!

## СҮНМӘСЕН – СҮРЕЛМӘСЕН!

Дөнья да матур, түгәрәк
Изгелек тә җитәрлек,

Ходай биргән бу гомердә
Аны күбрәк күтәрик!

Башкаларга да өләшик
Бәлки аңлый башларлар,
Ялгыш булган бу эшләрен
Эшләмәсләр – ташларлар!

Күңелләренә дә, бәлки,
Әйләнеп кайтыр акыл,
Күпме яхшылык кылсак та
Башлары шул тап-такыр.

Ходайга бары ышаныч
Ходай ташлый күрмәсен,
Ата-бабадан калган көч –
Сүнмәсен – сүрелмәсен!

## ҺӘРЧАК ШУЛАЙ ЙӨРЕГЕЗ!

Изге барча теләкләр дә
Гөлназ белән Рафиска,
Дөньясы да хәзер матур
Көннәре бүген башка.

Гөлназ исеме яртысы
Ул – чәчәк атучы гөл,
“Наз” дигәне дә фарсыча –
“Иркәләү” ул – Рафис бел!

Рафис үзе дә гарәпчә
Этүче, тибәрүче,
Авырлыкка төшермичә –
Гел алга җибәрүче.

Исемегез – җисемегез
Туры килә – көлегез,
Әти-әни, дус-туганнар

Хөрмәтлиләр, белегез!
Һәрчак шулай йөрегез!

## ҺӘРВАКЫТ ТА ӘЗЕР!

Килеп җитте җәй дә
Бик ышанма мәйгә,
Эсседән сусасаң –
Бары таян чәйгә.

Чәең чәчелмәсен
Ал син аны төреп,
Кайнар чәйгә пешмә
Эч бары тик өреп!

Һәр йотымы аның
Тәнгә бирер зур көч,
Мәйгә бик ышанма
Тизрәк син чәйгә күч!

Аның күп төрләрен
Без беләбез хәзер,
Тәмле чәй эчәргә –
Һәрвакыт та әзер!

## БАЛАЧАК ШАУКЫМЫ

Балалар уйныйлар
Кычкырып урамда,
Куркытмый аларны
Бернәрсә грамм да.

Этләр дә күп өрә
Аларга кушылып,
Кемнәрдер сагына
Якынын юксынып.

Алар да кайчандыр

Уйнаган шаулашып,
Юк кына нәрсәне
Бүлгәннәр даулашып.

Бу матур гөрләшү
Балачак шаукымы,
Кычкырып уйнаулар –
Яшь йөрәк ялкыны.

## БИРЕШМИК КЫРАУЛАРГА

Бүген менә мәктәбеңдә
Соңгы звонок тавышы,
Һәр чың үзенчә яңгырый
Аларның бу ярышы.

Балачак белән хушлашу
Тормышка тәүге адым,
Моның өчен мәктәбеңдә
Тәрбия, белем алдың.

Барысын да син уңай куллан
Каушама сынауларда,
Алган белемеңә таян –
Куркытмас, сораулар да.
Бирешмик кырауларга.

## БӘХЕТЛӘР ТЕЛӘЧӘК

Гимназия күләмендә
Торабыз линейкада,
Күп укучы бүләкләнде
Шатлана моңа бар да.

Район, шәһәр, республика,
Рәсәй күләм уңышлар,

Мондый тырыш буын үскәч –
Җиңеләер тормышлар.

Ел күләм үткән чарага
Катнаштылар барысы да,
Алар җиңгән медаль, кубок
Күп дипломнар каршыда.

Гимназия дә котлады
Теләп якты киләчәк,
Аларның зур уңышларын –
Бар кеше дә беләчәк
Һәм бехетләр теләчәк!

## СОРАШ!

Мәктәпләрдә хәзер
Имтихан башлана,
Булган бар вакытны
Әрәмгә ташлама.

Тырыш, бел белемнең
Үткәнен барысын да,
Аңламый утырсаң –
Сораш син, тарсынма!

Алырсың аттестат
Бу урта белемгә,
Нык тамыр җәярсең
Алдагы көнеңә.

Намус һәм тырышлык
Гел сине әйдәсен,
Бәхетле булуның
Ачар ул хәйләсен.

## ЯКТЫ БУЛЫР ТӨНЕ ДӘ

Соңгы кыңгырау бәйрәме
Бер агачлыкта узды,
Зифа каенлык урманы
Шат авазлардан тулды.

Укытучылар куана
Җырлыйлар һәм бииләр,
Барысы да мәктәпләрен –
Туган йортка тиңлиләр.

Дөрестән дә мәктәп якын
Ул белемнең учагы,
Һәркем аны алып чыга –
Җиткән кадәр кочагы.

Алган белемне раслыйсы
Килеп җитә көне дә,
Яхшы билгеләр алсалар –
Якты булыр төне дә!

## КАЗАНСУ

Казансу – тарихка кергән
Башкаланың нигезе,
Кочагында яткан Казан
Шуңадыр да бик изге.

Ханлыкта да аның белән
Чит дәүләтләр эш иткән,
Казанның зур байлыгына
Дошманнар күзе төшкән.

Басып алырга дәүләтне
Кабат-кабат килгәннәр,
Күп явызлык һәм кан коеп
Ахырында җиңгәннәр.

Байлыкны дошман тапмаган
Эзләп бар җир кырылган,
Утыз чакрымга татарлар
Казан-тирә куылган.

Явыз Иван табалмаган
Казан ханы байлыгын,
Биш гасыр узып барса да
Белмиләр кайдалыгын.

Килер вакыт, халкым өчен
Ачылыр тарих сере,
Бабайлар да шуны көтә
Әйтерсең, алар тере.

Дөрес тарих, байлык кайтыр
Казаныма яңадан,
Үз телендә бар бала да
Кычкырып әйтер азан.
Бу ханлык – безнең Казан

## ЧИСТАРТ ЮЛЫҢНЫ

Казан елгасы – Казансу
Зур афәтләр күргән су,
Күп авырлыклар кичергән
Шуңа да булган борчу.

Хәзер зурая, чистара
Милли үзәк тирәсе,
Халкыбызны, телебезне
Килә чиста күрәсе!

Арынсын, чистарсын иде
Ялганнан һәм нахактан,
Казансу, чистарт юлыңны
Ага бир яңа баштан!

## СЕРЕҢНЕ АЧ

460 ел изелдек
Авырлыклар астында,
Даһилык һәм горурлыклар
Онытыла барысы да

Зур байлык, данга ирешкән
Бу ханлык – Казаныбыз,
Яңгырады бәхет белән
Һәрвакытта даныбыз.

И Казан, моңлы кала син
Халкымның башкаласы,
Мең елдан артык сереңне
Безгә дә ачкалачы!

## ЧӘЧӘКЛӘР ДӘРЬЯСЫ

Тормыш ул аткан чәчәктәй
Ачыла да ябыла,
Кояш нурлары балкыса –
Ул да елмаеп тора.

Сез дә гел шулай елмаеп
Бәхет белән яшәгез,
Без дә шулай, елмаешып –
Якын итеп дәшәбез.

Бу көннәр, айлар һәм еллар
Бары бәхет китерсен,
Булган барлык мәшәкатьне –
Җил яңгырлар бетерсен.

Җылы яңгыр һәм кояшның
Булыр бик күп файдасы,
Җир йөзен матурлар, бизәр –
Күп чәчәкләр дәрьясы.

## БЕРАЗ УЙЛАНЫЙК

Дөнья матур, эш тә күркәм
Ходайның бу фәрманы,
Тормыш авырлыгын җиңү –
Бу кешелек дәрманы.

Матур тормыш алымнары
Ул булсын безгә маяк,
Кем намуссыз юлдан бара –
Аңа – аркылы таяк.

Кайберәүләр шуны аңламый
Без бит искән таң җиле,
Һәркемгә дә якын булсын –
Үз теле һәм үз иле.

Җилнең дә була төрлесе –
Йомшагы һәм катысы,
Сүзнең дә була төрлесе –
Ачысы һәм татлысы.

Йомшак җилне, татлы сүзне
Тормышта без кулланыйк,
Намуслы кеше булырга –
Әйдә, бераз уйланыйк.
Әйдәгез, соңга калмыйк!

## ЧЫГАРЫЛЫШ КИЧӘСЕ

Менә бүген килеп җитте
Чыгарылыш кичәсе,
Зур тормышка аяк басып
Хәзер килә китәсе.

Нык басып алга барырга

Гимназия бирде көч,
Төпле белем алып чыктык
Онытмабыз аны, һич!

Монда алган ныклы белем
Тормышта безгә кирәк,
Һәр адым атлаган саен
Алар булырлар терәк.

Йомгаклап мин шуны әйтәм
Гимназиябез – изге,
Күп авырлыклар күрсә дә
Бирелмәде ул – түзде.

Зур уңышлар белән атлый
Артта бара көчләре,
Халыкны, телне баета
Аның изге эшләре.

## САУБУЛЛАШУ

Укучылар, бүген сезгә
Саубуллашып китәргә,
Алган белем, тәрбияне
Туры килә сүтәргә.

Бу белемнәргә таянып
Адашмыйча – батмыйча,
Ихтирам-хөрмәт яулагыз –
Бик күп йоклап ятмыйча.

## ХӘТЕР ЧИШМӘСЕ

Җыелды халык
Инде нишләсе,
Ачылды кабат

Хәтер чишмәсе.

Күпме хәтерне
Ул монда корган,
Сер һәм хисләрне
Тирәннән ерган.

Сулары да бит
Ургылып ага,
Куйган улактан
Ашкынып бара.

Күпме яшь парлар
Суларын эчкән,
Сөю ялкыны
Аша да күчкән.

“Хәтер” чишмәсен
Кадерләп саклыйк,
Тормыш юлыннан
Нык басып атлыйк!

## ШАРТ – БАР

Бүген атнаның да менә
Чәршәмбе көне җитте,
Тикшерү буенча ике
Комиссия килеп китте.

Алып килергә соңгысын
Туры килә барырга,
Машина яллап җибәрдек
Без аларны алырга.

Уку елын башлар өчен
Ремонтны күп башкардык,
Күп идәннәр алыштырып
Искеләрен ташладык.

Үзебезчә, бар да тәртип
Шарт бар ныклы белемгә,
Нык белемле, тәрбияле
Яшьләр бирик илемә!

## ЧИШМӘ

Хәтеремдә минем, бу чишмәдән
Ничек итеп сулар ташыган,
Язгы сулар юлны каплаганчы
Өлгерим дип, күңел ашкынган.

Чишмәләр күп туган авылымда
Саваплы, саф аның сулары,
Суын эчеп үскән ул – кызларын
Очраштыра аның юллары.

Саф сулары аның дәва бирә
Кешеләргә аны яраткан,
Челтерәп аккан көмеш бу чыңнары
Борчу-сагышларны тараткан.

Бу чишмәдә безнең яшьлек хәтер
Сабантуйлар да күп булдылар,
Болыннар да чишмә суын эчеп –
Күп чәчәкләр белән тулдылар.

Озак гасырлар әле челтерәп ак
Саулык, бәхет бирсен бу суың,
Сине эчеп киткән кешеләрнең –
Калдырмагыз бер дә борчуын!

## ЙӨЗ КЫЗАРМАСЫН

Тормыш адымы
Астан башлана,
Ул баскычларны –
Бер үк таптама.

Чиста булсын һәр
Баскан эзләрең,
Елмаеп торсын –
Һәрчак күзләрең.

Дөньяны ярат
Бар эшеңдә дә,
Рәхмәтең иңсен –
Бар кешегә дә.

Намус көзгесе
Тузанланмасын,
Кылган эшләрдән –
Йөз кызармасын.

## ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

Саулык ул – үзе бер байлык
Хәрәкәттә – бәрәкәт,
Аның сүзләре бик изге,
Аны аңлау бик рәхәт.

Бу әйтем белән мәкальләр
Тормышка ак юл ача,
Телне белмәгән кешеләр
“Сазлыкка кереп кача”.

Ул шуннан кычкырган була
“Телне беләбез!” – тәмам,
Үз телендә аның бер дә
“Тибрәткәне” юк каләм.

Аңа каян килсен бәхет
Тормыш саулыгы кая,
Кайсы якка җил нык иссә –
Ул шунда китеп “тая”.

Шуңа да, мондый адәмнәр
Телгә, илгә кирәкми;
Аларны барыр юлында
Бары “шайтан” җитәкли.

## ДУСЛАР БАР ИЧ

Туганнар күк дуслар булган
Бу инде ныклы ярлар,
Андый дуслар булган гаилә –
Шунда ук мине аңлар.

Дусларыбыз – безнең өчен
Рузалия һәм Борис,
Авырлыкларны җиңәргә –
Һәрвакыт дуслар бар ич!

## ГАРМУН СУЗАРМЫН

Аягымны карадылар
Ходай кушса, төзәлә.
Нык басып йөрисе булыр –
Авырлакны өзәргә.

Тормыш иптәшем тырышты
Җайлады да көйләде,
Дүшәмбе көнне алалар
Аяктагы җөйләрне.

Ходай кушса, элеккечә

Рәхәтләнеп эшләрмен,
Аннары гармун сузармын
Яңгыратып кичләрен.

## КИЛӘЧӘККӘ

Мин шатланам һәм куанам
Зәңгәр күкләрдә очам,
Зур уңышларга ирешкән –
Укучыларны кочам.

Ходай изге эшләр биреп
Кайтарса кабат җиргә,
Гел хезмәт итеп яшәрбез –
Халкыма, туган телгә!

Әле бар яулыйсы үрләр
Халкыма һәм телемә,
Ходай бирсә ныклы саулык –
Бу киләчәк көнемә.

## ГӨЛФИЯ

Исемегез туры килә
Фарсыча – гөлгә охшаш,
Изгелек, яхшылык кылу –
Тормышыгызда тоташ.

Иптәшегезнең дә бик нык
Фарсыча из исеме,
Ил гизүче, сәяхәтче –
Исеменең җисеме.

Ике бишле сезгә бүген
Бу тормышка куела,
Кайбер булган мәшәкатьләр –

Чиста судай юыла.

Чиста, матур ак юллардан
Атларга да атларга,
Бәхетле тормыш парларын
Калдырмыйча ятларга!

Саулыкны, якыннарыңны –
Бик кадерләп сакларга!

## СЕНТЯБРЬДӘ – СИН ДӘ БЕР, МИН ДӘ БЕР

Менә бүген искечә дә
Сентябрьның бересе,
Һәм бу айда син дә, мин дә
“Бер” дигәннәр, дөресе.

Шундый зур ышаныч белән
Без басабыз аякка,
Ходай сәламәтлек биреп –
Калдырмасын таякка!

Язның марты килгәндә дә
Аяклар нык атласын,
“Мартта кем кала артта?” – дигәннәр
Безгә насыйп булмасын!

Тишелеп чыккан үләннәр
Шаулап аккан гөрләвек,
Алып килсен бары бәхет
Аякларыма – саулык!

## АЧЫК БУЛСЫН КАПКАГЫЗ

Сулар чиста, ашамлык күп
Балык хуҗа бар җиргә,
Алар кебек кешеләр дә
Хәзер хуҗа бар илгә.

Ашамлыгы булса да күп
Чиста булса да суы,
Аңа туры кирәк икән –
Һәрвакыт йөзәр юлы.

Боргалана шул, елга да
Уңга-сулга ташлана,
Аларга да, бит, кайчакта
Агызалар ашлама

Мондый чакта балыкларның
Башы түнә – ул батыр,
Әйтерсең лә, йөзәр юлы
Һәрвакыт аның такыр.

Күп вакыт такыр юлда да
Очырый бит ташлары,
Аларга килеп бәрелгәч –
Бик авырта башлары.

Авырткан баш, хуҗасызлык
Булып яшәү бик авыр,
Көтмәгәндә йөзәр юлда
Каршылыклар да булыр.

Халык бик тә дөрес әйткән:
“Башны кирәк сакларга!”
Балык бит, баштан бозыла –
Моны белә бит, бар да.

Җитәкчеләр, сез дә шулай
Бу балыктай чапмагыз,
Башыгызны авырттырып

Ялгыш эшләп ятмагыз!

Чиста күңелле кешегә
Ачык булсын капкагыз,
Авырлыкны яшерергә –
Ак юрганнар япмагыз!

## ЗУР ЫШАНЫЧ

Менә сәгать унбер тулгач
Алдылар бик зур эшкә,
Ике сәгать вакыт узгач –
Китерделәр түшәккә.

Билгә кадәр аякларым
Тора – таш булган – сулган,
Әйтерсең, өшегән гөлдәй
Кышкы салкыннан туңган.

Хәзер менә туңган килеш
Җәрәхәтләр ачыла,
Кискән, тишкән авыртулар
Вакыт узгач, басыла.

Ышанычым алда олы
Зур эшләр башкарырга,
Халкым өчен, телем өчен
Утка да ташланырга
Һәм нык басып барырга!

## ӨМЕТ ЧАТКЫСЫ

Күздәрдә өмет чаткысы
Йөзләрдә шаян көлү,
Кирәк һәрчак кешеләрнең
Уй-хисен тоя белү.

Хәзер уйланып ятабыз
Тикшерү бүген бетә,
Иртән торгач бик җаваплы
Вакытлар безне көтә.

Аягым көтә котылып
Авыру – сызланудан,
Нык басып, матур эшләргә
Курыкмыйча, кар-боздан.

Ходай кушса, кире кайтыр
Саулыгым – бәхетем минем,
Без үстергән гөлләр белән
Ак чәчәк атар илем.

## УЙЛАП КЫЛ

Түгәрәк йөз, матур күзләр
Алар тора елмаеп,
Син үзең дә бик зирәк бул
Егыла күрмә һич таеп.

Бер тапкыр инде абынгач
Атла син карап кына,
Ашыкмый башкарган эшләр
Һәрвакыт ярап тора.

Кеше заты үзе шундый
Ялгышып та куйгалый,
Бик яхшы барган эшләрне
Кирегә дә боргалый.

Әй син кеше, аңыңа кил
Тоз салма керсез җанга,
Гомер ул бер генә килә
Уйлап кыл, шуны аңла!

Ашыкмый, сөеп башкарсаң
Һәр эшең булыр уңган,
Барыр юлың һәм гаиләң –
Бәхеттән генә тулган.

## БАСУЛАР ТУЛЫР

Яшь гомерләр уза бара
Кигән кием туза бара,
Игелек, яхшылык кылып –
Уңга кара, сулга кара!

Авырлаклар булса читтә
Төшеп тормас һәркөн искә,
Аларны син таратырсың
Матур тормышка басарсың.

Игеннәр үсәр кырларда
Яңгырар матур җырлар да,
Сандугачлар сайрап торыр
Басулар икмәккә тулыр.

Кешеләрнең йөзләре дә
Елмаеп торырлар көн дә,
Алар барысы булыр бик шат
Чиста, матур булыр – бар чат!

## ХАЛКЫБЫЗ – УҢГАН

Бүген соңгы кичне кунам
Изге хастаханәдә,
Биргән гомер, саулык өчен –
Бик рәхмәтлебез аңа.

Ходай бирсен зур тынычлык
Озын гомер һәм саулык,

Сәламәтлек кадерен белү
Яшәү өчен зур “ярлык”.

Булган белем, саулык белән
Зур эш кылып һәр төштә,
Газиз халык һәм тел өчен
Тырышлык кылыйк эштә!

Тормышны сөйсәк, чыгарбыз
Замана баткагыннан,
Ышанычлы һәм хөрмәтле
Кешеләр барыр алдан.

Күңелне әле төшермик
Илебез безнең зурдан,
Булганның кадерен белик –
Байлыклар булыр мулдан.
Халкыбыз безнең уңган.

## ВАКЫТЛЫЧА КАРАШ

Чаптырып йөрер атлар юк хәзер
Булганнары да эшсез,
Я аз гына чапкан була
Я булмаса, бик көчсез.

Сәбәбен бик тиз табалар
Техника заманасы,
Табигать бетә баруга
Исләре китми, анысы.

Тонналап йөкләр күчергән
Юк бит хәзер атлар да,
Булганнарын тырышалар –
Тизрәк элеп какларга.

Табигатькә хәзер караш
Вакытлыча – бер көнлек,

Нишләп кешелек сакламый
Аны шулай, гомерлек.

## АВЫРЛЫКЛАР ЮГАЛЫР

Язмыштан – юктыр ул узмыш
Бу шулай тормыш кормыш,
Мин сине рәнҗеткән булсам –
Ачулан, мине орыш!

Тормышта күп каршылыклар
Гел килеп чыгып тора,
Аны әйләнеп узганда
Юлны кирегә бора.

Яхшылыкка, изгелеккә
Юнәлгән юлларыңны,
Әйләндереп, борып ташлый –
Каерып кулларыңны.

Без кеше, шуңа да аңлыйк
Авырлыклар югалыр,
Изге ниятле эшебез –
Яктылыкка юл алыр.

Чылтырап агар чишмәләр
Саба җилләре исәр,
Без көткән саулык, бәхетләр
Безгә дә килеп җитәр,
Борчулар үтеп китәр!

## КҮРКӘМ БУЛЫР

Көзнең дә бит
Килеп җитте –
Соңгы ае,
Озак көттермәс
Тиздән җитәр –
Язның мае.

Гомернең дә
Сиздермичә –
Көне узар,
Өр яңасы
Киемнең дә
Бик тиз тузар.

Башкарыр эш
Күп булса да –
Туктап алыйк,
Ә эшләгән
Гамәл өчен –
Колак салыйк.

Яхшы булса
Кылган эшләр –
Тормышыңда,
Булыр күркәм –
Киләчәгең,
Язмышың да!

## АКЫЛГА КИЛИК

Күз буяу арта һәм ныгый
Шуңа какшый дөньясы,
Минутлык, көнлек ялтырау
Бары яшәү кыйбласы.

Тырышалар ялтырарга
Күгәргән булсалар да,
“Без чиста!” – дип мактаналар
Пычрактан тулсалар да.

И кешеләр, сез ник болай
Язасыз кешелектән,
Чиста, намуслы хезмәткә –
Караш бара этлектән

“Этләр – алар була!” – диләр
Һәрвакыт ышанычлы,
Ләкин, хәзер алар да бит
Капкалыйлар танышны.

Җәмәгать, килик акылга
Югалтмыйк кешелекне,
Намус, тырышлык һәм бәхет –
Кире кайтсын элекке!

## УЙЛАНАМ

Утырам, уйлыйм, уйланам
Дөньясы кая бара,
– Җир түгәрәк – күчә, диләр
Ә күчә кая таба?

Ул барса һәм күчсә иде
Бары тик яхшы якка,
Тыныч тормыш кайтыр иде –
Кешеләргә ул чакта.

Шатлык белән, алар барып
Эшләрендә эшләсә,
Намуслы, изге хезмәте –
Мakталудан төшмәсә.

Кешеләр булыр бәхетле
Изгелек, пакълык кылыр;
Һәр гаилә тыныч яшәп –
Гел үрнәк булып торыр!

## ТИРӘН МОҢ

“Җырлыйк әле”, – дигән бәйге
Гимназиядә узды,
Шәһәр күләм җыелганнар –
Монда моңнарын сузды.

Бездән дә теләп катнашты
Наил кызы Фәния,
Ул да безнең уңган кеше
Моңга-тавышка ия.

Татар халык җырын сузды
Моңга халкыбыз бик бай,
Барыбыз да шатланыштык
Тигәнгә безгә бу җай.

Күңелләр бик күтәрелде
Эшкә сәләт нык артты,
Халкыбызның тирән моңы –
Тагы үзенә тартты.

## НӘФЕСЛӘНМӘ

Оч син иркен, оч син канатланып
Очар канатларың булганда,
Риза бул тормышка – нәфесләнмә
Муллык белән өстәл тулганда.

Син эзләмә гаеп, ә ярдәм ит
Тикшерүче булып килгәндә,
Бары эзләп йөрсәң – табып була
Без Фәрештә түгел, ә бәндә.

Дөнья ул әйләнә, булса каршылыклар
Канатларың булсын таяныч,
Син аларны сакла: бәрмә, һич сындырма
Югалтуы авыр, аяныч.

Без шуларны аңлап, дөреслекне саклап
Бу дөньяда шулай яшәсәк,
Тормыш матураеп, кыек юл тураер
Бу юлларны бизәр – гөл, чәчәк!

## БӘХЕТ БЕЛӘН ҮТКӘРИК

И яшь буын, сез ник болай
Башка буыннан үзгә,
Югыйсә бит, барысы әзер
Иң яхшысы гел сезгә.

Халык язмышын белсәгез
Баскандай ут-күмергә,
Булырсыз намуслы һәм саф
Ихтирамлы гомергә.

Тотыгыз сез, кулга китап
Чын тарихны ачыгыз,
Начар юлга чакырганнан
Ераккарак качыгыз!

Телефоннарны да бары
Кирәктә кулланыгыз,
Тәрбия, белем алсагыз –
Нык булыр юлларыгыз.

Онытмагыз, сез барчагыз
Безнең киләчәк буын,
Бары тик зур бәхет белән
Үткәрик яшьләр туен!

## ТУГАН КӨН ТЕЛӘГЕ

Озын гомер, Равилә апа,
Ходай бирсен тынычлык,
Борчу-авырулар күреп
Инде бик озак чыныктык.

Ходай бирсен аяз көннәр
Һәм кояшын, һәм аен;
Дөнья игелеген күрик –
Һәрвакыт белеп җаен.

Гарәпчәдән исемегез
Язгы кояш, үсмер чак,
Бөтен булган авырлыкны –
Мичкә ташлап, утка як!

Әтиегез дә Алланың
Иң мактаулы кешесе,
Балаларга өлеш чыккан –
Алар ходай илчесе.

Абыегыз Рәшит – батыр
Туры юлдан баручы,
Кешегә ярдәм итүче –
Гел игелек салучы.

Тормыш иптәшегез – Рәис
Җитәкчене аңлата,
Бәхетле, матур яшәгез –
Кайчак аяк тайгач та.

Аяк асларында да гел
Булмас бит бозы-кары,
Яшел чирәм-чәчәкләрдән
Йөрербез әле бары.

Шуны тоеп һәм нык аңлап
Яхшыны күрә белеп,
Оныкларыгыз да йөрер –
“Дәү әттә, әннә!” – диеп.

## ЮБИЛЕЙ ТЕЛӘГЕ

Менә җитте кыш та
Бигрәк матур тышта,
Чана-чаңгыда йөрибез
Бер дә калмый узышта.

Кышның син нәкъ уртасында
Бу дөньяга килгәнсең,
Зәңгәр күктән “Зөһрә йолдыз”
Булып җиргә иңгәнсең.

“Кәҗә мөгез”нең – мөгезен
Гомер буе акладың,
Алдан тарттың, арттан эттең –
Тормышны нык сакладың.

Шуның өчен, сиңа бүген
Ике бишле куябыз,
Гомер юлы авырлыгын –
Себерәбез, җуябыз.

Чиста, матур, мул тормышта

Нык басып алга атлыйк,
Озын гомер, саулык белән
Дус-туганнарны саклыйк.
Авырып бер дә ятмыйк!

## “ТАТАР ЕГЕТЕ” БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕСЕНӘ

Гаилә ул матур
Ул бик нык тамыр
Аны сакласаң –
Мәңгелек калыр!

Шундый гаиләдә
Рәмзис тә туган,
Мөгаллим каны –
Буынга тулган.

Шуңа ул аңлый
Кеше күңелен,
Изгелек кылу –
Начар түгелен.

Табигатьне дә
Ул бик ярата,
Бары яхшылык –
Кына тарата.

Бик нык тәрбия
Һәм яхшы белем,
Гимназиябез –
Нык бирә безнең.

Гол Гали урамында
Бит ул урнашкан
Каюм Насыйри
Медален таккан.

Без бик бәхетле

Хәзерге көндә,
Шуңа бик аяз –
Караңгы төн дә!

## АК ЮЛ

Күренә – ал таңнар чаткысы
Бу безнең – киләчәк яктысы,
Бәхетле тормышлар кайтырлар –
Елмаеп ал таңнар атарлар.

Дөньяга нык басар балалар
Чәчәккә күмелер калалар,
Дөреслек, чынбарлык ачылыр –
Төзәлер авырткан яралар!

Син, дускай, курыкма давылдан
Ялгыштым, китеп, – дип, авылдан;
Җил-давыл, тына ул, басыла
Йөрибез, нык басып, ак юлдан!

## ТАРИХ

Авыл-калалар тарихы
Бу безнең үткәнебез,
Сезнең бу, Фирдәүс ханым,
Күп еллык хезмәтегез.

Ике томлык бу китапта
Халкыбызның үткәне,
Авыл, район, калаларның
Исәне һәм беткәне.

Әби-бабайлар тарихы
Узганы – бүгенгесе,
Эшкә, белемгә сәләтле
Булганнар бит күбесе.

Тау һәм елга исемнәре
Чишмәләре ни тора,
Урамнар һәм кушаматлар –
Тарихны ача, ера.

Сезнең бу, гаять зур хезмәт
Зур дәрәҗә һәм уңыш,
Аны алып укыганда –
Ачыла бара бар тормыш.

## ҖАЙЛАНЫР

Кышның беренче ае да
Атлады ике адым,
Бер адым атларга калды
Бу елда аның тагын.

Адымы булсын бәхетле
Уңдырышлы һәм бик бай,
Яңа еллар алып килсен –
Илгә – бәхет, эштә – җай!

Саулык һәм тынычлык белән
Кешеләр булсын эштә,
Ихтирамлык һәм изгелек –
Һәрвакыт чыксын өскә!

Шулай, тормышлар җайланса
Бәхет килер кешегә,
Бар җирдә дөреслек булса –
Җайлы барыр эше дә!

## САУЛЫК АРТЫР

Менә җитте декабрьның
Егерме икесе бүген,
Төннең дә бит – иң озыны
Ә иң кыскасы – көннең.

Кояш та елмаеп тора
Тирә-як ап-ак матур,
Тиздән көннең озынлыгы –
Һәр көн озаер, артыр!

Менә сугар сәгатьләр дә
Кыш бабай кыңгыравы,
Туар кыш уртасы – гыйнвар
Салкынның соңгылары.

Аннан көтәбез февральне
Өченчесен – кыскасын,
Кышка йокы алганнарны –
Әле уятма, йокласын!

Табигатьнең һәр фасылы
Үзенчә бай һәм матур,
Аны күрә, аңлый белсәң –
Үзеңдә саулык артыр!

## ЯҢА ЕЛГА КЕРӘБЕЗ

Декабрьнең соңгы атнасы
Көн кояшлы һәм матур,
Яз айлары килеп җиткәч –
Кошлар да очып кайтыр.

Әй табигать, табигать
Тыныч көнгә без бик шат,
Бары саулык һәм бәхетне –
Китереп тор, син күп кат!

Яңа ел да килеп җитте
Ишекләрне киң ачып,
Син дә уяу һәм тырыш бул
Камырың тулган ташып.

Өстәлләр мул һәм бик матур
Дуслар, туганнар булгач,
Яңа елга без керәбез –
Сәгать унике тулгач.

## УЗАР ДА КИТӘР

Бу күзләрем – кемне соң күзли
Ни көтә ул – нәрсәне эзли,
Дөреслек һәм хаклык бик кирәк –
Яна, даулый, дулый бу йөрәк.

Нидер эзли, кемнедер көтә
Тукталганны өстери – этә,
Көч-куәт һәм хәле килгәндә –
Күз яшьләре тама һәм бетә.

Мондый хәлне кичерә бик күпләр
Гөл бакчасын – баскалый чүпләр,
Тынычлык һәм саулык булганда –
Бар авырлык узар да китәр!

## УЯН КЕШЕЛЕК!

Иске ел да бетеп килә
Калды бары биш көне,
Озая башлады көннәр
Кыскара хәзер төне.

Бу көннәр озайган саен

Артса иде тынычлык,
Намуслы хезмәт башкарып –
Гомер буе тырыштык.

Өстәге бар түрәләр дә
Бәлки аңлый башларлар,
Гел кимчелек эзләүләрен –
Ыргытырлар, ташларлар.

Аларга да, бәлки, кайтыр
Әдәплелек – кешелек,
Намуслы закон кирәген –
Күп кат искә төшердек.

Иртән чыгарган законнар
Кич җиткәндә ярамый,
Уңай тараган тарагың –
Икенче көн тарамый.

И кешелек, уян син, тор
Намусың кайтсын кабат,
Узган гомер тарихыннан –
Алырга кирәк сабак!

## ЕЛМАЕП, УЗА ПАРЛАР

Килеп җитте гыйнварның да
Иң уртасы – “эссесе”,
Болай булуның сәбәбе –
Тикшерүнең көчлесе.

Бар документ һәм кәгазьләр
Барысы да китә ходка,
Аннан кирәге калмаса –
Ташларсың аны “утка”.

Хәзерге тормыш, җәмгыять
Корылган тик кәгазьгә,

Яхшы тормыш һәм киләчәк –
Кала бары вәгазьдә.

Намуслы хезмәт башкару
Нигә соң авырлаша,
Чиста, аяз, матур көнне –
Көтмичә, болыт баса.

Ышаныйк матур тормышка
Аязып атар таңнар,
Табигать әле йокыда –
Ябынган ап-ак карлар.
Елмаеп, уза парлар.

## КИЛЕП ҖИТӘР

Менә җитте туган көн дә
Сизелми уза гомер,
Узган гомер әллә чәчәк –
Әллә көйгән ул күмер.

Булса әгәр ул саф чәчәк
Шатландырыр халыкны,
Әгәр булса көйгән күмер –
Җылытыр чәй-азыкны.

Кешегә гомер тик бер кат
Тормышта бит бирелә,
Изгелек кыл, матур яшә –
Аны борма кирегә!

Булган борчу-авыртулар
Тәгәрәр, узар, китәр;
Бик ерак тоелган бәхет –
Безгә дә килеп җитәр!

**АМИН**

Туган телем, бөек халкым –
Синең тамырың бик тирән,
Чын дөреслек һәм тарихны –
Ачарга син, нык өйрән!

Күп гасырлар син тапталдың
Изелдең һәм кысылдың,
Әгәр “шулай икән!” – дисәң
Зинданнарда тотылдың.

“Татар барда – хәтәр бар!” – дип
Сиңа нахак такканнар,
Бар дөреслек, чынбарлыкны –
Учакларда якканнар.

Татар ул – бирми хәтәрне
Ә бирә намус, тәхет;
Аның белән эш йөрткәннәр –
Тапканнар бары бәхет!

Гыйлемлек һәм тырышлыгы
Һәрвакыт үрнәк булган,
Бездә табылган байлыктан –
Ил баеп, ташып тулган.

Аның бары тик үзенә
Ике кисәк бирелгән,
Ә калган туксан сигезе –
Ил буенча бүленгән.

“Татар – башыңны ашар!”да
Туры килми халыкка,
Ул юл бирми һәм булышмый –
Беркайчан да сатлыкка!

Шундый халык бит син, татар,
Эш сөючән һәм галим,

Зур ихтирам һәм хөрмәткә –
Ия булырсың, Амин!

## ТАБИГАТЬ ЮРГАНЫ

Кышның да бит менә җитте
Кыскасы – соңгы ае,
Озак көттермәс, килеп җитәр –
Чәчәкле ае – мае!

Күрә белсәң, табигатьнең
Бик матур һәр ае да:
Кышын ак юрганын япса,
Яшелен ябар маенда.

Һәр юрганын аның кирәк
Яратырга – пакъларга:
Ак юрганын – пычратмаска,
Яшелен – утка якмаска!

Көзен кабат алыштырып
Ябыныр ул – сарысын,
Байлык белән куандырыр –
Тереклекнең барысын!

## САУЛЫК-СӘЛАМӘТЛЕК

Саулык бит ул – бик зур байлык
Аны кирәк сакларга,
Зыян китерүчеләрдән –
Яшерергә, якларга.

Тәмәкесе, наркотигы,
Аракысы – бик начар;
Булган бар акыл, саулыгың –
Алардан куркып качар!

Кешелек, син бик уяу бул
Барма якын аларга,
Алар белән син дуслашма –
Һәм тырышма ярарга!

Ал кулыңа көрәк, чүкеч
Себеркесен-тырмасын,
Бар табигать чиста булсын –
Чүпләр очып тормасын!

Изге хезмәттән бушагач
Типкәлә син тупларга,
Саулык-сәламәтлек булгач –
Күңел төшмәс, юк-барга!

## ИГЕЛЕК КАЙТЫР

Көне дә бик матур
Кояш та елмая,
Яз җиткән шикелле –
Урамда боз тая.

Аяклар чылана
Җыелган сулардан,
Юнәлеш биреп куй –
Җибәр бу юллардан!

Йөрер юл ачылыр
Кире сүз әйтмәсләр,
Сиңа тик кайтырлар –
Җылы сүз, рәхмәтләр.

Әгәр син эшләсәң
Тормышта изгелек,
Кайтыр ул үзеңә –
Булып гел – игелек!

## ДӨНЬЯ – ТҮГӘРӘК

Була бит туганның
Кадерле-асылы,
Дусның да гел шулай
Акыллы-якыны.

Акыллы дусларың
Яшәргә көч бирә,
Бар күркәм сыйфатны –
Ныгыта, үстерә.

Һәрвакыт андый дус
Сиңа нык таяныч,
Югалтсаң син аны –
Монысы бик аяныч.

Дөньяда дусларча
Аңлашып яшә гел,
Беркайчан дустыңа
Тидермә ачы тел!

Туганнар һәм дуслар
Якында булганда,
Дөнья ул түгәрәк –
Шатлыктан тулганда.

## ТОРМЫШ – МАТУР

Дөнья түгәрәк булса да
Сикәлтәле, күп кырлы;
Күп авырлыклар күрсә дә –
Халкым моңлы, шук җырлы.

Кошлар оча җылы якка
Канатын каермагыз,

“Алар бай, алар ярлы”, – дип
Кешене аермагыз!

Байлык ул – булмый мәңгелек
Гомер дә бит килә бер,
Бәхетле хезмәт җимеше –
Монысы – байлык, монысы – сер.

Бу серне син ачар өчен
Бул намуслы һәм тырыш,
Изгелек кылып яшәсәң –
Бик матур булыр тормыш!

## ШУНДЫЙ ТЕЛӘКТӘ

Көне шундый бүген безнең
Әтиләрнең киткән көн,
Бу көнне ап-ак дөнья да
Булды нәкъ караңгы төн.

Үземнең әтием минем
Узган иде алтмыштан,
Иртә китүнең сәбәбе –
Сугыш күрү – атыштан.

Каты яра алса да ул
Тормышта булды үрнәк,
Һәрвакытта әниемә –
Булды чын ир, нык терәк.

Тормыш иптәшемнең дә бит
Әтисе шундый иде,
Бик тырыш һәм “алтын куллы”
Изгелек кылып йөрде.

Ул да иртә китеп барды
Тутырмый да алтмышны,
Мунчада каты чабыну –

Һәм салкын су ялгышы.

**5.02.2013**

Бер көнне алар киттеләр
Бары еллары башка,
Тик унөч ел аермасы
Язылып куелган ташка.

Дөньялыктан китсәгез дә
Тәрбияне биргәнсез,
Намуслы хезмәт, тырышлык –
Җиңәчәкне белгәнсез!

Үзегезнең дә урыннар
Булса иде җәннәттә,
Кешелекле, эчкерсезләр –
Анда кирәк – әлбәттә.
Без дә шундый теләктә!

## ДУЛКЫН

Тирбәлә, уйный, челтери
Суның йомшак дулкыны,
Урыны белән шаулап куя –
Әллә монда упкыны.

Табигатькә карап ага
Җил булмаса – ул да тын,
Җил-давыллар булып торса –
Ярга нык бәрә дулкын.

Матур, аяз тыныч көндә
Бик тын суның өсләре,
Яшьләр дә бит мондый көндә
Бүлешәләр хисләрне.

Дөньясы да аның һәрчак

Булса иде гел тыныч,
Тынычлык, саулык булганда –
Бик күркәм булыр тормыш!

## ГҮЗӘЛ ЗАТ

Күзләрең синең бик матур
Йөзләреңдә ай нуры,
Матурлыктан син оялма
Күземә кара туры.

Әй гүзәл зат, гүзәл зат
Йөзең сылу – мин бик шат,
Сиңа карап мин сокланам
Сине күзлим мин кат-кат.

Күзең, йөзең генә түгел
Саф синең күңелең дә,
Аралашып сөйләшкәндә
Елмаясың үзең дә.

Уй-фикерләрең дә бик саф
Йөрәгеңдә изгелек,
Моның өчен рәхмәтлемен –
Туган халкыма элек!

## БӘХЕТТӘН КОТЛАР

Синең күзләрең елмая
Якын итү – көлүме,
Әллә хис-тойгыны минем
Тулысынча белүме?

Елмайсын, елмайсын шулай
Алар бәхет юрыйлар,
Матур теләк һәм хисләрне

Тик ак юлга юллыйлар.

Кайчак күзләрең моңлана
Карашың да томанлы,
Әллә болыт сарган күктә
Атып килгән бу таңмы?

Яктырып ата таңы да
Тарала бар болытлар,
Күзләрең матур елмаеп –
Мине бәхеттән котлар!

## ШАТ ЕЛМАЙСЫН

Челтери, чишмә челтери
Анын бар үз тавышы,
Серен яшереп, ул кача –
Якын үскән камышы.

Әй чишмәкәй, чишмәкәй,
Синдә күпме сер ята;
Сиңа килеп, серен ачып
Күпләр күңелен бушата.

Кабул итә бу серләрне
Чишмәнең саф сулары,
Һәр кешегә саулык өсти –
Челтерәп, агулары.

Әй чишмәкәй, чишмәкәй,
Гел агып тыр син шулай;
Төннәрен бик шат елмайсын –
Күктән карап, сиңа ай!

Синең суларыңны эчсен
Хәзерге бу сабыйлар,
Яхшы саулык һәм бәхеткә –
Ия булсын андыйлар.

## ТАБИГАТЬ ШИФАСЫ

Яз җитә бит, яз җитә
Елмаеп көлә кояш.
Синең елмаю да шулай
Якынлашып килгән яз.

Аның килүен тизләтү
Күп кешенең теләге,
Матур хисләр белән тула –
Бар кешенең йөрәге.

Кар сулары агып узгач
Тишелеп чыга күп чәчәк,
Бар табигать матурая
Бу бит безнең киләчәк!

Сабый балалар да уйнар
Тәгәрәшеп үләндә,
Табигать саф һәм бик матур –
Шифа бирә чирәм дә.

## ЧИШМӘ СУЛАРЫ

Елмаеп суга барасың
Чиләк-көянтә асып,
Матур атлап син кайтасың
Йөрәк януын басып.

Әй син, гүзәл татар кызы.
Көянтәңне ташлама;
Техника китергән суны –
Бер үк эчә башлама.

Чишмә буйлары бик ямьле

Сулары да бик тәмле,
Аны кулланган кешенең –
Күңеле чиста, бел яме!

Борынгыдан калган гадәт
Халкым чиста күңелле,
Саф чишмә сулары эчү –
Элеккесе – бүгенге.

## ПАРОДИЯ

Килә кайчак, салкын җиргә ятып,
Янган күмер булып кызарасы;
Кабат кайтып, егет-яшьлегемә
Бик акыллы, гүзәл кыз аласы.

Һөнәрне дә алыштырмас булам
Намуслы һөнәр бит, хәзер гөнаһ,
Ә кем алдап, күп байлыклар җыя –
Исәпләнә икән, алар тыйнак.

Заманамы гаеп, әллә илме
Без бит бик бай һәм зур илдә туган,
Шуңа күрә, инде илебезгә –
“Диваналар” бик күп булып тулган.

Киләчәк соң безнең, ничек булыр
Гаилә өстәлләре – нәрсә белән тулыр?
Буш шешәләр, наркотиклар белән –
Күп кешенең гомере дә буылыр.

И кешеләр, бәлки, без дә бер көн
Чын кешеләр булып, уянырбыз;
Элеккечә намус, вөждан тулып –
Җир анага барып, таянырбыз.
Барысына да, шулай, таң калырбыз!

## ВАКЫТ БИЛГЕЛӘМИ

Гомерне бит билгеләми еллар
Билгеләми аны язмышлар.
Була аның бик матур көннәре –
Ямьсезләре кайчак, ялгышлар.

Гомерне бит, сайлаган вакытта
Ике юл чатында каласың,
Якты тормыш, бәхет ишекләрен –
Йә ачасың, яки ябасың.

Гомерне бит билгеләми вакыт
Бәяли тик аны изгелек.
Кичерерсең озын-озак гомер –
Син яшәсәң кылып игелек!

Гомерең синең булсын бик тә озын
Киләчәк буыннар соклансын,
Изге эшләреңне белеп, тоеп –
Яхшылыкта ул да кулलансын!

## ЙОКЫДАН АЙНЫРГА

Кышның да, бит җитте, иң соңгы –
Йомгаклау һәм җыю атнасы;
Кешегә – узган чор, гомергә –
Бик уйлап, нәтиҗә ясасы.

Тиздән бит, бик тиздән табигать
Яңадан йокыдан уяныр,
Йокыда вакытта зыянны –
Күрмәгән булса ул – куаныр.

Кешелек, безгә дә бик вакыт
Айнырга ваемсыз йокыдан;
Ышаныч, дәрәҗә, көч белән –

Чыгарга пычрак чокырдан!

Чокырның өсләрен чистартып,
Тигезләп, чәчәкләр үстерик;
Бар булган мәшәкать-кайгыны
Җыйныйк та чокырга тиз күмик.
Дусларның кадерен бик белик!

## ТАТАР КЫЗЫ

Татар кызы бик сөйкемле
Үзәкләрне ул өзә,
Агымга да каршы бара –
Колач салып, ул йөзә.

Әй милләтем, милләтем,
Бигрәк сылу кызларың;
Йөзләрендә нурлар балкый –
Күктәге йолдызларның.

Йолдызларның бар дуслары –
Бар кояшы, бар ае;
Очып сандугачлар сайрый –
Бигрәк матур, май ае!

Милләтем – татар кызының
Бик сөйкемле йөзләре,
Күңелләргә дәва бирә –
Йомшак әйткән сүзләре.

## ЮГАЛМАС, ҮСӘР

Гимназия – үсә, ныгый
Даны һаман күтәрелә,
Зур ярышларда катнашып –
Төшеп калмый, өскә менә.

Рәсәй күләм ярышта да
Гимназия үрнәгендә,
Укучылар катнашалар –
Җиңү яулап үрләрендә.

Республика ярышлары
Алардан бер читтә калмый,
Укучылар гел катнашып –
Приз алып, урын яулый.

Гимназиябез бит безнең
Туган телдә белем бирә,
Ана телендә гел шулай –
Тәрбия бирәсе килә.

Безнең теләк һәм тырышлык
Ул югалмас – ныгыр, үсәр;
Киләчәктә күп мәктәпләр –
Туган телдә эшкә күчәр!

## АҢЛАРГА КИРӘК

Яз җитте, керәбез мартка
Кояш матур елмая,
Карлар эри, бозлар чыга –
Кайчак, аяклар тая.

Кошлар да бик сайрашалар
Җыелышып очалар,
Яңа кайткан кош күрсәләр –
Сәламлиләр, кочалар.

Кешеләр дә елмаялар
Балалар да урамда,
Алар бик шат – карамыйлар
Кайчак, булган буранга.

Кешеләр дә табигать күк
Бер елмая, бер көлә;
Кайчак, буран кебек, дулый –
Аннан гаебен белә.

Тереклек көйләгән шулай
Аны кирәк санарга,
Кичләрен кояш та бата
Иртән чыга таңнарда.
Моны кирәк аңларга!

## ХӨРМӘТЛЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР

Сигезе бит – бәйрәм көне
Җомгага туры килә,
Изге зат булуыгызны –
Ир-атлар бар да белә.

Сез бит безнең зур ышаныч
Таяныч һәм назлы гөл
Кызлар – йолдызлар булгансыз –
Ир-ат дускай, моны бел!

Безгә юлны яктыртасыз
Беркайчан абынмаска,
Сүзең дөрес һәм бик туры
Юл бирәсез таймаска!

Ир-ат сезгә бик рәхмәтле
Күркәм, мөлаем затлар,
Сезне күреп сөйләшкәндә –
Үсә кебек канатлар

Кабат котлап, яңгырасын
Безнең җырыбыз, дуслар,
Сезне котлап очып кайтыр –
Сыерчыклар, күп кошлар!

## ӘЙ ТОРМЫШ

Әй, тормыш, тормыш
Заман таләбе,
Атлап киткәнче –
Нык бас әвәле.

Кая барсаң да
Адымнарың нык,
Хезмәт яратсаң –
Яшәрсең бик тук.

Әй тормыш, тормыш
Мин бит теләмим,
Чит тел көйләрен –
Яратып көйләмим.

Аерма мине
Туган телемнән,
Үз телем биргән
Ныклы белемнән!

Әй тормыш, тормыш
Бутама юлны,
Белмичә бармыйк –
Уңмы бу – сулмы.

Аерма безне
Күркәм гадәттән,
Туган телем һәм
Яхшы сәләттән!

## ТУГАН ТЕЛЕМ – ЯКТЫ КӨНЕМ

Туган телем – якты көнем
Син зур бәхет, шатлык минем;

Тапшырыла бара шулай –
Күп гасырдан килгән белем.

Туган телем, син бит бик саф
Ак чапанлы зирәк карттай,
Сикерәсең киртәләрне –
Нык көч ташып торган аттай.

Туган телем, син бик аяз
Болытсыз күк, кояш нуры;
Боргаланмый – сыргаланмый
Әйткән сүзең – һәрчак туры.

Туган телем, син шулай кал
Киң ачылсын – зур юлларың,
Һәрвакыт зирәк һәм уяу –
Эш башкарсын ул кызларың!

## ТАБИГАТЬ УЯНА

Менә тагын язлар җитте
Карлар эри, сулар җыела,
Кыш буена туңган карлар –
Тамчы булып җиргә коела.

Син кара, бел моны – үзең күр
Яз якын кешегә – шуны бел,
Йокыдан табигать уяна –
Елмая, шатлана бу күңел.

Кышның салкын көннәрендә
Өшегәнме әллә күңелең,
Язның кояш нурларыннан
Эреп агар карлар көн-төнен.

Карап торам кабат язга,
Тиздән җитәр – язның мае,
Аннан бик тиз җитәр җәй дә –

Дөнья көләм июль ае!

## ТАБИГАТЬ ФАСЫЛЫ

Табигатьнең һәр фасылы
Үзенчә ямьле, матур;
Аны күрә, тоя белсәң –
Ярсымас, тыныч ятыр!

Дүрт фасылы да, үзенчә
Зур матурлыкка ия,
Биек агачлар да үсә –
Күкләргә тия-тия.

Шул агачларда уйныйлар
Тиеннәр дә чабышып,
Кышка азык әзерлиләр
Чын хуҗага сабышып.

Чикләвеген дә җыялар
Җиләген, гөмбәсен дә;
Үләннәрен дә сайлыйлар
Кирәген – һәммәсен дә.

Җәен-көзен уздыргач та
Җитә бик салкын кыш та,
Кайбер җәнлек яңа тунын
Кия, чыкканда тышка!

## ОЗЫН ГОМЕР

Яктырып туды бүген көн
Ярты кышны без уздык,
Бар мәшәкать-авырлыкны
Юлыбыздан без сыздык.

Узар, шулай, гыйнварның да
Кыскарган бу төннәре,
Елмаеп, кояш җылытыр
Озынайган көннәрне.

Шундый көндә син тугансың
Аваз салып дөньяга,
Сафлык, чисталык аена –
Рәхмәтлемен мин шуңа.

Ходай бирсен саулык, бәхет
Кыш ае чисталыгын,
Тормышыбызның ныклыгын –
Май ае матурлыгын.
Озын гомерләр тагын!

## БИШЛЕЛӘР

Менә инде күптән көткән
Сукояр ае җитте,
Быелгы бу айны күңел
Бик дулкынланым көтте.

Чөнки бу елда бит гомер
Ала ике бишлене
Лаеклы булсын бишләргә
Изге эшләр исеме.

Ходай бирсен әле безгә
Кабат бик күп бишлеләр,
Боларны күп алган саен
Аңлыланыр кешеләр.

Бишлеләр күбәйгән саен
Акыл килер илемә,
Ике бишле һәм “түгәрәк”
Җитеп торыр гомергә.

## БӘХЕТ ЧӘЧӘРБЕЗ

Бүген бигрәк көне матур
Балкып тора кояшы,
Әллә инде бу, көннәрнең
Бик бәхетле оясы.

Ишектән дә кояш кебек
Килеп керде хатыным,
Әйтерсең лә шул кояшта
Ялтыраган “алтыным”!

Ул китергән бу нигъмәтләр
Тәнгә күпме көч кертә,
Бар авыртуны чыгара –
Аяктан төртә-төртә.

Ходай шулай саулык бирсә
Бик бәхетле яшәрбез,
Бар изге эш эшләүчегә –
Туганнарча, дәшәрбез.
Илгә бәхет чәчәрбез!

## ЫШАНЫЧ

Табигать уяна
Озая көннәре,
Авырлыклар китә
Кыскара төннәре.

Тормышка ышаныч
Көннән-көн гел арта,
Изгелек һәм сафлык
Үзләренә тарта.

Киләчәкне уйлап

Яңа эшләр туа,
Заман авырлыгын
Ул күңелдән куа.

Шатланып үсәләр
Сабыйлар бар җирдә,
Саулык, бәхет килер –
Безгә дә бу илдә!

## ҮТКӘННӘР БУЛСЫН САБАК

Менә җитте туган көнем
Юбилеем да минем,
Саулыгым кайта яңадан
Бу минем бәхет көнем.

Хыяллар кабат яңара
Башкарасы эшләргә,
Алда зур уңышлар көтә
Кергән кебек төшләргә.

Рәхмәтлемен мин ходайга
Өмет биргәнгә кабат,
Тырышып, рәхәт яшәрбез
Үткәннәр булсын сабак!

## БӘХЕТЛЕ ЗАМАННАР КИЛЕР!

Һәр көн иртән кояш чыга
Бар тереклек йоклап тора,
Уңыш теләп киләчәккә
Бик матур планнар кора.

Тормышка ашса бу планнар
Бар тереклек тыныч йоклар,
Сабыйлар туган гаиләне

Дус-туганнар бар да котлар.

Алар бәхеттә үсәрләр
Бар да илнең киләчәге,
Безгә билгеле аларның
Матур дөнья төзәчәге.

Эчкечелек, начарлыклар
Чүп-чар булып себерелер,
Кешегә зыян килмәскә –
Бер җиргә чүпкә өелер!
Бәхетле заманнар килер!

## СИН БОРЧЫЛМА!

Тирбәлә, үсә, чайкала
Күңелемдә хыяллар,
Уйлау сәләте булмаса –
Кеше соң ничек аңлар?

Зәңгәр күктә дулкын кебек
Тезелеп оча казлар,
Күңелдә җылылык сүнсә
Безне бит кемнәр аңлар?

Матурая бара көннәр
Табигать тә ачыла,
Авырлыкка тап булсаң да
Син борчылма, ярсыма!

Тыныч күңел белән уйла
Авырлыкны җиңәргә,
Тормышны бергә сөйрәсәң –
Авыр булмас иңнәргә!

## ЙОЛДЫЗЛАР

Бүген соңгы кич тә җитте
Хастаханәдә куну,
Монда алган бу саулыктан
Миңа бу кабат туу.

Бар авыру дәва алып
Тормышка кайта кабат,
Нык басып, алар атлыйлар –
Әйтерсең, атлый солдат.

Монда эшләүче табиблар
Табибәләр бик уңган,
Аларның бар хезмәте дә
Кешелек белән тулган.

Сезгә без бик рәхмәтлебез
Хөрмәтле хатын-кызлар,
Сез бит матур, зәңгәр күктә –
Янып торган йолдызлар.

## АҢЛАЕШСЫЗ ДӨНЬЯ

Ел саен тикшерү чыга
СанПиннан да киләләр,
Мәктәпләргә ничек кирәк –
Аяк чала беләләр.

Алар әйткән кимчелекнең
Әйтеп китәм кайберсен,
Ныклы фикер йөрткән кеше
Дөрес аңлар күбесен!

Урап уза уку йортын
Утыз еллык асфальт юл,
Якын үскән агачларның
Тамырларын ”кискән” ул.

Үсемлек тә йоклап ятмый
Йокласаң эшләр яман,
Нык үскән тамырлар белән
Күтәрә бара һаман.

Юан агач тамырлары
Өлешчә юлны бозган
Утыз еллык бу асфальтны
Тигезсезләгән, сызган.

Моның өчен без гаепле
Кирәк асфальт салырга,
Йә булмаса агачларның
Тамырларын чабарга!

Моны да закон якламый
Горзеленхоз да каршы,
Бу эшләргә каян акча
Табарга белми – барысы.

Башка кимчелекләр бар да
Үтәлде күп булса да,
Үтәлмәде берничәсе –
Инде вакыт тулса да.

Кайберсе бик соң табыла
Нишләп ул башта булмый,
Әйткәнне эшләп бетергәч –
Табыла – туктап тормый

Бассейндагы кимчелек
Башкарылып бетелде,
Эш беткәч – тагы берсенең
Калганлыгы беленде.

Юыну бүлмәсеннән соң
Өч метр бассейнга,
Шул араны кирәк икән –

Җылы юлдан барырга!

Җәйгән плитканы хәзер
Кирәк кабат сүтәргә,
Йөри торган юл астына –
Җылы торба өстәргә!

Һич аңламыйм, бу кимчелек
Башта әйтелми нигә,
Идәннәр җәелеп беткәч –
Кирәк эләргә “чөйгә”

Кабат идәннәр ватыла
Куярга җылыткычны,
Тик аңларга теләмиләр –
Ялгауны очын-очны.

Хәзер дөнья аңлаешсыз,
Бәлки шундый теләктер:
Бәхетле, тыныч тормышта
Яшәтмәскә кирәктер!

## ИЯ ЗУР КӨЧКӘ!

Март аеның бер атнасы
Инде узып та бара,
Ләкин кыш бирешми әле –
Һаман көн салкыная.

“Мартта – шарт була!” – дип халык
Белмичә шул әйтмәгән,
Мартта – кем кала артта? да
Тел төбеннән төшмәгән.

Халкыбыз – шундый шул безнең
Ул бик оста эшкә дә,
Аның тарихи байлыгы
Югалмас бер төштә дә!

Ия ул зур көчкә дә!

## КАР СУЫНДА АГЫЗА

Искечә дә менә җитте
Яз башлана иртәгә,
Бик шатланып, канат кага
Әтәч менгән киртәгә.

Тавыклар да чыркылдашып
Калган карны тырмыйлар,
Йомыркаларын салалар –
Кыенсынып тормыйлар.

Яз җитүен бар да сизә
Мөгери сыерлар да,
Көтү чыгуын көтәләр –
Йөрергә болыннарда.

Яз көннәре җылы, матур
Тамчыларын тамыза,
Тормышның бар мәшәкатен
Кар суында агыза!

## УЙНАП-КӨЛҮ

Иң озын – өченче чирек
Бүген менә соңгы көне,
Тигезләште озынлыкта
Вакытның да көне-төне.

Төннәрнең бар караңгысын
Узып бара якты көннәр,
Язның җылылыгын тоеп –
Чәчәк атар матур гөлләр!

Урман-кырлар яшәрерләр
Яшел юрганнарын киеп,
Кәккүк бирер үз хәбәрен –
– Су керергә мөмкин! – диеп.

Табигать – зур көчкә ия
Кирәк безгә – аңлый белү,
Аның чисталыгын саклап –
Ял да итү, уйнап көлү!

## ЯШЕРМӘ!

Кешенең бар сере – күзләрдә
Кайчан ул ачыла йөзләрдә,
Син аны каплама, яшермә –
Калдырма яшертен сүзләргә!

Эчкерсез елмайса күзләрең
Гел якты була бу йөзләрең,
Тормышта уңышың зур булыр –
Нык булыр баскан бар эзләрең!

Сиңа да елмаеп карарлар
Дөрес, бар эшләрең ярарлар;
Ихтирам, хөрмәттә яшәрсең –
Рәхмәтле булырлар балалар.

Йөзләрең гел шулай ал булыр
Бәхеттән елмаеп, ул торыр;
Нык белем алган бар балалар –
Киләчәк тормышка эш корыр!

## ХАЛКЫҢНЫ СӨЯРСЕҢ!

Яшьлектә шаярып
Син “чәчәк атасың”,

Юл ярып барырга –
Гел алга басасың!

Намуслы күңелең
Һәрвакыт гел алда,
Зур эшләр үтәлә –
Булганда син анда.

Кешегә бирелә
Яшьлек бит бер генә,
Чәчәгең саф булсын –
Сулмасын гомергә!

Кешелек һәм намус
Яныңда булганда,
Таралыр томаннар
Ачылыр юллар да.

Киң юлдан атларсың
Чөнки саф күңелең,
Сөярсең халкыңны –
Булса нык белемең!

## ЯШЕЛ ТӨС

Мартның да бит җитте
Иң соңгы атнасы,
Кыш кына бирешми –
Бик озакка тартасы.

Карын да яудыра
Өйдерә көртләрне,
Бу карлар һәм бозлар –
Тиз генә бетәрме?

Табигать бик серле
Аның үз рәвеше,
Яудырган карлары –

Үсемлек өлеше.

Бу карлар тиз эреп
Аларга бирер көч,
Бар кар да эрегәч –
Ачылыр яшел төс!

Яшеллек һәм хөрлек
Яшәргә көч бирә,
Гел шулай булуын –
Аның да син телә!

## УҢАЙСЫЗ

И гөрли, үзгәрә тормыш
Табигать тә тик тормый,
Көн саен бик күп кар ява –
Каяндыр аны "урлый"!

Аяк аслары бик начар
Кешеләр – тая, егыла;
Яшьләр сикереп тора да
Тагын алга "ыргыла".

Карт-коры, әби-бабайга
Йөрүләре уңайсыз,
Сикәлтәле бозлы юлдан –
Аяк атлау – бик җайсыз.

Алар искә гел алалар
Яшь һәм көчле чакларын
Урамнарның чиста, тигез –
Уңайлы вакытларын.

Гомерләр шулай икән шул
Картлык килә бар җиргә,
Биш-ун метр атлагач та –
Тешәсең кара тиргә.

## БӘЙГЕ

Зур бәйгедә катнашалар
Өч безнең укытучы,
Укучыларга күп еллар –
Алар белем тукучы.

Дәрестән тыш эшләрдә дә
Катнашалар тырышып,
Ил күләм ярышларда да
Алда алар – узышып!

Соңгы этап ярышта да
Телибез бары бәхет,
Зур җиңүләрне колачлап –
Урыныгыз булсын тәхет!

## ҮТКӘННӘРГӘ – ХАТЛАР

Гомер үтә, дөнья уза
Кигән кием – бик тиз туза,
Узган көннәр, айлар, еллар –
Тормыш сукмакларын суза.

Гомер уза, мин яшь һаман
Бүгенге көн – яшьлек сыман,
- Халкыма ни эшләргә! – дип
Киләчәккә төзелә план.

Үткәннәргә борылып карыйм
Тормыш сынауларын саныйм, –
Юк бирешмим картлыгыма –
Һәрчак тырыш булып калыйм!

Алда әле күп эшләрем,
Өлгермәсәм, мин нишләрмен,
Авылым тарихын ачам –

Һәм язмышын бик күпләрнең

Шуны аңлыйм, әле һаман
Үткәннәргә хатлар язам,
Тирә-якка нурлар өстәп –
Яңгырады матур азан!

## УЙЛА ЭЛЕК!

Кеше килә бу дөньяга
Гомерләр бит бер генә,
Шул вакытта яшә кылып –
Бары изгелек кенә.

Кеше бит ике яшәми
Юлларың булсын туры,
Ышанычлы булсын һәрчак –
Дуслар, якыннар кулы.

Бары бер гомер булса да
Эшлә бик күп изгелек,
Ышанычлы син менәрсең –
Таулар булса да биек!

Гомерләр – килми ул ике
Теләсәк тә без үзгә,
Кыл яхшылык һәм изгелек
Карамый, берни сүзгә!

Гомерләр килсә дә бер кат
Яхшылык ул – мәңгелек,
Кешегә борчу салганчы –
Яхшылап уйла элек!

## КҮТӘРЕРГӘ – ОНЫТМАСКА!

Узганнарны, дисең, оныт
Булмаса да кара болыт,
Үткәнне без – киңәйтәбез
Бары изге теләк кылып!

Оныт инде, дисең кабат
Җилпегәндәй ап-ак канат,
Иртәнге саф таң җилләрен
Юллагандай, безгә карап!

Бу саф җилләр бит элек тә
Оча иделәр биектә,
Кирәк тоя, сизә белү –
Кайчак башларны иеп тә.

Үткәннәрне кирәк безгә
Күтәрергә – онытмаска,
Яшәү өчен сафлык биргән
Табигатьне корытмаска!

## САГЫШ ТАМЧЫСЫ

Көз җиткәч, коела җиргә
Яфракларның барысы,
Моны тоя, күрә белсәң –
Яфрак – сагыш тамчысы.

Көздән соң, килә кышлары
Бар табигать йокыда,
Ә син уяу һәм сизгер бул –
Төшеп батма чокырга!

Яз җиткәч бит, чокырга да
Кар сулары тиз тула,
Ул суларны эчеп үсеп –
Чәчәкләр калкып чыга.

Язның матур табигате
Түгел – сагыш тамчысы,
Көтүче көтү чыгара
Бил бавында камчысы.

Камчыны шартлатып кую
Нәрсәнедер аңлата,
Бар тереклек сизә, тоя –
Менә тиздән таң ата.

## ӘТИЛӘР КӨНЕ

Дөнья үзгәрә
Кермә – сүзгә дә,
“Әтиләр көне” –
Якын безгә дә.

Без дә ир-атлар
Танып дөньяны,
Бу көн булуны
Белдек бит тагы.

Моңа кадәр бит
Без көнсез идек,
Дөресен әйткәндә –
Бер сүзсез идек.

Дөнья үзгәрә
Бәлки безгә дә,
Сүз ирек кайтыр –
Нык бас – тезләнмә!

“Ир-ат баш!” – дигән
Сүзгә элгәре,
Көлеп карадык –
Тирән – серләре.

Дөрес, күп җирдә
Ир-ат гел ул баш,
Авыр йөк тарту
Йә булдыру аш.

Хатын-кызны да
“Муен” дигәннәр,
Ләкин муенга –
Баш бит көйләнгән.

Муен үзенчә
Бора һәр якка,
Кайчак бит башка –
Эләгә таш та!

Эчтә ул муен
Иң җылы урын,
Җил-буран да юк –
Йомшак шул куен.

Ә баш гел тышта
Җәен дә, кыш та,
Бик матур сайрый –
Сүз әйтмә кошка!

Ул бик матурлап
Өстә сайрады,
Сузылды муен –
Аны карады.

Шулчак, кошка да
Йомышы терәлде,
Ул канат җилпеп –
Барысын көйләде.

Үтәлгән йомыш
Атылды аска,
Һәм килеп төште –
Тагы шул башка.

Муенга нәрсә
Ул – берни сизми,
Бары матурны –
Күрә һәм күзли.

Шулай дусларым,
Яшик гел бергә;
Юк-бар өчен дә
Кермәгез сүзгә!

## УКУЧЫБЫЗ ИЛНУР

Илнур Хөснетдинов безнең
Гимназия укучысы,“
Кул көрәше” бәйгесендә –
Зур үрнәк булып торучы.

Рәсәй күләм ярышларда
Ул катнашып, көч сынады;
Аңа каршы көрәшерлек –
Көчле куллар бик булмады.

Чистайда бит булды соңгы
Ярышның зур йомгагы,
Беренче урынны алды –
Укучыбыз Илнур тагы

Киләчәктә дә без аңа
Телибез зур уңыш, саулык;
Укуында һәм спортта –
Изге эштә һәрчак данлык!

## ТИКШЕРҮЧЕ ПЛАНЫ

Илебездә нигә безнең
Бу законнар һаман кире,
Язу өчен дәфтәр түгел –
Әйтерсең лә, кирәк "тире".

Бу сорауларның барысын –
Күп мәртәбә без күтәрдек;
Татарстан, Рәсәй буенча –
Ике конференция үткәрдек.

Уку елы дәверендә
Бик күп була тикшерүләр:
"Обрнадзор, пожарныйлар,
СанПин" – дигән "өшкерүләр".

Тикшерүгә алар килә
Тик эзләргә бары кимлек:
Документың бераз тузган,
Утың зәгыйф, бераз тузан –
Штраф сала! – әзер "җимлек".

Инде житте соңгы чирек
Имтиханнар алда тора,
Менә апрель аенда да –
Тикшерүче план кора.

Апрель ае тугызыннан
Бер атнага алар чыга:
"Хезмәт саклау", пожарные,
"МЧС"ы – бар да була.

Алар тагы нәрсә табар:
Нинди гаеп, нахак сүзләр;
Белем, тәрбия йортлары –
Авырлыктан ничек түзәр?

Ә ник хөкүмәт кайгыртмый

Миллəтенə ник юк ярдəм
Ике бинада укыйбыз –
Безгə кирəк бина – бердəм!

Хəер, ярдəм – ул юк нəрсə
Яхшы эшкə, намуслыга;
Кешелеклек юкка чыга –
Юл ачыла – намуссызга.

Арта һаман бик зур байлар
Миллиардларга хуҗа алар,
Алар бу зур гөнаһларын –
Дөньядан киткəндə аңлар!

Бар кылган намуссыз эшен
Тəмуг кочагында барлар;
Кешелеклек, намус кайтып –
Алсуланып атар таңнар,
Онытылырлар, борчу-зарлар!

## КАБАТ КҮЗЛƏРМЕН

Табигать тə матур
Елмая күзлəрең,
Ягымлы синең дə
Һəр əйткəн сүзлəрең.

Чəчəктə табигать
Болыны, кыры да;
Яңгырый бик матур –
Халкымның җыры да.

Йөрибез сокланып
Бу матур дөньяга,
Вакыт та тиз узган
Кояш та бит бая!

Бу гүзəл дөньяны

Мин кабат күзләрмен,
Матурлык эченнән –
Тик сине эзләрмен!

## БАРСКА ТИҢ

Тукай китте бу дөньядан
Бик күп күреп авырлыклар:
Ятим калу, ялангачлык,
Авыр тормыш күреп – ачлык!

Киткәненә менә быел
Булды инде гасыр тулы,
Гомер узган саен күренә
Аның булган чиста юлы.

Туган ягын бик яраткан
Чишмәләрен – табигатен;
Ул бик матур тасфирлаган –
Су анасын, шүрәләсен!

Туган телне олылаган
Аңа атап ул күп язган,
“И туган тел – матур тел!” дип
Аның данын бик зурлаган!

Дөнья күләм ихтирамлы
Нинди бөек шагыйрь бит син,
Язып калдырган иҗатың –
Горур барган Барска тиң!

## КАБАТ ЯУЛАР

Табигать тә инде арыган
Каеннарны сары сарган,
Булган яфракларын коеп –

Агачлар да тынып калган.

Бар табигать – үзенчә тын
Тик каяндыр – яңгырый моң,
Күңелләрне үзенә тарта –
Тереклек бик тыңлый, тып-тын!

Алар да бит нидер көтә
Кошлар оча өстә-өстә,
Саубуллашып туган яктан –
Еракларга очып китә.

Табигать бик матур шаулар
Сулар белән тулыр ярлар,
Кайткан кошларның тавышы –
Бар җирне дә кабат яулар!

## ЗУР БАЙЛЫК

Менә җитә көткән язлар
Табигатькә чыктым эзләп,
Бар җирдә дә карлар эри –
Каеннарны йөрим күзләп.

Алар инде уянганнар
Җир анадан көч алалар,
Ап-ак зифа гәүдәләрен –
Яшел яфракка маналар!

Үсеп чыгар чәчәкләр дә
Калып бара әз көннәре,
Тирә ягын чорнап алыр –
Каен җиләк, гөмбәләре.

Табигать ул – бик зур байлык
Безгә кирәк – аны аңлау,
Гаиләңне яраткандай –
Хөрмәт итү, аны саннау!

## ОНЫТМА

Үткәннәрне син онытма
Хәтерләүдән һич курыкма,
Узган көннәр бирсен рәхәт –
Изге эшең өчен рәхмәт!

Бар кылган изге эшләрең
Тамыр җәер, үсәр, ныгыр;
Алар шулай, киң таралып –
Тормышны ал-гөлгә маныр.

Без кешеләр – һәрчак шулай
Кылыйк һәр көн изге эшләр,
Дөнья шулай матураер –
Бәхетле яшәр кешеләр.

## МАТУР ЭЗЛӘР

Көзләр, йөзләр – моңсу күзләр
Күп сөйләп тә бетми сүзләр,
Табигатьнең һәр фасылы –
Алып килә матур эзләр.

Көзләрен күп байлык була
Бар урын да шыплап тула,
Йөзләрдә дә шатлык нуры –
Күзләр генә моңсулана.

Булса да күп эшләр, байлык
Күзләр моңсу – ничә айлык?
Көзләр, кышлар – узып китәр
Язлар җиткәч – кайтыр саулык!

Язлар узгач – килә җәй дә
Күп йокладың, син тор әйдә!
Бар матурлык һәм байлыкны –
Күрә алсын һәрбер бәндә!

## ТАРСЫНМА!

Син бүләк ит миңа
Бәхетнең олысын,
Тазалык, саулыкны –
Эш сөю бурычын!

Сәламәт, нык булсаң
Бар эш тә җиңелә,
Исемең макталып –
Чәчәккә күмелә.

Намуслы башкарсаң
Эшләгән эшеңне,
Һәр юлда табарсың –
Ышаныч кешеңне.

Син бүләк ит миңа
Елмаю карашын,
Чәчеңне җил сүтсә –
Матурлап тарарсың!

Сүзләрең чын булса
Җайланыр барысы да,
Күңелең киң булсын –
Тормыштан тарсынма!

## ӘНКӘЙ

Бер кайтмасам, әнкәй, бер кайтырмын
Әниләр бик изге зат безгә,
Дөньядамы, яки оҗмахтамы –
Без рәхмәтле һәрчак гел сезгә!

Дөньялыкта чакта, очар коштай
Вакыт табып, кайтып йөрибез,
Ә күз йомгач, якты дөньялардан –

Үрнәк итеп, сезне сөйлибез!

Бер кайтмасам, әнкәй, бер кайтырмын
Мәңгелек урының – бик җыйнак,
Сиңа атап язган соңгы котлау –
Шигырь юлларында бик тыйнак.

Уңган идең, әнкәй, син бик уңган
Бәйләү, эрләү, тегү эшенә;
Аш-суга да кулың оста иде –
Бар ризыкны тәмле пешерә.

Якты дөньялардан киткәннән соң
Урының булсын синең – оҗмахта,
Безгә биргән изге, нык тәрбияң –
Маяк булып барсын һәрчакта!

## ШӨКЕР АЛЛА

Шөкер Алла, барысын барла
Кылган эшнең яхшысын,
Тагы күп изгелеккә бир –
Саулык, көннең яртысын!

Шөкер Алла, шатлык барга
Башта белем, нык акыл;
Рәхмәтеңнән ташламыйча –
Гел шулай яхшылык кыл!

Шөкер Аллам, киләчәктә
Авыр эшләр башлама,
Игътибар, ихтирам кимеп –
Рәхмәтеңнән ташлама!

Шөкер Аллам, әле алда
Зур эшләргә планнар,
Бары изгелек эшләргә –
Туып торсын оланнар!

## ӨЛГЕ

Изге эшнең гел кирәк
Кечесе – олысы,
Анда бит кешенең
Чиста җан җылысы.

Һәр кылган изге эш
Ул үсә, зурая;
Аңламый калганнар –
Гел читтә моңая.

Моңаю булмасын
Дөньяны син аңла,
Булганда авырлык –
Бирешмә һәм җайла!

Тырышып үтәсәң
Бар эшнең изгесен,
Киләчәк тормышның
Бирерсең өлгесен!

## ҮРНӘК БУЛАСЫҢ

Карамадың күзләремә
Минем бу сүзләремә,
Бары яхшылыкны теләп –
Карыйм мин йөзләреңә.

Бу йөзләрең һәм күзләрең
Бирсеннәр гел ышаныч,
Башкарган бар изгелекләр –
Биреп торсын куаныч!

Карадың да күзләремә
Әйткән бар сүзләремә,
Бар авырлыкны да җиңеп –

Яуладың үрләрен дә.

Нык атлап барасың алга
Тәртиптә эшләр бар да,
Авырлыклар узар, китәр –
Алырсың әле ял да!

Ышанып, киләчәк көнгә
Син планнар корасың,
Узып булмас, дигән җирдән –
Бар суны да ерасың.
Үрнәк булып торасың!

## НЫГЫЙСЫҢ

Әйдә дустым, Аланга
Анда бит күп балан да,
Күрсәң халкын, табигатен –
Калырсың үзең дә анда.

Бик күп чиста чишмәләр
Барысы шуннан эчәләр,
Авылдан киткәннәргә дә –
Һәрчак искә төшәләр.

Туган авылым син – Алан
Үсә-ныгыйсың һаман,
Сине гел шулай ярата –
Синдә үскән һәр балаң.

## АҢЛАГАНСЫҢ

Бу сөйләшү безнең
Исеңдәме,
Әллә кергән кебек –
Төшеңәме?

Ничек булса-булыр
Аңлагансың,
Барыр юлларыңда –
Таймагансың.

Булган уңышларны
Әгәр саклый белсәң,
Зур киңәшләр белән
Төшләреңә керсәм.

Килер зур уңышка
Ышанычлар тагы,
Кайтыр бу гомернең
Таза һәм нык чагы!

## ГЕЛ ҮЗГӘРӘ

Язлардан мин
Өмет өзмим,
Көтеп алам –
Аны күзлим.

Кар эрүгә
Үлән чыга,
Һәм калышмый –
Умырзая.

Ераклардан
Кайта казлар,
Һәрберенә –
Якын язлар.

Бар кешеләр
Куаналар,
Бәхет теләп –
Юаналар.

Быелгы яз
Бик катлаулы:
Яңгыр ява –
Кары тагы.

Хәзерге законнар кебек
Табигать тә гел үзгәрә,
Һаман үзенчә ул эшли –
Карамыйча, бер сүзгә дә.

## ҖАН ҖЫЛЫСЫ

Мәктәпне ярата
Кечесе-олысы,
Алардан саркыла –
Бары җан җылысы.

Кешелек, тыйнаклык
Тәрбия һәм белем,
Бирә бар балага –
Гимназия безнең.

Әле яшь булса да
Ул бик зур танылды,
Бөтенрәсәй буенча
Грант та ул алды.

Бөтенрәсәй мактаулы
Китапка ул керде,
Каюм Насыйри медале
Аңа да бирелде.

Яшьлеккә карамый
Ул тырыш һәм уңган,
Җитмеш бер укучы –
Медалист та булган.

Сигезе инде фән

Кандидат иясе,
Тагы бит бишесе –
Якларга нияте.

Ел саен уңышлар
Балалар китерә,
Рәсәй һәм җөмһүрият
Буенча җиткерә.

Уңыш зур, бары тик
Тикшерү күп килә,
Иртәгә киләсе –
Тикшерү ни дия?

Ник соң бу тәртиптә
Яшибез без һаман,
Тырышып эшләгәч –
Кемгәдер бик “яман”.

Тикшерү – ул килсен
Эшләргә – тик ярдәм,
Эш хәлен дә белеп –
Ярдәм ит! – бер мәлдән.

Ундүрт ел узабыз
Ике мәктәп арасын,
Тик һаман тапмыйбыз –
Бу чыгу чарасын.

Үзгәрер заманнар
Милли телләр үсәр,
Белем һәм тәрбия –
Туган телгә күчәр!

## ХОДАЙГА РӘХМӘТ!

Рәхмәтлемен ходайга
Китергәнгә гел җаена,
Бар мәшәкать артта калып –
Килеп җиткәнгә маена.

Май ае ул – бик матур ай,
Чәчәктә бар үсемлекләр,
Укытучы, укучыга –
Кирәк бик зур түземлекләр!

Бердәм дәүләт имтиханы
Май аенда бирә башлана,
Күп ел алган белемеңне
Оныта күрмә, син ташлама!

Каушамыйча, ашыкмыйча
Бир җавапны һәр сорауга,
Документлар алган чакта –
Кала күрмә син елауга!

## КАРТЛЫК КИЛМӘС

Карамыйча, булуың кайда
Бәхет яусын юлларыңа,
Зур хезмәтләр башкарсаң да
Сөял чыкмас кулларыңа.

Бар изге эш – ул кирәкле
Бирсәң шатлык кешеләргә,
Синең эштән үрнәк алыр –
“Тулыр-тулмас” ишеләр дә.

Әгәр эшең бирсә уңыш
Кешеләргә бәхет, шатлык;
Олы яшьтә син булсаң да –
Килмәс кебек сиңа картлык.

## ТУАР ИРТӘЛӘР

Әгәр кеше кадерен белсә
Бәхет гөле – мәңге сулмас,
Изгелек кылып яшәсә –
Беркайчан ул – начар булмас!

Бар әле ул, бар дөньяда
Изге затлар, яхшы күңел,
Әгәр кешелекле булсаң –
Абынсаң да тору җиңел.

Дөньясы бит аның шулай
Юлда очрый еш киртәләр,
Алардан юлларны ачып –
Бәхеттән туар иртәләр.

## БӘХЕТ ГӨЛЕ

Һәркемнең дөньяда
Бәхете бар кебек,
Кайчакта – чәчәктә
Кайчакта – ул чүбек.

Калдырмыйк чүбеккә
Без аны нык саклыйк,
Атлаган бар юлда –
Абынмыйк, нык атлыйк!

Корытмыйк бәхетнең
Бу матур чәчәген,
Һәр вакыт онытмый –
Сулар да сип тагын.

Бу бәхет гөлләре

Таралыр – нык үсәр,
Буыннан-буынга
Шатланып ул күчәр!

## ҮЗ ӨЕМ

Үз өемдә – үз көем
Син моны аңла – сөен,
Һәр җирдә чисталык-пакълык
Миңа бик якын өем!

Үз өемдә – үз көем
Чәчәге дә мул үсә,
Булган бар изгелек, сафлык –
Кешеләргә дә күчә.

Үзегез дә беләсез
Бар да яхшы – куаныч,
Игелек эшләп яшәве –
Бар кеше өчен юаныч.

Үз өемдә – үз көем
Алмагачлар чәчәктә,
Саулык, тынычлык булганда –
Көн матур бигрәк тә.

Үз өемдә – үз көем
Өстә дә чиста кием,
Әгәр табигать бозылса –
Син туңма – ныграк киен!
Рәхәт тормышка сөен!

## БЕР КАРАВЫҢ ҖИТӘ

Күзләремә – бер каравың җитә
Күп нәрсәләр анда беленә,

Моңа кадәр белми, сизми торган –
Яңалыклар бар да күренә.

Табигатькә – без бит чиста килгән
Күзләр бит ул – яшәү көзгесе,
Башкарган эш һәм уй – хыялыңның
Ачылып китә кылган өлгесе.

Күзләремә – бер каравың җитә
Икенчесе – минем йөзләремә,
Бар изге эш башкарганда шулай –
“Колак сал!” – син минем сүзләремә.

## ТӨШКӘ КЕРӘ

Тикшерү дә килеп китте
Бар документ тәртиптә,
Чисталык һәм пөхтәлекне –
Инде тормыйм, әйтеп тә.

Ике бина да каралды
Бар җирдә тәртип, чиста;
Инде моннан да артыгын –
Булдырып булмый һич тә.

Тикшерүче дә канәгать
Шулай яхшы эшләргә,
Ничә еллар күп тикшерү –
Керә инде төшләргә.

## ГАРМУН СУЗАМ

Искә алып яшьлек, туган якны
Гармун сузып алам кичләрен,
Акрын гына бу моңнарга кушыла
Күңелдәге кайнар хисләрем.

Гармун суза, үзенчә моңлана
Кая калдың, минем яшьлегем,
Туган авылым матур табигате –
Яшь чактагы һаман да минем.

Яшел чирәм баскан урамнарың
Алар саклый яшьлек серләрен,
Әйләндереп алган ике тавың –
Без яулаган биек үрләрең.

Гармун сузып алам – яшьлегемә
Шул моңнарда сәлам мин салам,
Яшьлек узып, инде олыгайсак та
Гармун сузам әле мин һаман!

## РӘХМӘТЛЕБЕЗ

Бар авырлаклар җиңелә
Арта көчем, арта хисләрем;
Авыл урамнарын яңгырата
Тальян гармуннары кичләрен.

Бу көйләрдә безнең – халык моңы
Күргән афәт, борчу – сагышлар;
Бар авырлык тизрәк артта калсын –
Булмасын ла башка ялгышлар!

Гармун сузыла, моңлы көй агыла
Матур көндә аккан елгадай,
Табигать тын, бар кеше йокыда –
Зур бишектә яткан баладай.

Төнге матурлык та бик тиз уза
Ай да китә кереп офыкка,
Кояш нурлары да уяналар
Әтәчләр кычкыра һәр йортта.

Һәр көн шулай, матур ал таң ата
Бар чыкларын җиргә тарата,
Табигать ул – бик зур көчкә ия
Рәхмәтлебез аңа карата.

## АПРЕЛЬ УРТАСЫ

Быелның язы озак сузыла
Җитсә дә апрельнең уртасы,
Яңгыр сибәли, кар ява –
Бозылган быел яз ноктасы.

Булган кар югала әкренләп
Бар җир дә су белән туклана,
Игеннәр бик яхшы булырлар –
Артык күп запасны туплама!

Елмаеп уйнарлар сабыйлар
Шатланып ямь-яшел чирәмдә,
Язның бу – безгә зур бүләге –
Табигать үстергән үлән дә.

Шуңа, без кешеләр, яратыйк
Табигать – икенче җир ана,
Ул матур һәм чиста булганда –
Безгә дә бәхетләр юллана.

## ЙОЛДЫЗЛАР УЯНА

Аяз төндә йолдызлар уяна
Җемелдиләр күктә нур чәчеп,
Кайвакытта алар атылалар
Нидер әйтеп, нидер эндәшеп.

Җемелдиләр алар төн буена
Һәрберенең бар бит исеме,

Җидегән йолдыз – әнә чүмеч йолдыз
Исемендә аның җисеме.

Зур яктылык бирә күк йөзенә
Күп йолдызлы киек каз юлы,
Кошлар китә – очып кайта шуннан
Ул юлда бит йолдызлар тулы.

Алар җиргә якты нур чәчәләр.
Җемелдәшеп, нидер әйтәләр;
Йолдызлы бу матур төндә йөргән
Яшьләргә дә алар дәшәләр.

## УЙНА, ШАЯР!

Дөнья якты, саулык ташып тора
Күңел күтәп ала – биюне,
Син очырма, югала күрмәсен –
Бәхет кошы булган сөюне!

Ул кош синдә кабат канатланса
Яңа оя, яңа пар эзләп;
Син ашыкма, барысын төптән уйла
Бора алмассың аны – буш сүзләп.

Тормыш матурлыгын син аңлый бел
“Шөкерана” кыл бар муллыкка,
Артык нәфесләнсәң – югалтырсың
Төшеп калырсың зур хурлыкка.

Дөнья якты, бар табигать матур
Матурлыкны күрә-тоя бел,
Бәхет кошың янында булганда
Аңлаш, сөйләш – аның белән гел.
Уйна, шаяр һәм кычкырып көл!

## СИН ДӘ ИЯ

Күп кешегә бирелә мөмкинлек
Тормыштан ямь табып яшәр өчен,
Ялкауланма, үстер мөмкинлекне –
Югалтмыйча бөтен яшәү көчен!

Кылган эшең бирсә балаларга
Ныклы белем, кирәкле тәрбия;
Зур дәрәҗә, мактаулы исемнәр –
Алар алса, син дә моңа ия!

Синең кылган барлык ниятләрең
Чәчәк атса, бирсәләр җимешен,
Дөньяга бер килгән – бары бер кат
Тормыш бәхете белән яшәр өчен!

Шуны аңлап, яхшылык кылырга
Тырыш син булса да зур киртәләр,
Яхшы эшләр, изгелек сайланса –
Аяз, чиста атар бар иртәләр!

## ЯШИБЕЗ – БЕР ГЕНӘ

Бар кеше уңышка омтыла
Ә уңыш тиз килми – көттерә,
Ирешү өчен бу теләккә –
Күп көчне, саулыкны бетерә.

Шулай да, кешелек бирешми
Ул кора планнар – һәм үти,
Кайвакыт бик артык уйламый –
Хатадан зур байлык тиз "төти".

Күп яна илемнең байлыгы
Сәбәпләр табыла качарга,
Миллионнар, миллиардлар агыла –
Чит илне "яратып кочарга!"

Нигә соң үз халкым тир түгеп
Тапкан бу байлыгы юк була,
Рәсәйдә бар шул, күп андыйлар –
Намусын югалтып “котыра”.

Тик алар кызганыч, аңламыйм
Кыл изге эшләрне син менә,
Эшлә күп яхшылык, изгелек –
Яшибез җирдә бит, бер генә!

## ТОРМЫШ ПЛАНЫ

Һәр изгелек – күренеп торсын
Эшләрегез үрнәк булсын,
Бар бала да яхшылыкны –
Начарлыктан аера алсын!

Югалтмагыз кешелекне
Бу гадәт бит бик элекке,
Әйләнгән дөнья шикелле –
Кире кайтыр – ул өметле!

Өметләр – торганда ташып
Туры атла, нык-нык басып,
Сиңа бик күпләр ышана –
Авырлыктан калма качып!

Ихтыяр көчең нык булса
Ышанычлы, уяу торса;
Бар авырлык бик тиз узар –
Матур тормыш план корса!

## ТОРМЫШ ЧЫГАНАГЫ

Айкала сулар, чайкала
Чиләкләр мөлдерәмә,
Ялгыш суларыңны түксәң –
Белдермә беркемгә дә!

Кабат бар сулар алырга
Чиләкләреңне тутыр,
Арысаң сулар ташыганда –
Ял итеп ал, син утыр!

Шунда карарсың суларга
Алар бит чиста, затлы;
Җир ананың куенынннан
“Сиңа!” – дип, бик озак акты.

Тормышның төп чыганагы
Шул бит чиста суларда,
Тереклеккә көч бирәләр –
Эш сөючән кулларга.

## ГОМЕР ИКЕ КИЛМИ

Ике килми бит ул гомер
Изгелек кыл һәм өлгер,
Бар начарлыкны кылучы –
Явызлыкны ач, җимер!

Бар авырлык һәм явызлык
Себерелеп ташлангач,
Тормыш матур чәчәк атар –
Яңа баштан ашлангач.

Дөньяга туар сабыйлар
Сау-сәламәт, шат булып,
Намуслы тапкан байлыктан –
Табыннар торыр тулып.

И кешеләр, кешелеклек
Кайтсын безгә яңадан,
Ике килми бит ул гомер –
Бер туабыз анадан.

## БӘХЕТ КИЛӘЧӘК

Йөрәкне елата, күңелне сыкрата
Тормышның аяусыз көннәре,
Дөньяны селкетә, яшенен бөркетә –
Яңгырлы бу кара төннәре.

Иреннәр елмая, күңелләр моңая
Көннәр бит аяза – яктыра,
Дөньяда тынычлык, яшәсен чын дуслык
"Изгеләр кая?" дип тапшыра.

Бу дөнья көйләнә, артыгын сөйләмә
Дөреслек һәрвакыт җиңәчәк,
Дусларча дәшәрбез, бик яхшы яшәрбез –
Саулык һәм бәхетләр киләчәк.
Моны бар кеше дә күрәчәк!

## КАБАТ КАЙТТЫМ

Күрим дисәң минем сагышымны
Тап вакытны, хатлар алыш инде,
Көтмәгәндә, һич тә сизмәгәндә –
Авырлыклар миңа шулай инде.

Матур гына тормыш агышында
Акрын гына тирбәлеп барганда,
Дөньялыктан китеп – кабат кайттым
Мин күз ачтым йөрәгем талганда.

Үз күзләрем белән күреп кайттым
Һәм ишеттем фәрештәләр сүзен,
Күп сорауга, шулай, җавап алдым –
Аларның мин күрдем нурлы йөзен.

Язлар килде, очып кайта кошлар
Чәчәк ата яшел болын-кырлар,
Кешеләргә, дөньяны яратып,
“Яшәгез!” – дип алар сайрар, җырлар!

## ЫШАНЫЧЛЫ ЮЛЛАР

Авырлыклар килгән чакта
Ачылмасын ярагыз,
Сөйгән ярларыгыз белән –
Якын булсын арагыз!

Борчу-мәшәкатьләр бетеп
Чәчәк атсын тормышлар,
Һәрвакыт саулык, тынычлык –
Алып килсен язмышлар.

Алдагы язмышта булсын
Ак бәхетләр – зур уңыш,
Бар борчу да артта калып –
Бәхетле булсын тормыш!

Мондый тормыш алып килсен
Тынычлык – барыбызга,
Бары ышанычлы юллар –
Чыкканда алыбызга!

## ТОЗ САЛМА

Кил әле, кил әле яныма
Тоз салма, белмичә, каныма;

Барысын да чын дөрес аңлагач –
Тынычлык алырсың җаныңа.

Чынбарлык, дөреслек – ул шундый
Булмый бит аны һич яшереп,
Барысын да син үзең аңларсың –
Күп укып, тырышып һәм белеп!

Оешкан дөреслек кузгалса
Ачылыр чын тарих битләре,
Моңарчы беленде бик азы –
Үткәннең бары тик читләре.

Офыкта бик чиста таң атар
Бар борчу югалыр һәм батар,
Яшь буын, туачак балалар –
Ышанып, аякка нык басар!

## БИЧАРАДАН – ЮК ЧАРА

Йөрәк әрни, яна; никтер кабалана
Нәрсә булды миңа – һичбер белгән юк,
Һәрбер килгән хәбәр, өстән төшкән әмер –
Безнең башка бәрә – көн дә тук та тук.

Нишли бу замана, аңлы затлар кая
Камчылыйлар безне – уңнан һәм сулдан,
Белем һәм тәрбия калына гел читтә
Бу хокуклар һаман югала кулдан.

Әгәр онытсагыз, балалар законын
Макаренко язган – педпоэманы,
Алар бит сабыйлар – булмагыз сез дошман
Дөньяга чистарып, килегез тагы!

Мәктәп – төп үтәүче, бар эшкә ул әзер
Тикшерү дә бик күп – гел бу төп чара,
Мондый алым белән, эшләве бик авыр –

Юкка чыгаралар – ул шул бичара.
Бичарадан – юк чара!

## ЗИФА КЫЗ

Ай тугач, түгәрәк булып,
Төннәр якты һәм аяз;
Йолдызлар да җемелдиләр –
Җиргә килде матур яз.

Айда күренә зифа кыз
Ышанмасаң син кара,
Чиләк-көянтәсен асып
Ул суга кабат бара.

Җемелдәшәләр йолдызлар
Зөһрә йолдыз да шунда,
Киек каз юлы җемелди –
Кошлар да кайтыр юлда.

Алар шатланып очалар
Сагынулар – бик мулдан,
Һәр йолдыз да маяк була –
Адашмый алар юлдан.

## ЗУР ТАЯНЫЧ

Зур тарихларга ия ул
Сөекле халкым минем,
Олы галим-галимәләр
Тугандай якын синең.

Алар сызган буразнада
Тереклек ныгый – үсә,
Булган бар гыйлем көчләре
Буыннан-буын күчә.

Халкымның зур таянычы
Гыйлемлек һәм тырышлык,
Үткән тарихны ачуда –
Бик күп еллар тырыштык.

Тырышлык юкка кимтәде
“Җир ана” – серен ача,
Начарлык теләгән затлар –
Ояттан шүрли – кача.

Кыю халкың булганда бит
Яшәргә дә яшәргә,
Үткән буын тарихыңа –
Үз телеңдә дәшәргә!

## ЯШЬЛЕК КАДЕРЕ

Һәркем яшьлегендә
Күңелдә яз була.
Чәчәк аткан чакта –
Бәхеттән ул тула.

Яшьлегем чәчәге
Мәңгегә син саф кал,
Киләчәк буынга –
Бирерсең син – күп бал!

Гомернең чәчәге
Яшьлек ул – килә бер,
Заяга уздырма –
Һәр көннең кадерен бел!

Чәчәктән булырлар
Көткән саф җимешләр,
Яшьлекнең кадерен –
Белергә тиешләр!

## КҮГӘРЧЕН

Күгәрчен тынычлык кошы
Бәхет теләп гөрли гел,
Аның шулай тырышканын –
Син дә аңла, син дә бел!

Күгәрчен гөрлидер
Шатлыклар таратырга,
Бар кешенең якыны бар –
Иркәләп яратырга.

Күгәрченнең томшыгына
Җиз мәрҗәннәр үргән күк,
Ул кешеләр белән яши –
Яхшы теләкләре күп.

Күгәрченнең атлаулары
Биеп барган кыз кебек,
Яратып, аңа син җим бир
Шатланып эндәш, көлеп!

## МОҢСУ ЯЗЛАР

Сагынганда – язлары да моңсу
Таңнары да, никтер, сагышлы;
Очрашулар була – аерылышу
Күрәчәкме, әллә язмышмы?

Язмыштагы күрәчәкне алып
Салып куйсак янган учакка,
Бар борчулар янып, юкка чыккач –
Үзең дә керерсең кочакка.

Җылы кочак көче – ул шифалы
Калган борчулар да югала,

Саулык арта бара, ул үрмәли
Якты тормышка ул – юл ала.

Алган безнең юллар – туры һәм киң
Дөнья матурая, зурая;
Дусларыбыз да күп, эштә уңыш –
Беркем китмәс хәзер, бер кая!

## ЕЛМАЙ ҺӘМ КӨЛ

Бар башкарган эшкә йомгак ясаганда
Хыял утравына – коштай, мин очам;
Бар уңышлар өчен, биргәнгә бар көчең –
Күкрәгемә сине – хөрмәтләп кочам.

Бердәмлек һәм дуслык бергә яшәгәндә
Зур җиңүләр яулап, алар киләләр;
Авыр көрәшләрдә бирешми баруның –
Сәбәпләрен аның – һәрчак беләләр.

Гел шулай, бул аңлы, карамый кич-таңмы
Җидегән йолдызларны аера бел,
Бар укучы тырышып, имтиханын биргәч –
Аттестат алганда, елмай һәм син көл!

## ХОДАЙ ГӨЛЕ

Бакчабызда үсә безнең
Бер үсемлек – ходай гөле,
Ул үстергән саф яфраклар –
Миңа яшәү көче бирде.

Кипрдан кайткан үсемлек
Күп авыруга – ул саваплы,
Яфрагыннан чәй ясасаң –
Булырсың сау һәм җаваплы.

Яфракларын вакытында
Җыясың да киптерәсең,
Ел әйләнә чәен эчеп –
Җәйне искә төшерәсең.

## ЙОМГАК

Ак юл ачам оланнарга
Карамагыз бураннарга,
Тырышып белем алыгыз –
Мин дә булам һәрчак янда.

Бураннар ул уза – китә
Ә ак юллар ерак илтә,
Туган җиреңдә син нык тор –
Бәхет тапмас беркем читтә.

Читтәгенең читәне дә
Комачаулар итәгеңә,
Буш сүз сөйләп йөрүчене
Бары кара читтән генә.

Сүзең дөрес, чиста булса
Башкарган эш бирер файда,
Уку елы дәверенә –
Йомгак ясала бит майда.
Әйдә син дә, соңга калма!

## МАТУРЛЫК

Инеш ага, Мишә ага
Тау аша, Алан аша;
Язгы ташулар кушылып –
Сулары тулып таша.

Сулары чиста һәм йомшак
Бар шарлавык, чоңгылы;
Язын ташып, чыгар өчен –
Яннарында болыны.

Аның суларында йөзә
Үрдәкләр, кыр казлары;
Әрәмәләрендә үсә –
Карлыганы, баланы.

Тау итәкләрен дә каплый
Мәтрүшкәләр, җиләкләр;
Теләк һәм сабырлык булса –
Бик тиз тула чиләкләр.

Шундый байлык, матурлыкны
Туган авылым белгән,
Анда үскән ул – кызлары
Бар дөньяны иңләгән.

## ДУСЛЫК ҖЫЛЫСЫ

Урман-тауга, суларга бай
Туган авылым минем – Алан,
Саф сулы чишмәләреңә –
Мин сокланам әле һаман.

Монда яшәгән тереклек
Бар да хуҗа булып кала,
Урман докторы тукран да –
Тукылдатып, шулай ала.

Һәр ел коенырга инде
Вакыт килеп җиткәнлекне,
Күке хәбәр итә-саный
Исәп тота бар тәүлекне.

Сандугачларың да шулай

Матур итеп сайрый, көйли;
Кайчак ялкауланып яткан –
Куяннарны да бит тирги.

Шулай, дуслыкта яшиләр
Хайваннарың һәм кошларың,
“Дуслык җылылыгы” белән –
Бик тиз уза бар кышларың.
Рәхәт яшәгез, дусларым!

## КАЕН

Күп юл буйлап, озынча тасмадай
Каен бизи барган юлымны,
“Яшел чукларыңны иркәлим!” – дип
Каеннарга сузам кулымны.

Каен агачлары бигрәк матур
Себеркесе дә бит ни тора,
Аннан дөрес файдаланган кеше –
Киләчәккә планнар кора.

Бөресе дә аның бик саваплы
Дәвалый ул бик күп чирләрдән,
Аның суын эчеп, терелү өчен –
Кайталар бит ерак җирләрдән.

Каеннарны кирәк яратырга
Үстерергә, кирәк ашларга;
Себеркесе белән тирә яктан –
Бар чүпне дә себереп ташларга!

## МИШӘ

Мишә су буйлары ямьле
Ял итүләр күңелле,

Су коену һәм кызыну –
Саваплыгы беленде.

Табигать биргәч җылысын
Мишә ярлары тула,
Су дулкыннары кешене
Иркәләгәндәй була.

Мишә буйлап сузылган бит
Чәчәкле яшел болын,
Шул болыннарда йөриләр –
Җитәкләп улын-кызын.

Табигать ул – бигрәк матур
Аны кирәк аңларга,
Анда булган тереклекне –
Яратырга, саннарга!

## МУЛ УҢЫШ

Әллә быел бераз соңлады
Сайрый күктә сабан тургае,
Бар табигать матур чәчәктә
Май айлары ямьле бигрәк тә.

Басуларда гөрли техника
Алар эшли көнен-төнен дә,
Кызу хезмәт барган вакытта
Җәнлекләр дә ятмый өнендә.

Киләчәккә бар да өметле
Бу көннәрне алар озак көтте,
Ышаныч һәм намус йомгагын –
Һәрвакытта үзендә йөртте.

Дөнья тыныч, матур булганда
Һәр ел уңыш үсеп торганда,
Син борчылма, күңелсезләнмә –

Кор планнар, ятма, тор әйдә!

Изге планнарың үтәлер
Намус белән эшне башлагач,
Басуларда уңыш мул булыр –
Үз эшеңне белеп башкаргач!

## НУРЛЫ КАЗАН

Күп йокладың – тор, чык торактан
Казан балкып тора ерактан,
“Кол Шәриф”е өсти матурлык –
Халыкларга шулай татулык.

Зур тарихка Казан – ул ия
Мәчетләре күкләргә тия,
Анда бара матур төзелеш –
Йоклап калма, син дә керт өлеш!

Метросыннан да бит йөрибез
Бары мактап кына сөйлибез,
Республикам- минем Татарстан –
Аның башкаласы – нурлы Казан!
Гел яңгырап торсын – моңлы Азан!

## ФАЙДАЛАНЫЙК

Чыклар таңда җем-җем итә
Энҗе бөртекләредәй үзе,
Намуслы, саф кешеләрнең
Энҗе кебек чиста йөзе.

Таң чыклары – сәламәтлек
Аны аңлый белү кирәк,
Ялан аяк әгәр йөрсәң –
Аякларга бирә терәк!

Табигать зур көчкә ия
Аңлый белсәң – ул зур байлык,
Аның булган һәр тармагын –
Файдаланыйк, алыйк – саулык!

## ХАЛЫК ҖИТӘКЧЕСЕНӘ

Бүген Алишка җыйдылар
Монда була җыелыш,
Һәр көн эштән аералар –
Нинди соң бездә узыш?

Кем бара хәзер “алда?” – дип
“Кем кала икән артта?”,
Бар киңәшмә-җыелышта
Беләбез шуның хакта.

Мин килешәм, әгәр чынлап
Ярышларны күрсәләр,
Республика, Рәсәй күләм –
Җиңүләрне белсәләр.

Юк шул, без һаман уенда
Һаман акча эшләргә,
Ничек булса да халыкның
Кесәләрен “тешләгә”.

Уйлап чыгаралар шулай
Чын узыш, чын бәйгеләр,
Күпме вакыт һәм байлыкның –
Күккә очуын белмиләр.

Рәсәй бик зур һәм бик бай ил
Аның байлыгы шулай;
Кемнәргәдер бу байлыкның
Читкә агуы уңай.

Билгесез шул, кайчан килер
Чын акыллы хуҗалар,
Саклый белсәк бар байлыкны
Бетәр иде нуҗалар.

Һәр һөнәрнең үз вәкиле
Эшләсә үз эшендә,
Зур байлык һәм сәламәтлек –
Булыр иде кешедә.

Укытучы элеккечә
Бирсә ныклы тәрбия,
Яхшы белем һәм киңәшләр –
Бирергә бит ул ия.

Шулай, халык җитәкчесе,
Булыгыз нык акылда,
Һәр көн "уен" уйлап табып –
Калдырмагыз ялкында.
Уйлагыз ил хакында!

## ӨМӘ

Шәһәр күләм өмә көнен
Үткәрәбез иртәгә,
Авылдагы әтәчләр дә –
Иртә менәр киртәгә.

Мәктәп яны һәм бүленгән
Шәһәрдәге урамнар,
Чистарып, ялтырап кала –
Күп кеше моны аңлар!

Тиздән менә үсеп чыгар
Ямь-яшел үләннәр дә,
Сабый балалар уйнарлар –
Тәгәрәп чирәмнәрдә.

Барыбыз да тойсак иде

Күрсәк иде чистаны,
Пычыратмый, чүпләмичә
Яшәсәк иде тагы.

И кешеләр, бар табигать
Чисталык ул – зур байлык,
Хуҗасыз һәм җыйнаксыздан
Баш тартып, тизрәк айныйк.
Беркайчан читтә калмыйк!

## ТАШЛЫЙК

Су буенда йөрим, шагыр-шыгыр
Кая бассам да гел таш кына,
Алар яныннан мин киткән саен
Кабат кайтам, күңелем ашкына.

Бу һәр ташның бар бит үз язмышы
Күпме сулар юа аларны,
Бу язмышны белер, ачар өчен –
Зур галимнәр, белмим, туармы?

Кайберләре ташның – бар яктан да
Юыла бит салкын су белән,
Таш астыннан чишмәләр ургылып –
Агып торганын да мин беләм.

Шундый матур һәм зур көчкә ия
“Ташлык” – дигән Мишә су буе,
Елганың ар ягын биләп үскән –
Әрәмәсе дә бит бик куе.

Ул урында үсә – бик күп үлән:
Карлыганы, тәмле бөрлегән;
Авылдашларымның читкә киткәч –
Сагынып кайтуларын мин беләм.

## ЗУР ТЕРӘК

Гөл чәчәкләре бертигез
Матурлар бит барысы да,
Алда күп эшлисе эшләр –
Түз, йөрәгем, ярсыма!

Бу чәчәкләр, бар да шулай –
Су сипкәч елмаялар,
Әгәр игътибар кимесә –
Кибәләр, саргаялар.

Кеше гомере дә шулай
Чәчәкләргә охшаган.
Бертигез була туганда
Яши-яши “бушаган”.

Бушаганны тутырырга
Саулыгыбыз гел кирәк,
Һәрвакыт нык, көчле булып,
Бәхетле типсен йөрәк.
Ул безгә – бик зур терәк!

## АҢЛАТАЛАР

Көн кояшлы, дөнья тыныч –
Күбәләкләр очалар,
Үзләренчә, алар шулай –
Бар нәрсәне кочалар.

Аңлаталар матур очып
Язның, җәйнең асылын;
Ә күзләрен яраталар –
Тулы икмәк басуын.

Көн дә шулай тынычлыкта
Очып йөри күбәләк,

Без дә күрик табигатьнең
Матурлыгын бергәләп!

## БАЛАЛАР ГАМЬЛЕ

Ямьле Мишә буйлары
Җәелеп ага сулары,
Аннан, шулай, дымнар ала
Тирә-як басулары.

Басу-әрәмәләрендә
Тургайлар-карлыгачлар,
Дым-сулар якында булгач –
Күкрәп үсә агачлар.

Мишә елгасы бик ямьле
Чишмәләре дә тәмле,
Сулар кереп, уйнап үскән –
Балалары да гамьле.

Табигатьнең мондый матур
Елгаларын күлләрен,
Пычыратма һәм киптермә –
Һәрвакыт син бел ямен!

## ПЛАН КОРЫЙК

Җан тартмаса, кан тарта ул
Һәр кеше моны белер,
Туган җирне, халкыңны сөй
Бер күрешү – бер гомер.

Тормыш ул аккан дәрьядай
Бәргәли уңга-сулга,
Күп вакыт зур упкыннар да
Ясала тигез юлда.

Мондый упкыннарны алдан
Их, күрә алсак иде,
Чөнки аның зур афәте –
Үземә минем тиде.

Бәргәләнми, каударланмый
Бар авырлыктан чыгыйк,
Туган як кошларын тыңлап –
Тын гына басып торыйк.
Изге эшкә план корыйк!

## АМӘНӘТ

Сабан туе – чәчүдән соң
Иң беренче бәйрәм ул,
Тырыш игенчеләр кебек –
Син дә шулай – уңган бул!

Анда чабыша атлары
Йөгерә ир-хатыннар,
Алардан калышмас өчен –
Чаба малай һәм кызлар.

Чүлмәк вату һәм бау тарту
Көчле, уңганнар эше;
Аларның бар тырышлыгын –
Елмаеп карый кеше.

Катыктан акча эзләү һәм
Капчык киеп йөгерү,
Бу бәйрәмдә барысын күрү
Барысына да өлгерү.

Колга башына үрмәләп
Менүләрне әйт әле,
Сабантуй батыры булып –
Җиңеп алгач тәкәне.

Чәчү эшләрен башкарып
Уңышларга амәнәт,
Болар бар да халкыбызның
Күп гасырлык зур гадәт!

## ЯШЬЛЕГЕМ

Йөрәк яна, күңел ургый
Җилгә кушылып җырлый,
Җил басылгач ул да тына –
Әйтерсең, нидер уйлый.

Бу йөрәгем янар өчен
Каян соң утлар алган,
Әллә яшьлек учагыннан
Күмер очкыны калган.

Йөрәк яна, кабалана
Ул каядыр ашкына,
Яшьлек узган сукмаклардан
Кабат атлый, ярсына.

Бу йөрәкнең хис-тойгысын
Салып моңлы бер көйгә,
"Яшьлегем син – бер генәм!" – дип
Яшьлек җырларын көйлә!

## ГАРМУНЫМ

Кичләрен гармунны тартып
Моңнар сибеп йөримме,
Шул гармун моңнары ача
Күңелдәге серемне.

Аның һәрбер төймәсендә

Бик күп сер яшеренгән,
Бу моңнарны аңлаучылар –
Уздыра хәтереннән.

Кичләрен гармун моңнары
Авылны яңгырата,
Йөрәктә булган серләрне
Әкрен генә тарата.

Карадым күзләреңә һәм
Нур чәчкән йөзләреңә,
Гармунга кушылып әйтәм –
Ышан син сүзләремә!

Әкрен генә гармун уйный
Йөрәк моңын тарата,
Гармуным да матур моңда
Сер ачарга ярата.

Әй гармуным, гармуным,
Син яшьлегем сердәше,
Бу чакларны искә алып –
Тагын шулай эндәшче!

## ЗУР ТЕРӘК

Күп җирләрдә матур гына
Чишмә ага челтерәп,
Аның суын файдалану –
Саулык өчен зур терәк.

Халкыбыз бик борынгыдан
Бу фикергә ышанган,
Шуңа да чишмә тирәсе –
Бик пөхтәләп тышланган.

Саф чишмә суының шулай
Җир астыннан чыгуы,

Җир ана куенында булган
Сихәтләрне юуы.

Болар бар да кешеләргә
Биргән бит зур ышаныч,
Аның шулай булулары
Барыбызга да таныш.

Чишмә суы күтәрелеп
Улаклардан ул ага,
Ул суларны күргән кеше –
Бик теләп аны ала.

## СҮНМӘС ЯКТЫ НУР

Безнең яшьлек – ышанычлы яшьлек
Күп планнар анда корылды,
Туры барган бу ак юллар кисәк –
Көтмәгәндә кыек борылды.

Без яшь чакта ышанычлы иде
Каян кайтып – кая барсаң да,
Ышанычлы куллар терәк иде
Кайчагында аяк тайса да.

Ул вакытта дөнья үзгә иде
Якын туган кебек бар халык,
Көтүдәге барлык хайваннар да –
Кәҗә белән шулай ук сарык.

Ышанычлы өмет алда иде
Нык белемгә ачык ишекләр,
Тырышлык һәм тәртип, теләк булса –
Тормышка ашты барлык өметләр.

Хәзерге чор яшьләрнең тормышы
Әйтерсең лә, әзерләнгән тур;
Аның белән безне чагыштырсаң –

Безнең яшьлек – сүнмәс якты нур!

## ДАҺИ ҺӨНӘР

Узган гомер учагыннан
Күп сораулар миңа инде,
Учактагы зур очкынга
Тиңнәр идем яшьлегемне.

Көчле яшьлек учагыннан
Күп очырдык очкыннарны,
Кабынган шул очкын аша –
Үти бардык хыялларны.

Урта мәктәп тәмамлагач
Баянчы ролен башкардым,
Институтка да кереп
Югары белемне алдым.

Аннан белем бирдек шулай
Яшь буынга үзебез дә,
Тәрбия һәм белем биреп –
Без нык тордык сүзебездә.

Дөнья, тормышның юллары
Кабат вузга “ыргыттылар”,
Университет тәмамлап –
Яңа юл башын тоттылар.

Казан каласы чакырды
Һәм без чыктык кабат юлга,
Яшьләргә белем бирергә –
Китап-дәфтәр алып кулга.

Гимназияне җитәкләп
Бару өчен белем кирәк,
Уңыш, дәрәҗәң дә була –
Белмәгәннәр моны сирәк.

Шул рухта эшләп һәм укып
Аспирантура тәмамладым,
“Фән кандидаты” дипломын –
Тагын бер вуздан мин алдым.

Шулай гомер бик тиз уза
Укучылар хәзер үсте,
Фән кандидатлары булып та
Бик күбесе үсеп җитте.

Бар генерал, министрлар
Укытучы һәм юристлар,
Шәфкать туташ, игенчеләр
Ял бирүче чын артистлар.

Шуңа – безнең һөнәр даһи
Киләчәккә ул нык тамыр,
Аны үстер, тәрбиялә –
Ул гел шулай изге калыр!

## ЙОМГАКМЫ, КЕРЕШМЕ?

Якты хыял белән яшәде
Безгә кадәр буын бигрәк тә,
Алар сызган юлдан без барсак –
Кырау төшмәс безнең йөрәккә.

Ышанычлы аның юллары
Нык булгандыр шулай куллары,
Юлда булганнарны калдырмас –
Аңа якын кыз һәм уллары.

Без аңласак үткән буынның
Ул башкарган һәрбер үз эшен,
Чын дөреслек ачар күзләрне –
Читтә калмас анда бер эшең.

Тигез юлның да бар чокыры
Кемдер чыккан аны сикереп,
Кемдер төшкән аягы таеп –
Кемдер узган аңа төкереп.

Без белмибез, ничек аңларга
Мондый хәлләр чынлап дөресме?
Начарлыкка кайчан чик булыр –
Бу йомгакмы, әллә керешме?

## БӘХЕТ ИҢӘ

Яшьлек килә – уйный, көлә
Бу соң озакмы сузылыр,
Картлык килә – тузгый, сүгенә
Бар хыяллар бозылыр.

Яшьлек дәрте – шаяруга
Кайчан нокта куела,
“Яратам, сөям!” сүзләрен
Кайчан әйтү тыела?

Яшьлек ул – картаймый бер дә
Әгәр күңелең яшь булса,
Сиңа елмайган кешегә –
Күзләрең көлеп торса!

Бар күңелең чиста булса
Калырсың син һәрчак яшь,
Олы яшькә карамыйча
Булырсың якын иптәш.

Яшьлекнең аның чиге юк
Картлыкны ул тиз җиңә,
Яшь күңелле булып калсаң –
Бар бәхет сиңа иңә!

## АЧУ БАСЫЛЫР

Кеше язмышы – ул бик катлаулы
Күп вакытта аптырап калабыз,
“Якты булсын!” – дип кабызган нурда –
Көрәш утларында янабыз.

Бу нурның бит кирәклеген белә
Алдынгы карашлы булганнар,
Ләкин нурны сүндерү эшенә –
Кайберәүләр кереп тулганнар.

Кеше язмышы да, тормышы да
Дулкынланып куя күп чакта,
Нур балкышы әгәр кими төшсә –
Утын өстә кабат учакка!

Җылылыгын, яктылыгын тойгач
Бик күпләрнең күңеле ачылыр,
Туган телгә каршы булган фикер –
Юкка чыгар, ачу басылыр!

## АҢЛАРЛАР

Комсомол ул – якты киләчәккә
Ярдәм итте, якты юл ачты;
Ә намусы, тәртибе булмаган –
Була алмады – еракка качты.

Бик зур көчкә, тәрбиягә ия
Комсомолны да бит яптылар,
Илгә тәртип, көч һәм ярдәм биргән –
Тамырларын аның чаптылар.

Комсомол ул – якты яшьлек иде
Күп батырларны ул тудырды,
Илгә каршы килгән дошманнарны

Ярдәм көче белән кудырды.

Комсомолда үсте күп даһилар
Гагариннар, Җәлил, Туфаннар;
Аларның тормышын якты белгән –
Күп кешеләр мине аңлarлар.

## ТЕЛӘКТӘШЛЕК ТЕЛИ

Авыл урамнары бушый
Җылылык юк, күңелдә туң;
Яшь, матур вакытны уйлап –
Моңнар түгә – ялгыз гармун.

Һәр сәдәбе аның серле
Нидер әйтә, нидер көйли;
Үз гомерендә күргәннәрне –
Яшь буынга-ача, сөйли.

Авыл урамнары да бит
Хәзер башка, хәзер үзгә;
Бу моңнарга кушылмыйлар –
Ышанмыйлар һәрбер сүзгә.

Төнге авыл өсләренә
Сибелә җыр, гармун моңы;
Гармун тели – теләктәшлек
Булмасын ул гармун – соңгы!

## КЕРФЕК ОЧЛАРЫННАН ТАМАЛАР

Илдә барган авырлык, хәлләрне
Җиңеләйтеп сөйләп – ябалар,
Борчу күргәннәрнең болар барысы –
Керфек очларыннан тамалар.

Ходай бирсә иде саулык, муллык
Кеше йөрәгенә тынычлык,
Шулай матур тормыш булсын өчен –
Гомер буе күпме тырыштык.

Акыл биреп түрә-хуҗаларга
Яшибез бит бары бер кабат,
Кешелекле һәм акыллы итеп –
Ходаебыз аларны ярат!

Аңлый алса барлык җитәкчеләр
Каян килеп – кая барганны,
Бәхет килер көннәрне каршылап –
Көтеп алырбыз без таңнарны.
Бик көтәрбез кабат язларны!

## ИЗГЕЛЕК ӨЧЕН КӨРӘШ

Күп гасырлар барысын күреп торган
Ерактагы якты йолдызлар күк,
Яхшылык һәм начарлык нияте корган
Җир йөзендә андый кешеләр күп.

Йолдызлар да, шулай, мәңгелек түгел
Кайчан да бер атыла һәм сүнә,
Кешеләр дә яшәү дәверендә –
Йә яхшылык кыла, йә тиз түнә.

Атылганчы һәм сүнгәнче йолдыз
Җемелди гел якты нур чәчеп,
Без дә, шулай, барысын дөрес аңлап –
Яшик җирдә бәхет өләшеп. Изгелек өчен гел көрәшеп!

## СҮЗ БИРӘМ

Күктә булган йолдызлар шикелле

Җирдә дә бит матур чәчәкләр күп,
Чәчәкләргә комачаулык иткән –
Бар чүпне дә җыеп, чокырга түк!

Йолдызлар бит алар яктырталар
Юл күрсәтеп, читкә китмәскә;
Чәчәкләр дә шатлык өләшәләр –
Абынмаска – кире чикмәскә!

Бу күк йөзе һәм җир йөзе матур
Мәңге бергә яшиләр шулай,
Саф һава һәм чисталык булганда –
Очрашалар алар бик уңай.

Җир йөзеннән – күк йөзенә оча
Очучылар – бик күп кунаклар,
Күк йөзеннән дә бит күренгәли –
Килгәләп китүче “җайдаклар”.

Барсак-кайтсак, килсәк-китсәк тә без
Эш-хыяллар булсын изгедән,
Йөзләр тыныч, күңелләр шат булып –
Елмаеп торсыннар көзгедән.
Шулай яшәргә мин – сүз бирәм!

## ЙӘ-ЙӘ

Мин шаярам, уйныйм; Сөям-көләм
Сезнең яктан искән җилләр белән,
Алар бит саф, чиста һәм бик рәхәт –
Шуңа да мин аның – кадерен беләм.

Җилгә карата бит – төрле караш:
Кайсы мактый аны, кайсы сөя;
Ә кайберсе аның хикмәтеннән –
Газаплана, арый, утта көя.

Тормыш шундый, табигать тә шулай
Йә елмая, көлә; йә бик борчый,

Кеше күңеле дә – аңа бик хас
Йә ул кешелекле, йә йөрәкне “кашый”.

Җилләр искән якка мин еш карыйм
Тирә-якта ничек икән хәлләр,
Әкрен генә искән талгын җилдән
Килерсыман миңа – изге хәбәр!

## ҖИЛ ИРКӘЛИ

Әкрен генә йомшак, талгын җилләр исә
Ал нурларын чәчеп, кояш күтәрелә;
Табигатьнең матур, хозурлыгын тоеп –
Һаваларда очып, кошлар бөтерелә.

Бу бит, бик зур бәхет, аңлаганга
Тирә-якның матурлыгын тою,
Шул матурлык аша – күңеленә
Чисталык һәм сафлыкларны җыю.

Табигатьнең шулай, уянганын
Син тоярга бары – өлгер генә,
Аларны мин тоеп һәм күзәтеп –
Гел юаныч табам – күңелемә.

Күңел булганны да алар сизә
Җил иркәли сыйпап – чәчләреңнән,
Кояшның һәм җилнең – иркәләве
Беркайчан да чыкмас – хәтереңнән!

## ИЛҺАМ ЧИШМӘСЕ

Бар кешегә туган ягы якын
Барыбызга серен чишәсе,
Ял итүләр яхшы туган якта
Без торган җир – илһам чишмәсе.

Чишмәләре – аның бит саф сулы
Тамчылары – көмеш тәңкәдәй,
Бар кешегә саулык теләп ага
Барыбызга газиз әнкәдәй.

Туган як ул – якын бар кешегә
Кирәк аның кадерен белергә,
Аны саклап, яклап бар афәттән
Матурлыгын кирәк күрергә!

Туган ягыңда син яланаяк
Әгәр бассаң газиз җиреңә,
Сабый чагың кабат исеңә төшәр
Сагынып кайтырсың гел илеңә.
Тынычлык алырсың күңелеңә!

## НӘРСӘДЕР СӨЙЛИЛӘР

Табигать тә тыныч, урамнар да бик тын
Тальян гармун минем иңемдә,
Без уйнап һәм җырлап, нык биеп тә алдык
Бер тирбәлдек яшьлек илеңдә.

Бар җир дә тын калган, әйтерсең моңланган
Ишетеп бу матур көйләрне,
Ай да бит елмая, күрәсең моңая
Нур белән яктыртып өйләрне.

Матур моң тарала, сагыштан арала
Кими бит яшьлегем дуслары,
Аларны сагынып, каядыр ашкынып –
Сайрады таңның да кошлары.

Кошлар да бик матур, моңнарын сузалар
Нәрсәдер әйтергә телиләр,
Теләп бар кешегә – тынычлык, иминлек
Бик матур җырларын көйлиләр.

Үзенчә, нәрсәдер сөйлиләр.

## МАТУР СӘЛӘТ

Узган гомер, үткән вакытларны
Искә алып йөрим – хәзер көн дә
Матур тавыш – чишмәнеке килә
Аның суын эчеп – үстек бергә.

Армый, талмый – ул челтерәп ага
Кешеләргә суын бирә шулай,
Бу суларны рәхәтләнеп эчкәч –
Бар эшне дә башкаруы уңай.

Аның тавышында челтер-челтер
Күп вакыйга, кеше авазлары;
Вак ташларга бәрелеп, чыңлап китә –
Әйтерсең очалар, киек кыр казлары.

Бу чиста суларда – чагыла кешенең
Күп гасырдан килгән – изге гадәтләре,
Күпме карт-корыга чишмә суы ташып –
Изгелек эшләгән – матур сәләтләре.

## ТАРСЫНМА

Барлык эч серемне, әйтеп бетергәнне
Син бит тыныч кына, никтер көтмәдең;
Хәзер уйланасың, күзләреңне текәп –
Ниләр сөйли икән – бу керфекләрең.

Керфекләр – күзләр дә, озын сүзләр дә
Аңлатып бирерме – боларның барысын да,
Син хәзер тырыш та, заманны орышма –
Иркен ул бу дөнья – барысына тарсынма!

Барысы да көйләнер, сөйләгән – сөйләнер,
Таш – ташка бәрелгәч – ут чыга,
Берәүләр тормышта “лыгырдап” яшиләр
Күп сөйләп алар да “тынчыга”

## КЕШЕ БЕЛӘ

Кеше йоклый, кошлар сайрый
Җәйге көн бу – кыска төн,
Озын көндә күп эшләгәч –
Аюга да кысан өн.

Язның-җәйнең һәрбер көне
Туйдыра диләр елны,
Шуңа да каты эшлиләр –
Кырыкка бүлеп кылны.

Утырталар, үстерәләр
Сукалыйдар, казыйлар;
Үсеп җиткәч игеннәрне –
Иркәлиләр, назлыйлар.

Игенчегә үзе үстергәч
Кадерле бу – барыннан,
Ел буе бит хезмәт керә –
Башлап тоткан карыннан.

Көзен җыеп алып барысын
Тутыргач амбарларга,
Кирәк урын басуларда –
Барлык яуган карларга.

Дөнья шулай көйләнгән ул
Кешеләр моны белә,
Хезмәт уңышларын күреп –
Шатлана, уйный, көлә.

## ОЛЫ ТОРМЫШ

Яңа тормыш корган чакта
Һәр парда алтын йөзек,
Үбешәләр, елмаялар –
Йөриләр ялкын кебек.

Чәчәкле, матур туй узгач
Кунаклар китә чыгып,
Чәчәк атып торган яшьлек
Узган күк хәзер тузып.

Узса да яшьлек – “Юләр чак”
Олы тормыш башлана,
Булган матур хисләреңне –
Син югалтма – ташлама!

Моны раслап, күп көттерми
Туар сабый балалар,
Сиздерми дә бу вакытлар –
Бик тиз артта калалар.

Шулай гомер бик тиз узып
Алар да үсеп җитәр,
Сез таккан кебек балдаклар –
Алар кулына күчәр.
Тот бокалыңны, күтәр!

## РӘХМӘТЛЕБЕЗ

Табигать уяна бара
Үләннәр баш калкыта,
Чүпләр тамыр җәя алмас
Кыш буе тик ятып та.

Бар җирне бик чистарталар
Урамнар матурая,

Көн саен кояш җылыта
Йөрер юл такырая.

Очып кайткан сыерчыклар
Керәләр өйләренә,
Матур итеп сайрашалар
Сокланып көйләренә.

Бар җирдә чисталык, пакълык
Балкып тора урамнар,
Бик тырышып эшләделәр –
Укучылар – оланнар.

Без аларга рәхмәтлебез
Өлкәннәр дә аңлагыз,
Шешәләрне ташламагыз –
Чисталыкны санлагыз!

Тарткан тәмәкегез белән
Мактанмагыз күплеккә,
Тартмый калган төпчекләрне –
Ташлагыз тик чүплеккә.

## АРТКА КАЛМА!

Язлар җитте, көннәр матурая
Юллар ачыла бара карлардан,
Матур сайрап, тавышларын биреп –
Кошлар очып кайта юллардан.

Алар да бит, нидер аңлаталар
Канат кагып, серләрен чишеп,
Киек казлар кабат эндәшәләр –
Канатларын киереп ишеп.

Алар да бит, чапкан тулпар аттай
Ашкыналар туган якларга,
Бар кошлар да – матур, бик файдалы

Аларны гел кирәк – сакларга!

Кошлар табигатькә – бик файдалы
Корткыч бөҗәкләрдән чистарта,
Аларга син оя – тиз ясап куй –
Бу чарада калма һич артта!

## РӘХӘТЕН КҮР

Матурлыгын тоеп табигатьнең
Сулар булып шулай агармын,
Күңеленә бары сихәт биреп –
Чык тамчысы булып тамармын!

Иртә тамган бу чык тамчылары
Җемелдиләр чиста көмештәй,
Вакыт-вакыт йөзләрең елмая
Бүлеп биргән кебек өлештәй.

Аккан сулар – алар кире кайтмый
Ярлар ташып, сулар басса да;
Айлар, еллар да бит кабатланмый –
Кыңгыраулар каты какса да.

Узган айлар һәм бу еллар бирсен
Киләчәкнең ныклы нигезен,
Тырыш хезмәтең һәм уңышларның –
Рәхәтен күр, һәрчак син үзең!

## КҮККӘ ТИЯ

Менә елның да иң матур
Вакытлары килеп җитте,
Чиста сулы зәңгәр күлгә –
Ике аккош килеп төште.

Алар бик сагынып килгән
Кайтышлары ерак юлдан,
Исәнләшкән кебек килеп –
Ризыкны алалар кулдан.

Аларга да бик кадерле
Туган якның табигате,
Кешегә дә моны аңлау –
Яшәешнең төп хикмәте.

Барыбыз да моны аңлыйк
Табигать – зур көчкә ия,
Туган якка кайткан саен –
Башларыбыз күккә “тия”!

## СУДА КОЕН!

Елның да бит матур ае –
«Чәчәкле май!» килеп җитте,
Көздән чәчкән игеннәр дә
Яхшы гына үсеп китте.

Чәчәкле май айларында
Мишә буйлары бик ямьле,
Чиста суда уйнап үскән –
Балык шулпалары тәмле.

Игътибар белән карасаң –
Мишә – синең суың тулы,
Сине сагынып кайткангамы –
Аккан суың да бит җылы.

Әйе, һәркем сагынып кайта
Туган җирен, кергән суын;
Бар җиреңә – сихәт бирә –
Коен әйдә, суда юын!

## ИРТӘ ӘЛЕ

Язның җылы иртәсендә
Еракларга китәсең дә,
“Хәлләр ничек?” – дип сорыйсың
Кызыксынып, кайчак син дә.

Язның җылы иртәләре
Табигатьнең киртәләре,
Кайчан көннәр салкыная –
Яшелчәгә иртә әле.

Матураер көннәре дә
Аяз булыр төннәре,
Җир ана җылылык алгач –
Бакчада бул элгәре.
Куанырсыз сез дә әле!

## МАТУР ДӨНЬЯ

Ходай дөньяга яратып
Эштән аермам дигән,
Изге эшләр башкарганда –
Кулны каермам дигән.

Һәр изге эш агач кебек
Тамыры үсә- ныгый,
Җил-давыллар да куркытмый
Авырлыкка ул чыдый.

Бар авырлык вакытлыча
Йомшак җил аны куа,
Булган борчу, мәшәкатьне –
Җылы яңгырлар юа.

Елмаеп, ал нурын чәчеп
Иркәләп, кояш чыга;

Җирдә тырышып эшләсәң –
Бар дөнья матур була!

## ҖӘННӘТ БАКЧАСЫ

Ак кар яуган кебек бакчабыз
Капланган бит ап-ак чәчәккә,
Алмагачы, чия, баланы –
Һәм башкасы матур бигрәк тә.

Хуҗа булып оча картлар да
Бар чәчәкне алар тикшерә,
Балын җыеп, серкәләндереп –
Бары байлык кына китерә.

Табигать бит шулай көйләнгән
Кирәк аны бары аңларга,
Җирдә үскән бар үсемлекне –
Тереклекне кирәк санларга.

Бакчабызда йөрим шатланып
Әйтерсең бу җәннәт бакчасы,
Чишмәсеннән алып су эчәм –
Бигрәк тәмле, гел-гел аксачы!

## ТАҢ КАЛЫЙК!

Хезмәтне дә ходай яраткан
Безгә кеше булып яшәргә,
Башкарган һәр изге эшеңә –
Һәрчак якын итеп дәшәргә.

Әй хезмәтем, син бит бик изге
Байлык, саулык, бәхет бирәсең,
Тәртип салып, булган җиреңдә –
Чәчәкләргә, гөлгә күмәсең.

Халкыбыз да безнең бик тырыш
Матурлыкны тоя, ярата;
Күпме әйтем, мәкальләр йөри –
Ул чыгарган моңа карата.

“Эш сөйгәнне, – ди ул – ил сөя!”
Ашыксаң – пешәрсең ашка да,
Кем тырыша – барысын булдыра
Кадагын кага ул ташка да!

Шулай дускай, хезмәт зур язмыш
Бик тырышып аны башкарыйк,
Язмыштан бит – юк диләр узмыш –
Уңышларга карап, таң калыйк!

## ҖИР АНА

Еракта, еракта
Ерак ай артында
Анда юл тапмады –
Әле бер батыр да.

Бары күңелем белән
Мин бик ерак очам,
Бар изге затны да
Иркәлим һәм кочам.

Галәмлек һәм дөнья
Ул бик зур бердәмлек,
Аны аңлый белү –
Сорый зур күндәмлек.

Кешелек тә аны
Кайчан да бер ачар,
Явызлык, нахактан –
Чын күңелдән кочар.

Зур намус, дөреслек
Юл ачар дөньяга,
Бар кеше бәхетле –
Ашкынмый һич кая.

Бар җирдә матурлык
Без күрә-тоябыз,
Бик матур, бик күркәм
Җир ана – оябыз!

## ХЕЗМӘТ КӨЧЕ

Яз килә миңа иртәрәк
Башлауга карлар эри,
Юллар ачам су агарга –
Карларны көри-көри.

Үсемлек, агачларга да
Карны бирәм җитәрлек,
Аннан алган күп дымнары –
Җәйгә дә бит китәрлек.

Яз килә миңа иртәрәк
Ә китә соңга калып,
Язның көне ел туйдыра –
Шуңа, бик эшлим, арып.

Язын ачыла бөреләр
Алар чиста, тереләр;
Алардан бәхет иңүен –
Бар кешеләр күрерләр.
Хезмәт көчен белерләр!

## ИСӘП-ХИСАП

Нинди илдә без яшибез

Авыр, искә алуы да;
Намуслы яшәве читен
Хәзер исән калуы да.

Бар җирдә дә исәп-хисап
Әйләнеп тора төймәләр,
Уты, суы, газына да –
Алар шулай көйләнгәннәр.

Дөрес булыр иде – әгәр
Күренгәнчә, без түләсәк;
Ләкин икеләтә сорап –
Алар гел-гел бит киләчәк.

Урамнарда ут күп яна
Кибетләрдә дә бар утлар,
Алар файдаланган утка –
Халык кесәсеннән чутлар.

Нигә илдә дөреслек юк
Ата-баба бит саклаган,
Күпме авырлыклар күреп –
Дошманнардан нык яклаган.

Юк шул, закон безнең башка
Яклаучылар үлеп бетте,
Исән булып яшәүчеләр –
Ил байлыгын хәйран сүтте.

Алар алды квартирлар
Машиналар да бирделәр,
Чөнки алар сугыш утын –
Читләтеп кенә йөрделәр.

Аңлый алмыйм, безнең илдә
Төпле фикер нигә сирәк,
Акыллы, намуслы булып –
Яшәүчеләр безгә кирәк.
Алар булыр иде терәк!

## БӘЙРӘМ

Килеп житте – тугызы да
Май аенда зур бәйрәм,
Һавага да “салют” оча –
Йөрибез әйлән-бәйлән.

Бик үзенчәлекле бәйрәм ул
Бар кеше көтеп алган,
Җиңү көнен җиткерүдә –
Күпләре башын салган.

Чын сугыш эчендә булып
Исән кайтканнары да,
Зур саулык һәм исәнлекне –
Калдырганнар бит анда.

Бу бәйрәм – бик зур афәтне
Җирдән себереп түкте,
Сугыш китергән дошманнар –
Үзләре дә тез чүкте.

Сугышта үлеп калганның
Хатыны, балалары;
Аларның гомер буена –
Йөрәкләре сызлады.

## ТУГАН ЯГЫБЫЗ ЯЗЫ

Бүген бит майның ундүрте
Искечә була – бере,
Шуңа да бит бар үсемлек –
Йокыдан торды – тере.

Алмагачлар да бөредә

Чәчәк атып киләләр,
Көннәр бозылып торса да
Яз җиткәнен беләләр.

Умарта кортлары гөрләп
Төрле якка очалар,
Язгы матур чәчәкләрне –
Иркәлиләр, кочалар.

Шундый матурлыкка ия
Туган ягыбыз язы,
Һавалардан очып уза –
Төркем-төркем кыр казы.

## ЯРАТУ СҮРЕЛМӘСЕН!

Алма бакчаларында йөрим
Чәчәк ата алмагач,
Һәр көн алар матурая –
Яхшы, салкын алмагач!

Әйтерсең, җәннәт бакчасы
Бакчабыз – матур, ямьле;
Анда үскән җиләк-җимеш
Бигрәк саф һәм бик тәмле.

Ямь-яшел чирәмнәрендә
Йөрү дә ялан аяк,
Сәламәтлек өстәү өчен –
Кирәкле бу – бер маяк!

Бу изге маяк утлары
Беркайчан да сүнмәсен,
Торган нигез, бакчаларны –
Чүп үләннәр күммәсен.
Туган нигез, туган якка –
Ярату сүрелмәсен!

## КАДЕРЕН БЕЛ!

Бар үсемлек яшеллектә
Кошлар сайрый шатланып,
Каен агачлары ямьле –
Бу күптәннән бик анык.

Иртә язын ул су бирә
Каен суы бик тәмле,
Саулык-сәламәтлек өсти –
Аның шифасы ямьле.

Язгы иртәнге бөресе –
Кайнатып эчкәч сихәт,
Аның аша дәвалангач –
Дөньяда яшәү рәхәт.

Себеркесен әйткән дә юк
Мунчада ул бирә көч,
Аның белән бер чабынсаң –
Бар авыру кача тиз.

Урам себеркеләрен дә
Каен агачы бирә,
Тирә-юньне себергәч тә –
Чисталык җиргә иңә.
Кадерен бел, шуңа күрә!

## ЯЛГЫШМЫЙК!

Елга ярсып ага
Карамыйча җәйгә,
Суы аның чиста –
Кулланалар чәйгә.

Бормалы-сырмалы

Аның агышлары,
Моң-җырларга охшаш
Чыккан тавышлары.

Күп кешеләр серен
Ул үзенә ала,
Белдерми башкага
Чоңгылларга сала.

Бу чиста елганың
Исеме бит – Мишә,
Күймәдә йөзәләр –
Ишкәк ишә-ишә.

Җәйләрен елгада
Без су кереп үстек,
Сай урыннан башлап –
Бик тирәнгә күчтек.

Тирәндә йөзсәк тә
Без бик ышанычлы,
Беркайчан батмабыз –
Ясамыйк ялгышны!

## АК КАЕННАР – КАРТ КАЕН

Туган авылым бакчасында
Ак каеннар инде – карт каен,
Һәр ел шулай, яшел яфракларда –
Каршылады алар май аен.

Ак каеннар үскән бу бакчада
Бик күп яшь парлар бит кавышты,
Ә көндезен алар басу-кырда
Зур хезмәттә эшләп ярышты.

Эштән яшьләр арып кайтсалар да
Кичләрен бакчага килделәр,

Татар моңы, гармун тавышында –
Аруларын бик тиз җиңделәр.

Төрле уен, матур зәлиләләр
Һаман да бит хәтер өлгесе,
Клуб бакчасында үскәнгәме –
Бу каеннар яшьлек көзгесе.

Күп үзгәреш, вакыйгалар булды
Зур янгыннан авыл сакланды,
Ләкин, бу каеннар ни сәбәптер –
Юк ителде, кисеп ташланды.

## ИЗГЕЛЕК – ҖИРДӘ ЯТМЫЙ

Һәр эшне дә башлаганда –
Изге булсын юл башың,
Изге эшләр үтәлгәндә –
Намус булсын – юлдашың!

Синең белән бергә йөрсә –
Намус ул – бик зур юлдаш,
Изге башкарган эшеңә –
Беркем дә киртә кормас.

“Изгелек – җирдә ятмый!” – дип
Халык бик дөрес әйткән,
Изге эшләр кыла-кыла
Яхшылыкны күбәйткән.

Яхшылык һәм җаваплылык
Кайтыр әле әйләнеп,
Намуслы, матур киләчәк –
Килер бергә бәйләнеп!

## МОҢЛЫ КӨЙ

Соң булса да утлар яна
Әллә кунаклар кайталар,
Кисәк-кисәк моң агыла –
Тальян гармун уйнаталар.

Моң бик матур, челтер-челтер
Әллә чишмә тавышлары,
Һәр моңда да халкыбызның –
Төрле авыр язмышлары.

“Шахталарга китәм!” – дисең
Якыннарыңны калдырып,
Анда күпме син торырсың? –
Йөрәкләрен нык яндырып.

Матур гына яңгырап ала
Әллүки һәм бәллүки дә,
Халкыбызның бар язмышы –
Ишетелә моңлы көйдә!

## ЧЫН КӨЗГЕ

Эшкә барам – эштән кайтам
Гел очырыйм аларга,
Матур итеп исәнләшәм –
Кыймыйм туры карарга.

Халкымның изге гадәте
Күзләр бит ул – чын көзге,
Ул гел тыныч, нык караса –
Тормышлар булыр изге.

Шул тынычлык һәм матурлык
Яшькә, чүпкә тулмасын;
Халкымның изге гадәте –
Сулмасын, югалмасын!

Кара күзләр, кара кашлар
Торсыннар гел елмаеп,
Онытма, матур сүзеңне –
Син дә әйт, җаен табып!

## КҮҢЕЛ КЫЛЫ

Гомер уза, йөрәк туза
Ник син иртә китәсең,
Ләкин яшьлек искә төшеп –
Күңел кылын чиртәсең.

Бу кыл бирә саф чыңнарны
Яшьлекне искә алып,
Нык басып бар, кыю атла –
Адашма читтә калып!

Ныклы адым – ул көч бирә
Йөрәкне җимсендерә,
Очраган бар авырлыкны –
Җимерә һәм иңдерә.

Йөрәкләр саф, нык булганда
Тиз картаймый күңелләр,
Намуслы, матур яшәсәк –
Озын булыр гомерләр!

## КАРТАЕРГА ИРТӘ ӘЛЕ

Яшьлек дуслар, сирәк очрашабыз
Дөнья мәшәкате катлаулы,
Телефоннар аша аңлашабыз –
Дуслык җебен өзми саклауны.

Яшьлек еллар, яшьли йөргән юллар

Бар кешегә газиз, якыннар;
Ул юллардан кабат атлаганда –
Яңгыраган кебек күп моңнар.

Яшьлек моңы, яшьлек җырлары да
Кадерле һәм якын күңелгә,
Студент еллары һәм егет чак –
Онытылмаслар гомер-гомергә!

Ул чактагы кебек эшләгәндә
Яшьләр безне куып җитәрме?
Башкарасы изге эшләр зурдан –
Картаерга безгә – иртә әле!

## ИРКЕН СУЛЫЙК!

Тәрәзәгә кемдер шакый
Әллә кеше, әллә кош,
Күп шакып та ачмасалар –
Озак ялынма, тот та оч!

Очкан вакытта күрерсең
Дөньяның матурлыгын,
Мул уңышлар үстерүче –
Игенче батырлыгын.

Батырлыкка бик күп хезмәт
Тир һәм тырышлык чыккан,
Ләкин аларның,уңышы –
Каядыр читкә очкан.

Очкан байлык һәм хөрмәтне
Без кирегә кайтарыйк,
Намуслы хезмәткә һәрчак –
Гел игътибарлы булыйк.
Борчылмый – иркен сулыйк!

## АЧ ТӘРӘЗӘҢ!

Ач тәрәзәң, керсен һава
Кояшның ал нурлары,
Бакчадагы агачларда –
Җырлаучы кош хорлары.

Саф һавасы – үзе саулык
Тәнең, җаның чистарыр;
Күңел яралары да тиз –
Төзәлер, төшеп калыр!

Кошларның матур җырлары
Йөрәгеңне ачарлар,
Начар, авыр уй-тойгылар
Күңелеңнән качарлар.

Ач тәрәзәң, син бикләнмә
Бик матур ул – табигать,
Күңелең саф, чиста булса –
Сиңа булыр зур хөрмәт!

## ЯШЕЛ КҮЛМӘК

Җир киенде яшел күлмәгенә
Бар табигать матурая бара,
Һәр агачның аткан чәчәкләрен –
Өере белән кортлар килеп сара.

Бу матурлык бер дә сүрелмәсен
Табигать гел калсын яшел булып,
Анда булган барлык елгалары –
Гел аксыннар чиста сулар тулып.

Яшел күлмәк – җиргә бик килешә
Пычыранмый – чиста ул саклансын,
Табигатькә авырлык килгәндә –

Кеше тарафыннан – ул яклансын!

Табигать вә кеше бер гаиләдәй
Ихтирам һәм игътибарга лаек,
Чисталык, тырышлык булганда –
Яхшы яшәр җирдә – барча халык!

## ТОЯ БЕЛҮ

Табигать тын, бар да йоклый тыныч
Күңелләрдә кайный, моңлы җырлар;
Ишетелми, алар бары уйда –
Тавышсыз соң аны кемнәр тыңнар?

Табигать бит ия, бик зур көчкә
Аны кирәк бары – тирән аңлау,
Анда булган көч һәм матурлыкны –
Тоя белү, ихтирамлап саннау.

Ул ия бит, бик зур көч-куәткә
Аны кирәк, бары күрә белү,
Анда уйнап, шатланып су кереп –
Бәхетеңне татып, көлә белү!

Моны белеп, әгәр без яшәсәк
Табигать тын, матур – бик озак яшәр,
Барысын күреп, киләчәк буын да –
Рәхмәт әйтеп, бары безгә дәшәр!

## САВЫМЧЫ АПАЛАР

Җәйләүләрдә көтү йөри
Төннәрен дә алар шунда,
Сыерлар телен аңларсың –
Яннарында бераз кун да.

Иртә таңнан уяналар
Әзерләнеп мул савымга,
Төп эшләре – күп сөт бирү
Көзен кайтырлар авылга.

Ерактан ук ишетәләр
Савымчы апалар килә,
Сыерлар да бик акыллы –
Аларның җырларын белә.

Шулай матур эшләгәндә
Яшәгәндә мул сөт өчен,
Сыерлар да бик тырыша –
Кызганмыйча булган көчен.

## ЧАЛГЫ ТАВЫШЫ

Матур тавыш ишетелә
Чапкан чалгы тавышы,
Әйтерсең, бик нык селтәнеп
Ерак китеп барышы.

Бу чалгы чапкан җирләрдән
Бик күп чалгылар үткән,
"Тагын мул булып үсик!" – дип
Үләннәр орлык сипкән.

Җылы яңгыр явып узгач
Кояш елмаеп чыга,
Иртәнге чык кипкәнче чап –
Чалгы бит моны тоя!

Ул омтыла һаман алга
Ярата нык эшләргә,
Сау сәламәт үсү өчен –
Бик кирәкле яшьләргә!

## СӘЛАМ СИҢА, ӘНИЕМ!

Сәлам сиңа, әнием,
Гел хәтердә минем,
Тәрбияви әйткән сүзләрең:
“Вакытында һәрчак –
Син ашап-эч, балам,
Саулык сирпеп торсын күзләрең!

Ашаган ат армый
Күпме эшләсә дә,
Авыр йөкләрне дә тартырсың –
Яхшы эшләр кылып,
Кешеләр шатлангач –
Ял иткәндә тыныч ятырсың!”

Синең сүзләр, әни,
Һәрчак хәтеремдә
Тормышымда якты нур кебек,
Гел билгесез эшне
Үти башлаганда –
Бисмилланы әйтәм мин элек!

## СОҢГЫ КЫҢГЫРАУ

Бүгенге безнең кыңгырау
Уку белән хушлашу,
Имтиханнарны тапшырып –
Тормыш белән дуслашу.

Мәктәп биргән аң-белемнәр
Таяныч булсын сезгә,
Сезнең уңышларыгыз гел –
Шатлык китерсен безгә!

Бердәм дәүләт имтиханы
Уңышлы тапшырылсын,

Бәхет үрләрен яуларга –
Юлларыгыз киң булсын!

## КҮК КҮГӘРЧЕН

Күк күгәрчен гөрлидер
Бу бит нидер аңлата,
Алар тыныч гөрләгәндә
Таңнар да матур ата.

Күгәрченнәр матур гөрләп
Балаларын йоклата,
Ата күгәрченнәр очып –
Ашарга алып кайта.

Тиздән үсеп, балалары
Шулай гөрләп очарлар,
Саулык һәм тынычлык теләп –
Канат җилпеп, кочарлар.

Күгәрченнәр бар кешегә
Бары бәхет телиләр,
Тынычлык, саулык һәм шатлык –
Теләп матур гөрлиләр.

## ҖИР ҖИЛӘК

Җәйге матур табигатьтә
Ял итүләр бик кирәк,
Бар җир матур һәм чәчәкле –
Тирә якта – җир җиләк.

Алар сине сокландыра
Бәхет, шатлык өләшә;
Авыртуы да тиз уза –
Кигәвеннәр тешләсә.

Шул җиләкләрне җыйганда
Бөгеләсең-торасың,
Иртәгә тагы килергә –
Зур планнар корасың.

Туган ягым табигате
Бик матур ул һәм бик бай,
Аңа кайтырга тырышам –
Туры килгән саен җай.

## ТОМАН

Табигатьнең үз фасылы
Иртә томан, кич томан;
Мондый иртә һәм кичләрен –
Юлга мин чыгып тормам.

Томан – табигать пәрдәсе
Вакытлыча томалый,
Тереклеккә күп нәрсәне
Күрсәтмичә торгалый.

Елмаеп кояш уянгач
Тормыйсың инде качып,
Аның нуры килеп керә –
Томан пәрдәсен ачып.

Кояш елмаеп карагач
Сабыйлар да уяна,
Бу матурлыкка сокланып –
Бар кеше дә куана.
Аңа карап, юана!

## ЮАНЫЧ

Элеккечә нык эшләсәң
Йөрәк никтер арадыр,
Бу инде шуны аңлата –
Гомер узып барадыр.

Узган гомергә үкенмик
Узсын ул тыныч кына,
Шаулап аккан елгалар да –
Агалар тынып кына.

Шул тынлыкны яңгыратып
Оныклар көлешәләр,
Башкарган изге эшләрнең –
Шатлыгын бүлешәләр.

Яхшы эшләп, узган гомер
Үзе бер зур куаныч,
Изге эшләр башкарганга –
Чиксез бәхет, юаныч!

## КӨЧ БИРӘ

Бала чагым чишмәләрен
Әле һаман сагынам,
Туган якка кайткан саен –
Алардан мин – су алам.

Хәтерләтәләр яшьлекне
Чишмә буйлары ямьле,
Күпме халык суын эчкән –
Сулары бигрәк тәмле.

Җир куеныннан чыккан чакта
Кисәк ул ургын куя,
Әйтерсең, аңа сокланып –
Карап торганны тоя.

Чишмә сулары шифалы
Кешегә ул көч бирә,
Кайткан саен суларын эч –
Булса да ара-тирә.

## КҮҢЕЛЕМ ТАЛПЫНА

Күңелем талпына – каядыр ашкына
Нәрсәдер ул көтә – сизенә,
Бу булсын бәхетле – киләчәк шаукымы
Бирсәңче, ходаем, тиз генә!

Алдагы тормышның – юллары гел якты
Бары тик уңышлар китерсең,
Озак гомер башкарган бу изге хезмәтем –
Киләчәк буынга көч бирсен!

Яшь буын яңача, яшәргә омтылып
Үстерсен меңьяшәр гөлләрне,
Бар кеше намуслы башкарган эшенең –
Рәхәтен татыган көннәрне.

Йөрәк тә җилпенә – бары тик сиз генә
Мул һәм бай тормышның килүен,
Тынычлык һәм саулык, бәхетле язмышның
Ил күләм һәркемгә иңүен!

## АТКАН АҖАГАН

Өстә кием ничек тузганы
Сизелмидер гомер узганы,
Бары изге эшләр башкарсаң –
Тиз басылыр – йөрәк сызлавы.

Гомер бит ул – аткан аҗаган

Йә сузыла озак, йә сүнә,
Кешеләр дә шуңа охшамаган –
Йә көрәшә белә, йә күнә.

Гомер узуы бик сизелми
Таң ата да була кич тагын,
Изге эшләр кылып яшәсәң –
Теләмәссең аның туктавын.

Таң атканда – атсын яктырып
Бар табигать булсын – ал нурда,
Анда яшәгән бар тереклек –
Изгелектә, саваплы юлда!

## СИБЕЛӘ ЧӘЧӘК

Табигатьнең – бар үз законы
Сибелә чәчәк – җилләр искәндә,
Каушамаска кыюлык кирәк –
Тирән елгаларны кичкәндә.

Сибелгән чәчәктәй тарала
Кешеләр дә “тормыш җиленнән”,
Диңгез-океаннарны ул кичә –
Ерак китеп туган җиреннән.

Чәчәк орлыклары сибелеп
Тамырланып кабат үсәләр,
Кешеләр дә зур бәхет эзләп –
Төрле җиргә шулай күчәләр.

Инде үсеп, өлгереп җиткәч
Сибелә чәчәк – җилләр искәндә,
Туган табигатьне сагынам –
Күп дусларны – искә төшкәндә.

## ТАБИГАТЬ МАТУРЛЫГЫ

Матурлыкка нык сокланып
Җиләк җыям тугайда,
Балаларын очыргалап –
Уйнап оча тургай да.

Матур тугай, мул җиләкле
Бар да пешеп өлгергән,
Безнең килеп җыячакны –
Әйтерсең, алар белгән.

Кызарып пешкән җиләкләр
Бик түбәнгә иелгән,
Шулай алар бергә бар да
Кызыл төскә киенгән.

Табигатьнең матурлыгы
Һәм муллыгы күренә,
Җылы яңгыр явып узса –
Зур байлыкка төренә.

## ОЗАК ИШӘЛӘР

Мишә яры якын, суы салкын
Зур балыклар каршы йөзәдер,
Сезнең белән монда – бер күрешү
Үзәкләрне бик тә өзәдер.

Учагы да матур, тәмле исләр
Дөнья матурлыгы искиткеч,
Бу пешергән аштан – авыз итү –
Хуш исләре дә бит исерткеч.

Безнең шулай, ел да бер күрешү
Һәрчак калсын кереп гадәткә,
Ел да туганнар бер, монда булыйк
Карамыйча, һичбер гайбәткә.

Мишә дулкыннары – чиста судан
Чөнки анда бик күп чишмәләр,
Бу суларга кереп коенганда
Колач салып, бик озак ишәләр.

## ТӘНГӘ – СИХӘТ

Мишә суларының бу сафлыгы
Тәнгә – сихәт, җанга зур файда;
Шуңадыр да аңа су керүләр –
Ел саен бит башлана майда.

Яр буенда булган комлыкларга
Судан чыккач, җәелеп ятасың;
Анда сулар кереп һәм кызынгач –
Саулык тыеп, өйгә кайтасың.

Мишә елгасы – бик чиста сулы
Кыр үрдәге, кызлар да йөзә,
Балыклардан – сазаны һәм сомы
Бик борчысаң – килә дә “сөзә”!

Иртә яздан – шул суларга кереп
Чумып, йөзеп-коенып йөрдек,
Табигатьнең матурлыгын тоеп –
Кирәклеген, сафлыгын белдек!

## АВЫЗ ИТИК!

Күңел чиста, намуслы бул
Һәрвакыт саф җил иссен,
Кимчелектән борчылмыйча –
Бит пешмәсен – ит пешсен!

Без пешергән тәмле иттән

Килеп тора хуш исләр,
Моны тойган, сизгән кеше –
Авыз итмәсә – нишләр?

Дуслар, туганнар җыелып
Күмәкләшеп утырып,
Рәхәтләнеп авыз итик –
Савытларны тутырып!

## ТУРЫ БУЛСЫН!

Менә без көткән җәйнең дә
Беренче ае җитте,
Кыш буе җыелган чүпләр –
Су белән акты, китте.

Табигать яшәрде, гүя –
Юрганын япты – яшел,
Ул да килүен белдерде –
Очкын уйнатып яшен.

Табигатьнең һәр мизгеле
Бик күп нәрсә аңлата,
Болытлап, озак яңгыр яуса –
Кояш – йокларга ята.

Ә яңгыр арып туктагач,
Ул бит кабат уяна,
Җирнең чиста, матурлыгын –
Күреп, бик тә куана.

Нурларын сирпеп уята
Чәчәкләрне йоклаган,
Каты яңгыр яуган чакта –
Бар машина туктаган.

Алар кабат хәрәкәттә
Чыктылар олы юлга,

Барыр юллар туры булсын –
Бормаланмый уң-сулга.

## ХӨРМӘТ

Кемдер уйный, гармун тавышы
Йөрәккә тиеп уйный,
Бу моңлы көйләрне тыңлап –
Күңелләр бер дә туймый.

Һәр көйнең бит үз язмышы
Үз тарихы – узганы,
Халкымның авыр язмыштан –
Борчылганы – тузганы.

И кошлар, сез бик ирекле
Туган якка очасыз,
Матур җырларыгыз белән –
Иркәлисез, кочасыз.

Кеше күңеле дә коштай
Оча бит бик еракка,
Аның да моң-сагышлары
Тарала төрле якка.

Челтерәп акка чишмәгә
Мин суга килгән идем,
Аның моңлы челтерәвен –
Ишетеп, белгән идем.

Челтер-челтер чишмә тавышы
Анда гомер агышы,
Бу сулардан авыз иткән –
Күп кешенең язмышы.

“Язмыштан – узмыш юк!” – диеп
Бик дөрес әйткән халкым,
Бу язмышны кичергәндә –

Чорнаган була ялкын.

Дуслар, якыннар булганда
Сүндерәсең ялкынны,
Мин хөрмәтлим авырлыкны –
Җиңеп барган халкымны!

## ХАЛКЫМ КҮҢЕЛЕ

Гармунда бит бик күп сырлар
Алар тату һәм бердәм,
Бергә тыңлап, тын калалар –
Кайвакыт, чыккан көйдән.

Һәр көйнең бит үз сулышы
Үз вакыты, үз моңы;
Кайчак тукталып ул кала –
Өзелгән кебек тыны.

Ләкин тынлык тиз ялгана
Моңнар ташкыны белән,
Бу моңнарны күп кешенең –
Нык яратканын беләм.

Анда кошлар авазы да
Чапкан җайдак тавышы,
Саф чишмә суында үскән –
Ямь-яшел саф камышы.

Халкыбыз бит нинди хисчән
Барысын күрә һәм тоя,
Табигатьнең бар мизгеле –
Аның күңеленә сыя!

## ИРКЕНЛЕК

Табигать тын, сулар тыныч
Йөзеп йөри балыклар,
Аларга хәзер иркенлек –
Юк бияләр, арыклар.

Сулары да бик тыныч, тын
Агалар бер җай белән,
Аның болай тын булуның
Сәбәбен дә мин беләм.

Элекке су тегермәне
Су утлары хәзер юк,
Беркем елгага кагылмый
Балыклар да шуңа тук.

Су төбе һәм ярларында
Үсемлекләр күп үсә,
Җирдә үскәннәре дә бит –
Әкренләп, суга күчә.

Балыклар йөзә шаярып
Чумалар, сикерәләр;
Елгада су эчеп торган –
Сыерлар үкерәләр.

Табигать ул – шундый иркен
Суы, җире – тереклек;
Аны сөю, саклау кирәк –
Без бит аңа беректек.

## КАНӘГАТЬ

Җәйнең бара матур ае
Тирә-як чәчәк, яшел;
Җылы яңгырлар яугалый –
Уйнаклап ала яшен.

Яңгыр узгач, чыга кояш
Җылы нурларын сибә,
Җыелып торган сулар да
Юк була, бик тиз кибә.

Ә агачлар һәм үләннәр
Киерелеп китәләр,
Кояшка, айга талпынып –
Гел югары үсәләр.

Һавасы саф, көннәр матур
Бигрәк ямьле табигать,
Аны саклап, чиста тотыйк –
Без бик аңа канәгать.
Безгә дә булыр хөрмәт!

## ҮЗЕҢ КАЙТ

Менә тагын җәйләр җитте
Менә бүген сабантуй була,
Туган якның күп кешесе –
Шатланышып монда җыела.

Кайт син, кайт син – үзең кайт
Мәшәкатьне тот та утка як,
Кайт син, кайт син – үзең кайт
Яшьлеккә бит – ачыла маяк.

Язгы хисләр – җәйге көндә
Сулганнармы әллә боегып,
Саулык булгач, яшим мин дә
Тормыш бәхетенә коенып.

Бу мәйданда карыйм сезгә
Бик күбегез таныш безгә,
Матур гына ял итегез –
Кызыллык китерми йөзгә.

## НӘТИҖӘ

Бердәм дәүләт имтиханы
Нәтиҗәләре килде,
Барыбыз да нык шатланып –
Яхшы узуын белде.

Иң түбән балл утыз алты
Булырга тиеш икән,
Кайбер укучылар балы –
Туксан бишкә дә җиткән.

Илле, алтмыш, җитмеш, сиксән,
Туксан баллар бездә күп,
Бары бер укучы эше –
Кырык баллда калган күк.

Татар мәктәбе булып та
Рус телен нык беләләр,
Күп мәктәпне узып барып –
Шаярталар, көләләр.

Егерме дүрт укучы да
Имтиханны тапшырды,
Аттестат алу баскычы –
Бер адымга яхшырды.

## НӘРСӘ КҮРЕРБЕЗ

Унбишенче июнь җиткәч
Математикадан да,
Күрсәткечләрне алырбыз –
Нәрсә күрербез анда?

Ходай кушып, бу фәннән дә –

Яхшы булып баллары,
Аттестатлар тапшыруы –
Бәхет бирер аннары.

Барысы да документ алгач
Уллары һәм кызлары,
Югары уку йортларына –
Ачык булыр юллары.

Мәктәп биргән ныклы белем
Аларга булыр терәк,
Яхшы акыл һәм тәрбия –
Һәрчак бирергә кирәк!

## ЗУР ТЕРӘК

Авыл сабан туйлары да
Гөрләде – матур узды,
Сыйныфташлар, якын дуслар –
Барысы да кулын сузды.

“Бер күрешү – бер гомер!” дип
Бик дөрес әйткән халкым,
Югалганнар искә төшә –
Кабынган кебек ялкын.

Бу ялкынны басар өчен
Дус-ишләр бит бик кирәк,
Бер-береңә ярдәм итү –
Безнең яшьтә зур терәк!

## АЙ КЕБЕК

Дөнья матур, саулык яхшы
Чәчәк үсә – җир кибеп,
Тормыш гүзәллеген күрә –

Йөзе тулган ай кебек.

Шул нурлы йөзләре белән
Бәхет өсти кешегә,
Кызарып пешкән җиләктәй –
Иреннәре төсе дә.

Күзләрендә зәңгәр күкнең
Чаткылары күренә,
Елмаеп, каршы килгәндә –
Кем икәне беленә.

Йөзең һәрчак булсын якты
Болыт каплый күрмәсен,
Кисәк, авырлыклар килеп –
Күз яшең түгелмәсен!

## КЕШЕ БУЛЫРГА КИРӘК

Без яшибез дөньяларда
Тирә-як яшел тирәк,
Яхшылык кылып яшәргә –
Нәрсә җитми, ни кирәк?

Тамаклар тук, өсләр бөтен
Муллыктан тулган өстәл,
Болар бар да юкка чыгар –
Күрсәтмә төшсә – өстән.

Тынычлыкның белеп кадерен
Бик тырышып эшләргә,
“Бары – бергә, югы – уртак!” – дип
Кеше булып яшәргә!

Туган ил һәм халык өчен
Никтер тырышу сирәк,
Чын бәхетне аңлау өчен –
Кеше булырга кирәк!

## УЯТЫЙК ӘЛЕ!

Күпләр аңлый алмаслык шул –
Кылып яхшылык, изгелек;
Уятыйк туңган күңелне –
Югалып бара – кешелек.

Бар иде кешенең – кеше
Булып яшәгән заманы,
Соңгы бер кабымны да бит –
Уртак бүлеп ашаганы.

Күп авырлыклар булса да
Җиңә алды – юлны ачты,
Бу вакытта бердәм иде –
Кешелексезлек тә качты.

Күп гасырлардан җәелгән
Дөньякүләм изге эшне,
Кабат торгызырга иде –
Уятыйк әле, кешене!

## БӘХЕТ ҖЫРЛАРЫ

Хәзер бик матур
Басу-кырлары,
Яңгырап тора –
Бәхет җырлары.

Бу басуларда
Яшьләр күп эшли,
Яраткан эшкә –
Ихтирам төшми.

Чөнки хезмәтнең
Яхшы асылы,
Табигатьнең дә
Язгы фасылы.

Кырыкка хәзер
Бүләбез кылны,
Язның бер көне –
Туйдыра елны.

## МАТУР ЯШИК!

Дөньялыкта яшик, эшлик
Елмаеп-көлеп кенә;
Башкарган изге эшләрнең
Кадерен белеп кенә.

Изгелекнең чикләре юк
Тарсынмый башкар әйдә,
Күп эшләп – авызың кипсә –
Һәрвакыт әзер чәй дә.

Татар балы белән чәе
Көч бирә тәнгә-җанга,
Туган тел, халыкка хөрмәт –
Үсә ул – сеңеп канга.

Үстереп һәм нык баетып
Сәнгатьне, телебезне;
Һәрвакыт дус, матур яшик –
Яратып илебезне!

## ТОРМЫШНЫҢ АК ЮЛЫ

Тормышта кылган эшебез
Бары изгелектән тулган,
Тәрбия, белем бирәбез –
Иман нуры безгә кунган.

Бу нурларны нык үстереп

Яшь буын барсын алга,
Изге эшкә исәп тотып –
Тукталган саен ялга.

Һәр елдан соң – иман нуры
Тагы да үссен, ныгысын;
Начарлык теләүче эшләр –
Башкарылмый – корысын!

Үсеп чыксын, мул тармактан
Бары изгелек нуры,
Нур астыннан баручының –
Юллары булыр туры.
Бу тормышның ак юлы!

## ЗУР ТЕРӘК

Тормыш матурлыгын тою
Саулык булу – зур терәк,
Бәхетле булып яшәргә –
Әти һәм әни кирәк!

Әти-әни исән чакта
Бик кирәк киңәшләре,
Балаларны яратуда –
Юктыр ла тиңдәшләре.

Дөнья матур һәм бик якты
Алар елмайган чакта,
Сау-исән булуын телә –
Гел кайтып туган якка.

Туган як ул – аңлый белсәң
Әти-әни кебек якын,
Җаныңа бирә җылылык –
Булганда да кайчак салкын.

## ҮЗ МОҢЫ

Айлы кичтә, һәрчак истә
Сайраша сандугачлар,
Алар җырына кушылып –
Тибрәнгәли агачлар.

Һәр агачның – бар үз моңы
Яфраклары тирбәлә,
Әкрен генә җил иссә дә –
Туктап кала бер мәлгә.

Алар шулай, үзләренчә,
Авазларын көйлиләр,
Табигатьтә ни барганын –
Әкрен генә сөйлиләр.

Табигать – зур көчкә ия
Аны кирәк аңларга,
Аның көчен, матурлыгын –
Яратырга, санларга!

## ТИҢ БУЛЫЙК!

Имтихан да бетте
Барысы да бик күркәм,
Авырлык җиңелә –
Тырышлыкта бердәм.

Өч алтын медальгә
Лаек без булдык,
Тырышып укыгач –
Имтиханда уңдык.

Баллар да югары
Бар туксан, йөзләр дә;
Шатлыклы елмаю –

Безнең бит күзләрдә.

Вуз ишекләре дә
Ачылсын безгә киң,
Белемгә, намуска –
Бәхеткә булыйк тиң!

## ИЯ БУЛДЫ

Тугызынчы сыйныф бүген
Мәктәп белән хушлашты,
Барысы да документка –
Ия булды, дуслашты.

Алда әле бик күп юллар
Кирәк сайлый белергә,
Алган тәрбия-белемне
Югалтмаска – төрергә!

Кайберләре нык җыена
Барырга техникумга,
Китәргә теләмәгәннәр –
Киләләр кабат унга.

Унда, унбердә укыгач
Ныгыр – белем, тәрбия;
Намуслы, тырыш укучы –
Барысы да моңа ия!

## ЕГЫЛМАССЫҢ

Иртән торгач, уң аягың белән
Бисмилланы әйтеп, бас аякка;
Шөкер ана кылып, эш башкарсаң –
Килмәс борчу, калмасын – таякка.

Башкарган эшләрең – булсын якты
Китерсен ул – бар кешегә савап,
Эшең һәм тормышыңда килешеп –
Якыннарыңны яшә син саннап.

Үтәгән изге эш, уңышларың
Озак көттермәс, килер ул елмаеп;
Һәр адымың ышанычлы булса –
Егылмассың беркайчан да таеп!

## ЮЛ БАШЫМ

Мәктәбем, белемем –
Син минем юл башым,
Алган бар белемем –
Гомерлек юлдашым.

Унбер ел мәктәптә
Өйрәндек бик күпкә,
Тырышып укыгач –
Калмадык без чүпкә.

Без медаль яуладык
Иң яхшы – алтынын,
Туган тел җырында –
Рәхмәтем, бар моңым.

Рәсәй күп ярышта
Безне нык сынады,
“Зирәк тиен” бәйгесе
Ике приз юллады.

Мактау дипломнары да
Безгә күп эләкте,
Белемгә омтылу –
Ярсыта йөрәкне!

## БАЛКЫРБЫЗ!

Дөнья матур, күңелләр киң –
Бердәм булып тотыныгыз,
Намуслы, күркәм хезмәткә –
Сез дә безгә кушылыгыз!

Башкарган изге эшең мул
Бирсә шатлык һәм юаныч,
Балаларга киң юл ачса –
Монысы бик тә куаныч.

Бу юлларны чүпләмичә
Бизәп бару уку-эштә,
Бар уңышка шатланырбыз –
Карамыйча ничә яшькә.

“Бер яшьлектә, бер картлыкта” –
Бик дөрес әйткән халкыбыз,
Һәрвакыт бик тырыш булып –
Изге эштә гел балкырбыз!

## АК КАЕН

Яфраклары яшел ак каенның
Бик күп җырлар аңа салынган,
Яшь парларның серле йөрәк хисе –
Күпләренең аннан алынган.

Яфраклары яшел ак каенның
Бу яфраклар барысын күрәләр,
Әкрен генә җилдә тирбәләләр –
Бик күпләрнең серен беләләр.

Ак күлмәген кигән бу ак каен
Яшел яулыгы да бик матур,
Язгы чорда аның суын эчсәң –

Сау-сәламәт, булырсың, батыр!

Яшел яулык япкан, ак күлмәкле
Бигрәк зифа, бигрәк күркәм бит,
Бер серне дә чишми ул ятларга –
Бар сереңне аңа ачып кит!

## БЕР ГЕНӘ

Тормышны аңламый йөрсәләр
Уфтанма, бары тик, көл генә;
Кешегә гомер бит бирелә –
Мең түгел, бары тик бер генә.

Кешегә бирелгән шул гомер
Бик күпне күрергә өйрәтә,
Дөньяда яшәргә теләсәң –
Алырлар, җибәрми, сөйрәп тә.

Үзеңә бирелгән гомерне
Син үткәр рәхәттә, муллыкта;
Дусларың булсыннар таяныч –
Борчылма, уфтанма бар-юкка!

Туп-тулы, тулган ай шикелле
Гомерләр бирелә түгәрәк,
Чын дуслар, иң якын тугандай –
Утыр син, оялма, түргәрәк!

## АЧЫЛЫР, ЧИСТАРЫР ДӨНЬЯСЫ

Әйтмә син авыр сүз, әйтмә түз
Тулса да кайчакта күңелең,
Аңласаң чын дөрес-хикмәтне –
Мин бит бер гаепле түгелмен.

Дөресне аңлавы бик авыр
Дөньясы шулайга куела,
Сакланган намус һәм чынбарлык
Тормыштан – сузыла, юыла.

Килер бу, кайтыр бу дөреслек
Күз буяу, алдашу югалыр,
Чынбарлык, намуслык шаукымы
Югалмас, һәрвакыт нык калыр.

Әйтмә син авыр сүз, әйтмә түз
Мин телим бары тик яхшылык,
Ачылыр, чистарыр дөньясы –
Булса да хәзергә ул тонык.

## ДӘШӘЛӘР

Туган якка кайткач, карап йөрим
Булган саен мөмкин ялларым,
Узган яшь гомердә утыртылган
Боек тора никтер, талларым.

Бу таллар бит җиргә – тамыр җәеп
Утыз елдан артык үстеләр,
Кайбер ботакларын малай-шалай
Уйнаганда кисеп киттеләр.

Карамыйча берни авырлыкка
Колачларын алар җәяләр,
Кышын ап-ак кардан, җәен җилдән
Безне саклап күлмәк кияләр.

Бу талларга шулай, бит төп хуҗа
Ренат абыйлары бар иде,
Намуслы һәм бик ярдәмчел кеше –
Күп еллар бит инде – ул үлде.

Аны югалтканга – боек таллар

Башын иеп нидер әйтәләр,
“Тыныч йокла, урының җәннәт булсын!”
Пышылдыйлар аңа дәшәләр.

## ҖИЛӘК ҖЫЮ

Без бардык җиләк җыярга
Кып-кызыл, бар да пешкән;
Күбесе инде кызарып –
Өлгереп җиргә төшкән.

Тезләнеп әгәр карасаң
“Кызыл чуктай” тирә-як,
Хуш исләре аңкып тора
Алданмассың, алып кап!

Җиләкләре дә бик матур
Тау итәгендә генә,
Ерак түгел Мишә ага
Шуңа да тәмле менә.

Бераз тырышып эшләгәч
Чиләкләр дә тиз тула,
Чишмәләрдән су эчәбез –
Кул-битне юа, юа.

Туган ягым табигате –
Шифалы һәм бик матур,
Ул үстергән ул-кызлары
Аны гел сагынып кайтыр!

## ТЫРЫШЛЫК БЕЛЕНӘ

Имтиханнарыбыз бетте
Укучылар өлгерләр,
Аттестатлар алгач алар –

Күп вузларга йөриләр.

Бердәм дәүләт имтиханы
Уртача балл югары:
Рус теленнән – алтмыш тугыз,
Сиксән биш балл инглиздән –
Булуын син бел тагы.

Теләп биргән фәннәрдән дә
Уңышлары югары: География җитмеш өч балл,
Биология алтмыш өч –
Яхшы булган баллары.

Тарих-җәмгыять белеме
Илле тугызга җитә,
Авыр фән – математика –
Илле биш узып китә.

Сигез фәнне сайлаганнар
Белемнәр нык бирелә,
Яхшы белгечләр булырлар –
Туып үскән илемә.
Зур тырышлык беленә!

## КҮЗЛӘРЕҢ

Күзләрең синең елмая
Йөзеңне күрмәсәм дә,
Якынлыкны сизеп торам –
Яратам, димәсәң дә.

Әй күзләрең, күзләрең
Кирәкми лә сүзләрең,
Аларның нурлы чаткысын –
Гомер буе эзләдем.

Дулкын сыман керфекләрең
Тибрәнгәләп китәләр,

Алар аша матур караш –
Үзенеке итәләр.

Күз карашың бик сөйкемле
Ай нурлары сирпелә,
Елмаеп, алар телиләр –
Бары тик бәхет кенә.

## УНИВЕРСИАДА

Дөнья Универсиадасы
Казанда үткәрелә,
Йөз җитмеш илнең флагы
Бездә бит күтәрелә.

Шимбә көнне без дә менә
Мәңгелек ут күрәбез,
Ярышларда кайсы илнең
Көчлелеген беләбез.

Ә кичен "Арена" инде
Яңадан безне көтә,
Егерме җиденче ярыш
Ачылу вакыты җитә.

Безнең ярышчыларыбыз
Көчләрен сынашырлар
Спортның бар төрендә дә
Көрәштә ярышырлар.

Дөньякүләм бу узышта
Телибез зур уңышлар,
Казаныбыз үсә-гөрли
Алда бик күп узышлар.

## БӘХЕТ НУРЫ

Елмаясың – йөзләреңдә
Кояш-айның нурлары,
Озын чәчле күркәм йөзләр –
Әйтерсең, хур кызлары.

Кояш батса – ай калка
Алар нурын тарата,
Ачык йөзле – күркәм кызны
Бар егет тә ярата.

Бигрәк күркәм – елмайганда
Битләрең чокырлана,
Бу вакытта егетләрнең –
Йөрәкләре гел “яна”.

Йөзләреңнән беркайчан да
Елмаюың бетмәсен,
Тулып торган бәхет нуры –
Чайкалып түгелмәсен!

## КОЛАЧЛАП ЙӨЗӘМ

Мишә елгасы чиста су
Күп чишмәләр кушыла,
Бу елгада су коенгач –
Арыганнар онытыла.

Аның ярлары да матур
Болыннары чәчәкле,
Күккә карап анда ятсаң –
Беләсең киләчәкне.

Елганың бар үз тарихы
Биек ярдай таулары,
Язларын ташып акканда
Туктатучы ярлары.

Күңелләргә син бик якын
Чиста сулы – тын Мишә,
Сиңа килеп мин бер йөзәм –
Колачлап, ишә-ишә.

## ЕЛМАЮ

Бар матурлыкны бирәсең
Күз карашларың белән,
Бер күз сирпүеңнән дә мин
Әйтер сүзеңне беләм.

Әй күзләрең, күзләрең
Моңсу гына сүзләрең,
Син гел елмай, сөйкемле бул –
Якты булсын йөзләрең.

Күзләреңдә кайчан күрәм
Иртәнге чык тамчысын,
Бу чыклар бит бик тиз кибә
Син күрсәтмә анысысын.

Йөзләреңдә, күзләреңдә
Елмаю тулып торсын,
Сине үрнәк итеп кеше –
Матур планнар корсын!

## ИРЕННӘР

Кызарып пешкәннәр
Җиләктәй иреннәр,
Әйтерсең мул булып –
Өлгергән игеннәр.

Булган бар иген дә

Кадерле кешегә,
Яхшылык кылганда –
Кысылма эшенә.

Елмаеп торганда
Бик матур иренең,
Тулган ай шикелле –
Бик чиста күңелең.

Яшь ай да көн саен
Зурая һәм тула,
Изгелек кылганнар –
Тормышта гел уңа.

Иреннәр һәрвакыт
Бәхетле елмайсын,
Изгелек бары кыл –
Аермый һич кайсын!

## ТЫРЫШ БУЛ!

Җәйнең уртасы да җитте
Кыскара бара көннәр,
Эссесе озак торганга да
Йомшак һәм җылы төннәр.

Әгәр кызганмасаң суны
Күп җиләк һәм яшелчә,
Аларны яхшы карасаң –
Мул уңыш биреп үсә.

Үскән, җыйган уңышларны
Яхшылап эшкәртәсең,
Ел буена җитәрлекне –
Кар базына кертәсең.

Яхшы базың әгәр булса
Ул икенче суыткыч,

Күп еллар анда саклана
Уңышка – тими корткыч.

Эшеңне белеп башкарсаң
Күңелең һәрчак тыныч,
Тәмләткеч кирәк булганда –
Төшеп аласың – борыч.
Ялкауланма, бул тырыш!

## ЕВРОПА КҮЛӘМ ШӘҺӘР

Иртәгә соңгы эш көне
Универсиада тәмам,
Зур уңышларга ирештек –
Кулга да алдым каләм.

Дөньядагы йөз алтмыш ил
Вәкилләре Казанда,
Матур гына ишетелә –
Яңгыраган азан да.

Башкалабыз – Казан безнең
Дөньякүләм танылды,
“Мәңгелек ут” ялкыны да
Анда матур кабынды.

Якты нуры белән бу ут
Илебезгә юл ачты,
Казаныбыз Европа күләм
Шәһәр рәтенә басты.

## “ШАЛТЫРАМА” ЧИШМӘСЕ

Чишмә – матур тау астыннан
Агып ята көнчыгыштан,
Бик күп еллар аның суын

Алан кызлары ташыган.

Суы тәмле һәм файдалы
Ашкынып ул – шаулап ага,
Аның суын эчкән һәркем –
Гел ашкына аңа таба.

Көчле матур тавышы белән
Ул күпләрне куандырган,
Аңа лаеклы исем дә
“Шалтырама” – дип кушылган.

Күп еллар тынычлап яткач
Аны кабат уяттылар,
Тирә-якларын чистартып –
Калайдан түбә ябтылар.

Мондый изге эш башкарган
Рәхмәтле без һәркемгә дә,
Чишмә суын эчеп узса –
Рәхәт яшәр бар бәндә дә.

## АВЫЛЫМ ЧИШМӘЛӘРЕ

Туган авылым Алан – бик матур
Чишмәләре бик күп авылның,
Чорнап алган таулар итәге –
Юлын каплап тора давылның.

Һәр чишмәнең бар үз исеме
Тарихы да шунда чагыла,
Көмеш кебек чиста сулары –
Мишә елгасына агыла.

“Чакрак тавы” чишмә сулары
Дәва биреп, искә төшәләр;
Аның суын эчкән кешеләр –
Авырмыйча, таза үсәләр.

“Хәтер чишмәсе”нең суы да
Хәтерләтә яшьлек елларны,
Якын узган сабан туйларын –
Яшьлектәге моңлы җырларны.

“Лагерь чишмәсе”нә килгәндә
“Пионер лагерь” – бары әйтемдә,
Анда алган белем, тәрбия –
Калды бик тә матур хәтердә.

## ЯКЛА!

Шаярасың, елмаясың
Кояш нуры йөзләрдә,
Тормышта көч, куәт бирә –
Синең әйткән сүзләр дә.

Әй нурлы йөз, татлы сүз
Яктыртасың дөньяны,
Син бик бәхетле булырсың –
Тик югалтма аларны.

Авырлыклар да җиңелә
Булса сөю билгесе,
Изге эшләр башкарганда –
Игелекнең өлгесе.

Бәхетле елмай гел шулай
Нур сибеп тирә-якка,
Яхшылык эшлә кешегә –
Борчылма аны – якла!

## ГОРУР ЙӨРТӘ

Әкрен генә, сизелми дә

Яңа уку елы җитте,
Дөньякүләм көчкә ия
Универсиада үтте.

Аны уңай үткәрүдә
Барыбызның көче керде,
Каршыларга һәм озатырга
Укытучылар өлгерде.

Волонтерлар да булдылар
Дөнья үзенекен итте,
Өч телне бик уңай белү –
Аралашырга өлгертте.

Дөньякүләм очрашулар
Әле безне кабат көтә,
Казан шәһәренең даны –
Аны шулай горур йөртә.

## ТИЗРӘК “АЙНЫЙК”!

Табигать быел бик сәер
Йә көн буе яңгыр ява,
Икенче көнне яңадан –
Көн буе кояш кыздыра.

Бер көнне булса көз ае
Икенче көн – күчә җәйгә,
Кешеләрне сынау өчен –
Табигать корамы хәйлә?

Аның да бар бит үз җае
Күп байлыклар ул үстерә,
Гөрләп үскән гөмбәләрне –
Мул табыннарга күчерә.

Табигатьнең һәр көне дә
Тереклеккә бирә байлык,

Пычыратмыйк – аны саклыйк –
Начарлыктан тизрәк айныйк!

## ТУГАН ЯК ҖИЛЕ

Җилләр исә – туган яклардан
Агымы да акрын һәм тыныч,
Нидер әйтә, нидер пышылдый –
Дөнья матур һәм бик мул тормыш.

Тыныч кына исеп барганда
Ул бит күрә – үзгәрешләрне,
Ярты гасыр элек башкарган
Үзе хуҗа булган эшләрне.

Җилнең тегермәне хәзер юк
Утлары да күптән өзелде,
Ераклардан килгән утларга –
Баганалар бик күп тезелде.

Җилләр исә – туган як җиле
Битләрне дә сыйпап китәләр,
Дөньялыкта кылган бар эшләр –
Әкрен генә искә төшәләр.

Һәркемнең дә узган юлында
Изге эшләр булу күңелле,
Яхшылыкны гел башкарырга
Җилкендереп тора күңелне.

## КОШЛАР ОЧА

Кошлар оча җылы якларга
Таныш була анда ятлар да,
Туган якка язын кайтырга –
Кирәк хәзер көчне сакларга.

Язлар җиткәч, бар да калкына
Туган якка күңел талпына,
Шатланышып кайта башлыйлар
Март аеның инде башында.

Бик тырышып коралар оя
Ояларга барысы да сыя,
Кошчыклары бар да үссеннәр –
Әнкәләре саклый һәм тыя.

Әткәләре дә бит бик өлгер
Иртүк оча – булса да эңгер,
Азык ташый ул оясына –
Барысын ашап бара бит кемдер.

Кошчыклар да тизрәк үсәләр
Канат үстерүгә күчәләр,
Бар кеше дә сокланып карый
Очканнарын әгәр күрсәләр.

## ЭШ БАТЫРЛЫГЫ

Менә җитте сентябрнең дә
Искечә бит тагы бересе,
Әбиләрнең чуагы бара –
Шуңа матур көннең күбесе.

Үсемлекләр әле ямь-яшел
Яшел юрган япкан өсләре,
Умарта кортлары да оча –
Ташып тора әле көчләре.

Кайчак китә яңгыр сибәләп
Сафландырып булган тузаннан,
Аннан кабат елмая кояш –
Бар тереклек бик риза аннан.

Табигать ул – зур көчкә ия
Һәр айның бар үз матурлыгы,
Аны бизи һәм нык үстерә –
Кешеләрнең эш батырлыгы.

## АКЛАНЫР

Тусак та без төрле җирләрдә
Яшәсәк тә төрле илләрдә,
Телебез һәм динебез дә бер –
Моңланабыз бер үк көйләрдә.

Динебез һәм телебез бөек
Бик даһи тел булган бит элек,
Зур шәхесләр аны белгәннәр –
Ә наданнар карыйлар көлеп.

Милләттәшләр инде уяныйк
Туган телгә хөрмәтләп карыйк,
Бөеклеген аның нык танып –
Бер сүзен дә югалтмыйк, барлыйк!

Туган сабыйлар да шатланыр
Ата-ананың нык булыр тамыр,
Тузан баскан өслек юылыр –
Дөреслек бит кабат акланыр!

## АКЛЫЙК

Яшьлек җыры, авыл урамнары
Барыбызга якын һәм изге,
Аны белеп, тоеп үскәнгә дә
Тартып тора – җибәрми безне.

Һәркемнең дә яшьлек хатирәсе
Сандугачлар тавышы колакта,

Ал таңнарның нуры, юеш чыклар
Калды инде бик тә еракта.

Авыл урамнары – сихри тынлык
Ник югалды гармун тавышы,
Матур җырлар җырлап һәм танышып –
Бик күп парлар шулай кавышты.

Яшьлек җырын, авыл урамнарын
Без онытмыйк – кадерләп саклыйк,
Безнең буын чоры истәлеген
Нык олылыйк – матурлап аклыйк!

## ШАТ ЕЛМАЙ

Синең бит әле
Әйтер сүзең бар,
Ә бу сүзләрне –
Күзләрең әйтә.

Болар барысы да
Бәлки әйтелмәс,
Аларның барысын
Күзләр төзәтә.

Кабат сизенәм
Синең сүзләр күп,
Алар бирмиләр
Тынычлык никтер.

Бу күзләреңнең
Керфек очлары –
Юешләнгәнне
Тизерәк киптер!

Менә күзләрең
Кояштай көлә,
Чын дөреслекне

Алар бит белә.

Гел син шат елмай
Борчылма юкка,
Аяк тайганда
Егылма, тукта!

## КӨЧЛЕ АВАЗ

Көчле аваз – мәңге аяз
Ул – туган тел авазы,
Аны мәңге саклау өчен
Халык тоя газапны.

Томалауга, бетерүгә
Булса да өстән теләк,
Халкымның көчле рухлары
Телебезгә нык терәк.

Телебез нык һәм бик гүзәл
Күп даһилар сөйләшкән,
Ата-ана телен аңлап
Алар бергә берләшкән.

Телебезнең колачы киң
Ул батмый һәм нык йөзә,
Илгә, дөньяга даһилар –
Армый-талмый үстерә.

## КАБАТ КАЙТАЛАР

Кошлар йөзә зәңгәр күлләрдә
Чумгалап та алар алалар,
Сагынып кайталар бит күлләрен
Үстерергә ел да балалар.

Үскән балалары да шулай
Канатларын җәеп очалар,
Туган җирләрен бик яратып
Канат кагу белән кочалар.

Көзен очсалар да еракка
Язын алар кабат кайталар,
Тик кайчакта очрап аучылар –
Аларны бит юлда аталар.

Сак булыгыз, күркәм аккошлар,
Золым салучылар җирдә күп;
Изге эшләр алар башкармый –
Җирдә яши бары булып чүп.

## ГАРМУН МОҢЫ

Гармунымны кулга алсам
Яшьлегем бит искә төшә,
Нык басып печән чабулар –
Алга һаман күчә-күчә.

Көндезен зур эш башкарып
Арыса да аяк-куллар,
Гармунны бер сузып алгач –
Яктырып китә бит юллар.

Гармун моңы тиз таралыр
Авылымның урамына,
Тәрәзәләр дә ачыла –
Бу моңнарга кушылырга.

Халык җырын һәм көйләрен
Яңгыратып уйнап узам,
Урамнардан бит кайчандыр –
Гармунчылар шулай узган.

Без борчуларны онытыйк

Кабат гармун моңы кайтсын,
Эштән арып кайтканнарны –
Татлы төш күреп йоклатсын!

## АЛМА АГАЧЫ

Май ае бик күркәм, чәчәкле ай
Кошлар сайрый кунып иңеңә,
Бакчада эшләп йөргән вакытларда –
Алмагачтан чәчәк сибелә.

Алар сибелүгә – алмалар да
Әкеренләп үсә башлыйлар,
Мул уңыш алырга теләгәннәр –
Алмагачны яхшы ашлыйлар.

Сулар сибеп торсаң кирәгенчә
Алар бик мул алма бирәләр,
Күбрәк булып, йөге авырайса –
Артыкларын җиргә сибәләр.

Алма агачы һәм бу алмалары
Кешеләргә бик нык таяныч,
Кайбер кешеләрнең аңламавы –
Монысы инде бик тә аяныч.

## МИЛӘШ

Кыеп – кызыл энҗе мәрҗәннәр
Тәлгәш-тәлгәш үскәннәр,
Табигатьнең сафлыклары –
Аңа шулай күчкәннәр.

Күз айлары ишек шакып
Килеп кергәндә безгә,
Миләшләрнең төсе, тәме –

Кызыллык бирмәс йөзгә.

Төсләре һәм тәмнәре дә
Үзенчәлекле аның,
Теләгеңчә син авыз ит –
Ашарсың әле тагын!

## КӨЗГЕ ЯҢГЫР

Көз көне көннәр яңгырлы
Көзге яңгыр ни сөйли,
Һәр тамчысы аның моңлы
Үзенчә нидер көйли.

Кайбер тамчысы бик йомшак
Акрын гына ул тама,
Ә кайберсе аткан уктай
Яткан ташны да яра.

Һәр яуган яңгыр тамчысы
Китерсен бары шатлык,
Абынмыйк, җирдә аунамыйк
Таш кебек анда ятмыйк!

## УКЫТУЧЫ ҺӨНӘРЕ

Бик борыңгыдан килә үл
Укытучы һөнәре,
Бар һөнәрнең башлангычы –
Кешелекнең үрнәге.

Булмас иде галимнәр дә
Табиблар һәм артистлар,
Туган илне нык саклаучы –
Очучылар, танкистлар.

Дөньядагы башка бик күп

Һөнәрне дә ул бирә,
Агачның нык кәүсәседәй
Барысына да ул ия.

Кәүсәдән үскән ботактай
Һөнәрләр таралалар,
Кешелек агым башында
Алар бит яралалар.

Укытучы миссиясе
Җаваплы һәм түземле;
Шуны аңлап, бу һөнәргә –
Мин тапшырдым үземне.

## ЯШЬЛЕК ҖЫРЫ

Дөньялыкта булган бар уңышлар
Яңгырады яшьлек җырында,
Дуслык көчле иде, ярдәмләштек –
Без тирбәлдек яшьлек моңында.

Яшьлек ул бер килә – сынатмадык
Зур сынаулар аша без үттек,
Тирән диңгез кебек – дөньялыкта
Батмый узарга да җитештек.

Диңгез утравыдай зур тормышта
Нык тамырлы гөлләр үстердек,
Дөньялыкта булган изгелекне –
Матурлыкны шулай күчердек.

## АҢЛАРСЫҢМЫ?

Нидер уйлап, тирән кызыксынып
Төбәгәнсең миңа күзләреңне,
Бары дөреслекне әйтеп бирсәм –

Аңларсыңмы, әйтер сүзләремне.

Тормыш агымында – батмас өчен
Киң колачлар салып йөзәсең син,
Зур эшләрне аңлау – тырышлыгың
Зәм-зәм суы эчкән – кошларга тиң.

Тырышлык – ул җиңә авырлыкны
Бары кирәк тирән – зур ышаныч,
Кыю басып барган һәр адымың –
Китерерләр бары, зур куаныч.

## КАТЫ ЭШ.

Кызарып ал таңнар атканда
Беренче әтәчләр уяна,
Аларның тавышын ишетеп –
Озак тормый көтү дә кузгала.

Җәйге таң үзенчә җаваплы
Кузгала техника зур эшкә,
Уңганнар тырышып эшлиләр –
Җавапсыз калмый бит бер төш тә.

Ал таңның нурлары җылыткач
Ялкау да йокыдан уяна,
- Көн матур, кибеткә барырга
Вакыт та җиткән, дип – куана.

Аның бу каты эш вакыты
Гел шулай унбердә башлана,
Көн буе өй-кибет арасы
Ике ара гел шулай таптала.

## ТАТАР МОҢЫ

Гармунның моңы уята
Туңган күңелләрне дә,
Сагынып искә төшерә –
Узган гомерләрне дә.

Гармун моңы, хезмәт җыры
Юлдаш алар гомерлек,
Алда булган бар киртәләр
Алыналар – бер көнлек.

Бу моңнар гомерлек юлдаш
Бар уңганнар өчен дә,
Аларның зур уңышлары –
Һәрчак калыр көчендә.

Без нык аңлыйк татар моңын
Беркайчан да югалтмыйк,
Аны көйләп һәм шатланып
Нык басып, алга атлыйк!

## ЮАНАБЫЗ

Көз дә җитте, көннәр үзгә
Йөрәк һаман язны сорый,
Кошлар оча җылы якка
Күңел никтер ямансулый.

Көз белән яз аермасы –
Берсе атлый салкын кышка,
Икенчесе ышандыра –
Кызынырга җәен тышта.

Һәр чорның үз шаукымы бар:
Кышын чаңгыда шуабыз,
Җәен елгаларга кереп
Рәхәтләнеп юынабыз.

Илдә булганда тынычлык
Яз да, көз дә куанабыз;
Көзге уңышка шатланып –
Чын бәхеттән юанабыз.

## КӨЧ КАЙТА

Күп комлыклар урнашканнар
Бормалы су буйларында,
Аларда кызынган чаклар –
Әле һаман уйларымда.

Кайткан кунаклар да килә
Бу суларда коенырга,
Комда кызынган тәннәрне
Ял иттереп, юынырга.

Кызынгач һәм юынгач та
Кабат көч кайта бу тәнгә,
Су буйларын һәм комлыкны
Чиста тотсын һәрбер бәндә.

## БИК ЯМЬЛЕ

Очрашуларга чакырам
Дус ишләрне мин күргәндә,
Яшьлекне кабат хәтерлим –
Су буйларында йөргәндә.

Аккан сулар кире кайтмый
Халык та бит әйткән дөрес,
Чишмә кебек челтерәп аккан
Яшьлек тә бит шуңа хирес.

Саф чишмәләр безгә якын

Сулары да аның тәмле,
Яшь гомерләр чишмә кебек
Сагындыра һәм бик ямьле!

## ЧӘЧӘКЛӘР ЯКЫНАЙТЫР

Көз дә җәйне алмаштырып
Сары күлмәген киде,
Син борчылма, моңсуланма
Иркәң – иркәлим, – диде.

Көзнең сары күлмәген дә
Кыш алыштырыр акка,
- Көн кыска, төннәр озын, – дип
Син артык йоклап ятма!

Алып көрәк һәм себерке
Чистарт тирә-юнеңне,
Гел шулай чисталык кылып –
Үткәрерсең көнеңне.

Кояш елмаеп карагач
Булган карлар эрерләр,
Беренче чәчәк шытканны
Кызлар көтеп йөрерләр.

Бу чәчәкләр якынайтыр
Җылы җәйләр җитүен,
Беренче язгы суларның
Матур гына китүен.

## ҮЗ ТАРИХЫ

Туган ягым чишмәләре
Миңа якын барысы да,
Алар челтерәп агалар –

Тау асты, тал астында.

Һәрберсенең үз тарихы
Үз язмышы, үз агышы;
Күп кешенең бу чишмәгә
Бушаткан йөрәк сагышы.

Күп гасырлар алар шулай
Челтерәп агып яталар,
Алган моңсу-сагышларны
Нык юалар, тараталар.

Кешеләр бит чишмәләргә
Күңел сагышын ачалар,
Йөрәгенә тынгы бирмәс –
Тынычсызлыктан качалар.

## ҮЗ ДӘВАСЫ

Кошлар сайрап, аяз көннәр тугач
Салкын чишмәләрдән су алдың,
Чиләкләрең тулып, чайпалгач та –
Матур атлап, китеп югалдың.

Салкын чишмәләрнең салкын суы
Йөрәк кайнарлыгын алдылар,
Күп яшьләрнең сагыш, эч серләре –
Гел чишелеп, анда калдылар.

Салкын чишмәләрдән су аласың
Сагыш-хисләреңне саласың,
Чишмәләргә барып, суын эчкәч –
Күңел рәхәтлеген аласың.

Шуңа да бит, чишмә суларының
Бар үз сере, бар үз дәвасы;
Чиста, матур чишмә буйларының
Саулык бирә, хәтта һавасы.

## ТАРИХИ ИЛ

Дөнья матур, күңелләр  көр
Дус-арага керәм, сыям;
Халкымның тарихын ачып –
Җырлый-җырлый “чәчәк” җыям.

Тарих булса да катлаулы
Чәчәкләр күп, бар билчәннәр;
Бу тарихны барлаганда
Кулланыла күп үлчәмнәр.

Бу үлчәмнәр күрсәткәнчә
Халкым – тырыш, гыйлем, уңган;
Аның бөек, даһилыгы –
Дөньялыкта инде тулган.

Халкыбызның төп нигезе
Татарстан – тарихи ил,
Аның белән кызыксынсаң
Башкаласы – Казанга кил!

## УРМАНКАЕМ – АК КАЕН

Табигатькә сокланырга
Табабыз без гел җаен,
Матурлыкны саклап тора
Урманкаем – ак каен!

Ак күлмәген алар киеп
Яшел шәлен ябына,
Туган яктан киткәннәр дә
Аңа кайтып табына.

Урманкаем – ап-ак каен

Син саулыкның челтәре,
Язын тәмле каен суын –
Эчеп җибәр элгәре.

Җәен кабат кешеләргә
Себеркеңне бирәсең,
Аның һәрбер тармагында –
Саулык барын беләсең.

Көзләр кергәч, бик мул итеп
Үстерәсең гөмбәңне,
Кыздырып та, киптереп тә
Куллануны бел, яме.

Каеннарның кадерен белеп
Кирәк бик тә сакларга,
Аны кисеп-тураударга
Дучар итми якларга!

## БУЕҢ ЗИФА

Билгә җиткән чәчләреңне
Йомшак җилләр сыйпап тора;
Бар торышың сокланырлык –
Буең зифа, кашың кара.

Акылың да буең кебек –
Чиста матур һәм инсафлы;
Борынгыдан килгән гадәт –
Син тапмассың һичбер тапны.

Татарның сылу кызлары
Йолдыздан бит исемнәре;
Зөһрә, Чулпан, Венералар –
Исемендә җисемнәре.

Алар бар да сәләтлеләр
Тәртипле һәм укымышлы,

Бар яктан да үрнәк булып
Якты тоталар тормышны.

## АЙТУГАНДА ТУДЫҢМЫ

Ай кебек балкый йөзләрең
Әллә анда булдыңмы,
Я булмаса бу дөньяга –
Ай туганда тудыңмы?

Ай яктыра, үсә бара
Күбрәк чәчә нурларын,
Йөзләрең гел нурлы булса –
Якты булыр юлларың.

Нурлы, якты юлларыңнан
Абынмыйчы үтәрсең,
Чуалган тормыш йомгагын
Буталмыйча сүтәрсең.

Бу йомгакны сүткән чакта
Очраса сикәлтәләр,
Якты юлдан югалырлар –
Булган барлык киртәләр.

## ХӨРМӘТЛЕ УКЫТУЧЫЛАР

Бәйрәмегез белән
Сезне Хөрмәтле укытучылар,
Балаларга һәрвакытта
Ныклы белем тукучылар.

Гаиләдә, эшегездә –
Тынычлык, саулык булсын;
Чын хезмәттән тапкан байлык –
Өстәлдә тулып торсын!

Килегез сез эшегезгә –
Балаларны яратып,
Үткәрегез дәресләрне
Аларны нык каратып.

Укытучы һәм укучы –
Ул гомерлек юл башы,
Сезнең эштә очрамасын –
Абынырлык юл ташы!

Һәрвакытта кояш кебек –
Балкып торсын йөзегез,
Якты юлга маяк булсын –
Һәрбер әйткән сүзегез
(Авырлыкка түзегез!)

## КҮБӘЛӘКЛӘР

Күзләр җитте, уңышлар мул
Шатлананалар, кочалар;
Күбәләкләр чәчкә эзләп
Төрле якка очалар.

Чәчкәләр дә әкрен генә
Хәзерләнәләр кышка,
Шуңа да бит салкын көндә
Таҗларын ачмый кышка.

Күбәләкләр очуы да
Хәзергә саубуллашу,
Канат җилпеп тирбәлүләр
Язга кадәр хушлашу.

Көннәре дә бик тиз уза
Көз артыннан үтә кыш,
Кыш артыннан килә язы –
Гел кояшлы булыр тыш.

Җылы көннәр кабат килгәч
Күбәләкләр очарлар,
Чиста, матур канатлары
Чәчәкләрне кочарлар!

## ЯРСЫП АГА

Су буенда яшел хәтфә болынлыкта
Тау итәге кабат юлын ачты аңа,
Байтак еллар йокымсырап яткан чишмә –
Кабат торып ургый-ургый ярсып ага.

Аны кабат йокысыннан уятырга
Ир-егетләр байтак кына көч керттеләр,
Киләч айлар балкып торган “күлмәкләр”не
Ак калайдан матур итеп кидерттеләр.

Тау астыннан ургып чыккан бу чишмәнең
Пар улактан салкын суы агып ята,
Ә таш җәйгән матур һәм нык баскычлары –
Һәр кешене су алырга үзенә тарта.

Бу чишмәне иркен койма урап алган
Матур төскә буялган бит коймалары,
Аның эче, аккан чишмә буйларында –
Күп чәчәкләр үсеп торган урыннары.

Акрын гына агып яткан бу чишмәләр
Зур тарихны безгә әйтә, безгә сөйли;
Челтер-челтер челтерәгән тавышлары –
Күп гасырлар күргәннәрен шулай көйли.

## ТОРМЫШЛАР ҖИҢЕЛӘЕР

Салкын дими, эссе дими
Тырышасың, эзлисең;
Эзләгәнең ошамаса –
Күзләремне күзлисең.

Ышаныч һәм нык таяныч
Булганын син белмисең.
Эзләнүең аша шуңа
Чыкканыңны сизмисең.

Эзләнүең, тырышуың
Сиздергәч зур уңышлар,
Дөнья матур, яхшы булыр
Җиңеләер тормышлар.

## ЯХШЫЛЫК КАЙТЫР

Дөнья чорсыз, дөнья кызу
Алар берсен-берсе кыйный,
Син бирешми көрәшәсең –
Йөзләреңдә нурлар уйный.

Мәшәкать, борчулар узар
Искән җилләр очыртырлар,
Начарлык явызлыкларның –
Тамырларын корытырлар.

Төп тамырлары корыгач
Алар явызлык кылмаслар,
Изгелек, яхшылык кайтыр –
Бер дә бирешеп тормаслар.

Барыр юллар да яхшырыр
Абынмыйча нык атларбыз,
Яшьтән алган тәрбияне –
Гомер буена сакларбыз.

## КӨЗ

Сентябрь да бетеп килә
Табигать көзгә керде,
Кайбер кошлар җылы якка
Китәргә дә өлгерде.

Туган яклардан киткәндә
Сайбуллашып очалар,
Канатларын җилпи-җилпи
Иркәлиләр, кочалар.

Озак көттермәс, килер кыш та
Аның арты – язлары,
Туган якка кабат кайтыр –
Язын киек казлары.

Мин дә йөрим су буенда
Ныклап атлый көз ае,
Көз дә, кыш та узып кикәч –
Килеп җитәр – яз ае.

Хәзер яфракларын коя
Ап-ак матур ак каен,
Гел шулай ул моңсулана –
Көзләр җиткәч ел саен.

Көзләр узып, кыш та җитәр
Ап-ак карлар яварлар,
Ак каенны кышын салкын –
Булмасын! – дип ягарлар.

Яз айлары аяк баскач
Уяныр кабат каен,
Бөреләре көтеп тора –
Баш калкытырга җаен.

## ТАБИГАТЬ – ЧӘЧӘКТӘ

Дөнья матур, көннәр җылы
Безнең шомырт чәчәктә,
Тагы табигать чәчәккә –
Күмелер киләчәктә.

Тынычлык, саулык булганда
Бар эштә дә бар уңай,
Изгелек кылып эшләсәң –
Эшләрең булыр кулай.

Чәчәктә булыр табигать
Кеше күңеле чистарыр,
Үзе кылган ялгышларга –
Аптырап хәйран калыр.

Хәйран калу, аптыраулар
Туры килмәсен кабат,
Туган халкың һәм җиреңне
Ялгышмыйча, син ярат!

## ТАБЫШ

Ходай дөньяга җибәрә
Теләп безгә ышаныч,
Акылың белән саулыгың –
Монысы инде зур табыш.

Бу табышны эшкә җигеп
Кылсаң бары изгелек,
Бәхетле булып яшәрсең –
Барысын да үзең сизеп.

Изгелек – ятмый бит җирдә
Ул үсә һәм зурая,
Кәкре, авыр булган юллар
Әкренләп турая.

Чиста, матур, ак юллардан
Син нык атлап барырсың,
Игелек кылган эшеңдә –
Ихтирамда калырсың!

## АЯНЫЧ

Яна бит йөрәк сызлана
Сизәсең сулганыңны,
Әле бит кайнар булсаң да –
Шатырдып туңганыңны.

Ихтирамның, дөреслекнең
Кирәксезен беләсең,
Ә шулай да “югалтмыйм!”, – дип
Тырышасың, түзәсең.

Кылны түгел – тик кырыкка
Бүләсең күбрәк – йөзгә,
Тырышып ярдәм итәсең –
Кайчак керәсең сүзгә.

Намуслы, чиста булуны
Аңлату хәзер авыр,
Кеше бит ул дөреслектән –
Һәрвакыт читтә калыр.

Кайда калды бар ышаныч
Киләчәккә таяныч,
Кешелеклек бетә бара –
Монысы бик тә аяныч!

## ГӨЛ-ЧӘЧӘК

Елмая синең күзләрең
Кирәкми бер сүзең дә,
Май чәчәкләре чаткысы –
Чагылып китә йөзеңдә.

Әй гүзәлем, гүзәлем
Син бит минем гөл-чәчәк,
Шулай, сөйкемле яшәгәч –
Дөнья матур киләчәк.

Күзләрең дә, йөзләрең дә
Бәхетле елмаялар,
Бу тормышың һәрвакытта –
Игелек бирә алар.

Йөзләреңдә елмайганда
Нурлы эзләр ясала,
Бу сөйкемле гадәтеңне –
Беркайчан да ташлама.

## СӘЛМӘН ДУС

Җитте бүген көз аеның
Уртасы һәм бересе,
Бик авыр моны үткәрде –
Танышларның күбесе.

Арабыздан китеп барды
Сәлмән Әхмәтҗан улы,
Мәңгелек булсын урыны –
Чәчәкләр белән тулы.

Гомерен ул багышлады
Тәрбиягә, белемгә;
Укучылар өчен тырышу –
Сәбәп булды үлемгә.

Намуслы, нык тәрбиягә –
Каршы хәзер законнар,
Бу өлкәдә эшләүчеләр –
Барысы да моны аңлар.

Элеккечә мөгаллимгә
Кайтса иде олылык,
Икенче әти-әнигә
Булган хөрмәт һәм зурлык.

## СӘЛАМӘТ ТӘНДӘ – СӘЛАМӘТ АКЫЛ

Халкыбыз бик борынгыдан
Тырыш, сәләтле булган;
Шуңа аның акылы да
Сәламәтлектән тулган.

Сәламәт тәндә – сәламәт акыл
Гимназия барган юл,
Шул юлдан нык атлап барып –
Гел шулай сәламәт бул!

Сәламәт акыл булганда
Сәламәт булыр тән дә,
Бу әйтемгә нык ышанса –
Сәламәт булыр бәндә!

## ХЕЗМӘТ ВЕТЕРАННАРЫ

Абый, апалар – сез безнең
Хөрмәтле ветераннар,
Озак, намуслы эшләгәннәр –
Барысы да моны аңлар.

Таң аткач та бит күбегез

Булды гел барыр юлда,
Эш кораллары төшмичә –
Һәрвакыт булды кулда.

Хәзер ялда булсагыз да
Бар кешегә сез кирәк,
Балаларга, оныкларга –
Буласыз бик нык терәк.

Озын гомерләр телибез
Бик олылап дәшәбез,
Кылган изге эшегезнең –
Кадерен белеп яшәгез!

## КАЕНЛЫКТА

Ак күлмәгеңне киясең
Каенлыкка киләсең,
Кайсы каен, кайсы сине –
Аерганны беләсең.

Ак каенның күлмәге дә
Бигрәк матур, путалы;
Синең дә бит бу күлмәгең –
Каен кебек билбаулы.

Ак күлмәген кигән каен
Яшел яулыгын япкан,
Елмаеп тора ул шулай –
Әйтерсең, сине тапкан.

Ак каенда – ак бәхетләр
Аны кирәк аңларга,
Булган матур эшләреңне
Югалтмаска – саннарга!

## СӘЛАМӘТ ТӘН – ЗУР САУЛЫК

Сәламәт тәндә – сәламәт акыл
Тирә-як саулык, ялкын;
Эш сөйсәң, спорт яратсаң –
Куркытмас бер дә салкын.

Менә бу ленталарда да
Агыла бара саулык,
Сәламәтлек һәм көч арта –
Башта бит ап-ак яулык.

Тырышып укып алгач та
Спортка кала вакыт,
Капкага төгәл ташлыйбыз
Шайбаны туры атып.

Аяк-куллар хәрәкәттә
Бар җиребез сау, көчле;
Шулай тырышып биибез –
Дуслар да безнең ишле.

Сәламәт тәндә – сәламәт акыл
Спортны бик ратыйк,
Ялкаулык һәм авыртуны –
Без үстермик – таратмыйк!

## НЫК БАРЫР!

Дөнья матур һәм түгәрәк
Карыйм сайраган кошка,
Аларның матур тавышы –
Чакырып тора тышка.

Һава да саф, искән җилдә
Тибрәлә моң –җырлары,
Бу җырларны көчәйтергә –
Кая халкым кызлары?

Галиябану, Гөлҗамаллар
Карурманнар – сез кайда,
Әллә барысы шул урманда –
Адашып калдымы әллә?

Вакытлыча адашудан
Халкым бик тиз уяныр,
Туган телне, әллүкине –
Җырлап, нык басып барыр!

## БАРМА!

Күзләремә бер тутырып
Нык елмаеп карадың да,
Чәчләреңне дулкынлатып –
Тирән итеп, тарадың да...

Әйтерсең лә саф чишмәнең
Аккан матур тавышлары,
Барысы үтте: акты, китте –
Калды бары сагышлары.

Күзләремне мин дә салдым
Синең матур карашыңа,
Кышын салкын – ул бәрмәсең
Ялындырма – ки башыңа!

Хәтер йомгагын бит чишеп
Кабат тәүге кат очрашу,
Анда мәктәптә укулар –
Төрле эшләрдә катнашу.

Шулай гомер баскычлары
Күтәрелде һаман алга,
Узган гомер артта кала –
Күп калмый бит инде ялга.

Һәркемнең гомер юллары
Акрын гына уза бара,
Матур яшьлек истәлеге –
Онытылмый ул – син дә барла!

## КӨЧЛЕ БЕЗ!

Ачыла яңа мәктәпләр
Түрәләр йөри котлап,
Тел һәм милләт читтә кала
“Ятсыннар!” – диеп, йоклап.

Үз телең һәм милләтеңә
Эләкми яңалары,
Унбиш ел шулай эшлибез –
Төзәтеп яраларны.

Ике бина арасында
Чабабыз, йөгерәбез;
Шулай тырышып эшләгәч –
Барысына өлгерәбез.

Гимназиябезнең яше
Үсмер вакыт – егет чак,
“Уңышларын белим”, – дисәң
Интернетны ачып бак!

Диплом һәм медален алды
Каюм Насыйриның да,
Рәсәй күләм Грантка да –
Ия булды бит, ул да.

Президент фотосы төшкән
Белешмәгә кертелдек,
Рәсәй Мактау китабына
Алынганны да белдек.

Рәсәйнең әйдәп баручы

Мәгариф идарәсе,
Милли реестрга кертте –
Хәзер анда барасы.

Гимназия яшь булса да
Сигез укучы кандидат,
Тагын алтау укып йөри –
Барысы өчен – без бик шат!

Шулай матур, нык тырышып
Эшлибез дә эшлибез,
Беркайчан да авырлыкка –
Каушап, җебеп төшмибез.
Телне сөйгәч – көчле без!

## САЙЛЫЙЛАР

Документлар яңа алдык
Петербург шәһәреннән,
Гимназиябез уңышы –
Аңа да бит барып иңгән.

Безне кабат чакыралар
Бәйгедә катнашырга,
Уңышларны барлап, теркәп –
Ил күләм узышырга.

Рәсәйдә булган иң яхшы
Йөз мәктәпне сайлыйлар,
Шулар арасына безнең –
Керүне д барлыйлар.

Без дә Уңышларны туплап
Катнашырга уйладык,
Эшләребез күп булса да
Ялкауланып тормадык.

Шулай бердәм, тырыш булып

Уңышларга ирешик,
Зур хөрмәткә ия булган –
Дәрәҗәләрдән төшмик!

## ӘМЕР

Дөнья гөрли, эшләр чаба
Өлгерәсе, тотасы;
Аяк таймый, егылмыйча –
Кирәк һәрчак отасы.

Бу отышның ничек болай
Булганын күп аңламый,
“Очраклы хәл генә”, – дип
Тырышлыкны саннамый.

Яратсаң бар укучыны
Сөйсәң әгәр эшеңне,
Онытырсың күп вакытта
Сыкраган бар төшеңне.

Бар да узар, терелерсең
Күңел кабат яшәрер,
“Яхшылыкта узышыйк!” – дип
Кабат безгә бир, әмер.

## КӨЗГЕ ҖИЛЛӘР

Яфраклар – саргая, оча
Көзге җилләр исәләр,
Аларга ияреп кошлар –
Җылы якка китәләр.

Җилләрнең бар үз гадәте
Дулаганы – органы,
Күп вакытта тыныч кына
Биттән “үбеп” торганы.

Табигатькә карап алар
Усаллана – я көлә,
Я елмаеп, карап тора –
Я салкынын бик “өрә”.

Җилләрне дә аңлый белсәң
Кешеләргә булышкан,
Я аларга ул ут биргән
Он да тарткан уңыштан.

Җил чыкты дип курыксагыз
Якмагыз хәтәр учак,
Ут-газларны карап кына
Файдаланыгыз һәрчак!

## ИЗГЕЛЕККӘ ЧАКЫРА

Ак томаннар җирне каплаган
Туры килә бик сак үтәргә,
Бик тырышып корган дәүләтне
Яңа баштан кире сүтәргә.

Бу томаннар әле гел ятмас
Көннәрнең дә булыр аязы,
Бар дөньяга матурлык биреп –
Килеп җитәр ямьле яз ае.

Бу айларда үскән чәчәктәй
Кабат үсәр, ныгыр илебез;
Илебездә барлык халыкның –
Чәчәк ата туган телебез.

Һәр телнең бар яхшы сыйфаты
Изгелеккә, эшкә чакыра;
Аны төгәл, дөрес үтәсәң –
Изге юллар бик тиз яктыра.

Шул юллардан без дә атларбыз

Куәт биреп туган илемә,
Туган ил бит була бер генә
Син салынма кеше иңенә.
Үз телеңнең кадерен бел генә!

## МОҢНАР КАЙТА

Күңел ярсый, нидер көтә
Йөрәк чакыра тышка,
Нәрсәдер җитмәгән кебек –
Карыйм сайраган кошка.

Кош та үзенчә аңлата
Канатларын да җилпи,
Аның сайраган тавышы –
Таралмый, ерак китми.

Ул чыгарган тавышларда
Яңгырый халкым моңы,
Алар кабат яңгырасын –
Булмасын көйнең соңы.

Язлар җиткәч, кайтыр кабат
Халкымның күп моңнары,
Һәрвакыт кешегә ныклык –
Бирә торган җырлары.

## ШАТ МИН

Изге эшләр кылып яшик
Дөньялыкта мин дә, син дә;
Ходайның изге догасы –
Ак күлмәгем кесәсендә.

Ак күлмәктән – ак юлларда
Нык адымнар белән атлыйм,

Изге эшләр башкарыла –
Шуңа күрә, һәрчак шат мин.

Алар шулай тамыр җәеп
Һаман үсә, һаман ныгый;
Бу башкарган матур хезмәт –
Алга бара – туктап тормый.

Хезмәтебез уңышлары –
Ишетелә кайчак безгә;
Изге эшләр башкарабыз –
Зур бәхетләр телим сезгә!

## ЕЛМАЕП ТОРСЫН

Бина матур, заллар зур
Бүген конференция,
Бу залларга – җыелышка
Меңләгән кеше сыя.

Уңышлы гына башлансын
Яңа уку еллары,
Олы күрсәткечләр белән
Тәмамлыйк ла без аны.

Бүген алган күрсәтмәләр
Булсыннар якты маяк,
Белем һәм тәрбия бирик –
Таймасын өчен аяк!

Укулар тиздән башлана
Бәхетле еллар булсын,
Балаларның якты йөзе –
Елмаеп кына торсын!

## РӘСӘЙ МӘКТӘБЕ

Безне кабат шатландырып
Хәбәр килгән Рәсәйдән,
Без дә бит илнең иң яхшы –
Йөз мәктәбенә кергән.

Бу елдагы тагы бәйге
Ел директоры булды,
Башкарган изге эшләргә –
Тагы бер плюс кунды.

Эшләребез зур, хөрмәтле
Тирән белем бирәбез,
Балаларга тапшырырга –
Һәр көн эшкә киләбез.

Укулар да дәвам итә
Хәзерлек имтиханга,
Намуслы кылган хезмәтләр –
Китерсен һәрчак данга!

## ТИҢ ИҢНӘР

Кояшның балкыган нурыдай
Тагы син елмаеп узасың,
Тойсаң син минем дә барлыкны –
Шатланып кулыңны сузасың.

Бу йомшак кулларың кагылса
Искән күк иртәнге саф җилләр,
Тормышта бәхетле яшәргә –
Һәрвакыт булса ла тиң иңнәр.

Балкыган йөзләрең нурында
Мин йөзәм, коенам һәм уйлыйм
Алар гел елмаеп торсыннар –
Һичкайчан алардан мин туймыйм.

Йөрәгем бу нурдан җылына
Колындай ул чаба һәм тибә,
Хисләрем сиңа да ирешсен –
Сал йомшак кулыңны бу иңгә.

## ДӘВАМ ИТӘМ

Яшь гомерләр уза, тузан туза
Ә шулай да истә иртәләре,
Эш башлаган горур мәктәбемнең –
Басып тора – зифа юкәләре.

Бу юкәләр – чын тарихны белә
Каршылаган һәм күпләрне озаткан,
Монда булган һәр кеше тарихын –
Белә кебек алар – барысы яттан.

Әле дә истә, шул юкә астында
Тезелешеп баскан укучылар,
Соңгы кыңгырауны шалтыратып –
Зур тормышка юлны тотучылар.

Без тырышып биргән белем, хезмәт
Гомерләр узса да картаймыйлар,
Аларга таянып атлаганда –
Беркайчан да аяклар таймыйлар.

“Яшь гомерләр узды!” дип уфтанмыйк
Алар узды – бәрәкәтле, күркәм;
Укучылар ирешкән уңышка –
Бик шатланып, эшне дәвам итәм!

## ТАЛЬЯН МОҢЫ

Уйна тальян гармуныңны
Моңландырып һәм сузып,
Яшьлекне кабат бирерсең –
Гомер китмәсен узып.

Шул моңнарга син дә кушыл
Алмагачлар чәчәктә,
Җыр-моңнарны бик яратып –
Яшәрсең киләчәктә.

Татар җырлары бик матур
Анда тальян моңнары,
Ул моңнарны белгәннәрнең –
Чиста булыр юллары.

Тальян гармун чыгарган көй
Бик зур көчкә ул ия,
Яшьлекне дә хәтерләтә –
Күңелгә тия-тия!

## КАЙТУЫН КӨТӘ

Елга буйларында йөрим
Чишмәләрдән сулар йотып,
Хәтерләп яшьлек елларын –
Өянкеләрдән сәлам отып.

Агачларның кәүсәләре
Ботаклары юанайган,
Кайберләре инде корып –
Тораташтай басып калган.

Алар барысын хәтерләтә
Барысын белә, барысын сизә;
Балачак көннәрен җепкә –
Әкеренләп тезә-тезә.

Алар үскән бу тирәлек
Матур аккан елга иде,
Бик күп бала балык тотып
Су коенып йөргән иде.

Ә бу урын бер бик юан
Өянкенең төбе иде,
Монда агып торган суның
Төбенә бит аяк тиде.

Суга атлап кергән чакта
Тимәсә дә төпкә аяк,
Өянке төбеннән сикергәч –
Комлыкка без бастык җайлап.

Балачакның хатирәсен
Бу өянкеләр хәтерләтә,
Югалган матур елганың
Кабат кайтуын бит көтә.

## ГИМНАЗИЯ ТУГАН КӨН

Туган көнең белән сине
Татар гимназиясе,
Син ирешкән Уңышларга –
Бары башны иясе.

Конституция көне бит
Синең туган көнең дә,
Милләтебез түземлеге –
Ныклык бирде гел безгә.

Унбиштә генә булсак та
Уңышларыбыз зурдан,
Рәсәй күләм дә танылдык –
Күрсәткечләр бит мулдан.

Фән кандидат – укучылар
Ундүрт санын тутыра,
Алар кебек танылырга –
Бик күпләр план кора.

Уңышлар гел арта тора
Бик тырышып эшлибез,
Рәсәйнең йөз яхшы мәктәп –
Исемлегенә кердек без.

Киләчәктә тагы шулай
Тырышып эшләргә план,
Кайсы тармак каралуын –
Исәпләп, уйлап торам.

## АЛМЫЙ КАЛМА

Әти-әни, туган җирем –
Якынлыгы – бармы сиңа,
Туган телнең саф авазы –
Һава сыман кирәк миңа.

Әти, әни – изге затлар
Яшәү көче бирүчеләр,
Туган тел һәм туган җирнең –
Яшәү көчен күрүчеләр.

Алар барысы – бер сулыштан
Саф һаваны тирән алып,
Тәрбия, белем бирәләр –
Алмый калма – йоклап калып!

## ЯМЬЛЕ МИШӘ

Мишә буйларында карап йөрим
Бигрәк матур ага бу юлы,
Һәр үсемлек, ташлар нидер сөйли
Камыш төпләрендә моң тулы.

Сулары да элек булган мулдан
Суның тегермәне эшләгән,
Яктылыкны биргән станция
Макталудан бер дә төшмәгән.

Чиста елгалардан – бит ул Мишә
Чыга чишмәләр дә ярлардан,
Язларын ул ташый, киң җәелә –
Сулар арта, эреп карлардан.

Шулай көчле, матур агым белән
Ул тиз ага, гөрләвек аша,
Ямьле Мишә, сулары да чиста
Камага ул барып тоташа.

## ЧӘЧКӘЛӘР БӘЙЛӘМЕ

Бик күп эшне башлап җибәргәндә
Очрап тора һәрчак юлда киртә,
Уйлап эшлә, бер дә каударланма –
Ашыгулар – ялгышуга илтә.

Бар эшне дә уйлап башкарганда
Ялгышлыктан тырыш син качарга,
Изгелекләр кылып кешеләргә –
Булыш, якты юлларын ачарга!

Якты юллар артып – киңәйгәндә
Куандырыр дөнья үзгәргәне,
Тирә-ягың матур, чиста булыр
Менә монысы – чәчкәләр бәйләме!

## БАР ДА АҢЛАР

Тормыш дулый, тынычланмый
Дулкын бәрә бирегә,
Аның юлын томалагыз –
Агып, сулар кирегә!

Кире агып тынычлангач
Тормыш дулкыны тынар,
Үз телен яраткан кеше –
Туган телендә җырлар.

И туган тел, и матур тел
Әткәй-әнкәйләр теле,
Сине күркәмлекләр бизи –
Бар чәчәкнең син – гөле.

Тормыш тынычлыгы кайтып
Матурайгач дөньялар,
Туган телнең бик зур көчкә –
Иялеген бар да аңлар.

## СЕРЕН АЧА

Табигать тын, кошлар сайрый
Кемдер матур көйне көйли,
Ак яулыклы күркәм апа –
Сандугачка серен сөйли.

Сандугач та тынып тора
Ул да аңлый, ул да тоя,
Үзенең моңлы көйләренә
Әйтерсең ул, сүзләр җыя.

Ак яулыклы апа шулай

Сандугачка серен ача,
Башка кошлар моңсу урынын
Ишетмәскә – читкә кача.

Ханыманың сүзләрендә
Тормыш иптәше моңнары,
Тальян уйнап җырлаганы –
Авыл көйләрен сузганы.

Шулай узган гомерләр дә
Калган бары – матур хәтер,
Сандугачка серен ача –
Бәлки аңа – “барып әйтер?”

## ГАРМУННЫҢ ЯҢАСЫ

Туган як – якын һәркемгә
Табигать тә ишеген ачкан,
Яшел чирәмдә тәгәрәп –
Без беренче тәпи баскан.

Үрмәләп һәм ябышкалап
Беренче адымнар киткән,
Кайчак егылып алганда
Җир ана да кочып үпкән.

Туган якның һәр тармагы
Биргән бары куәт һәм көч,
Елгалары, болыннары –
Онытылмас, беркайчан һич.

Көне буе хезмәт куйган
Кызлары һәм егетләре,
Кичен клуб бакчасында
Кабызганнар өметләрне.

Заманалар шулай үтә
Тәпи баскан көннәр узган,

Яшь вакытта күп уйнаган –
Гармуннар да инде тузган.

Кайтып киләм туган якка
Кулда гармунның яңасы,
Килә кабат чирәмнәргә
Яланаяклап басасы.

## ОНЫТМЫЙК

Дөнья матур, күңелләр көр
Нинди иркен туган илем,
Бар бәхеткә шатлык өсти –
Ак яулыклы әнием минем.

Бу яулыкның бар үз сере
Кояштан ул башны саклый,
Табигать шаярып алса –
Салкын җилдән дә ул каплый.

Ак яулык ябынган башта
Ак фикерләр, ак теләкләр;
Барчабызга бары бәхет
Өләшүче – нык терәкләр.

Ак яулыклы әнкәйләрнең
Изгелеген без онытмыйк,
Алар янына һичкайчан –
Җылы сукмакны суытмыйк!

## ЯШЬЛЕК МОҢЫ

Елга буйларында йөрим
Яр буйлары бигрәк комлы,
Яшьлек узды, барысы үтте –
Безнең күңел – нигә моңлы?

Бу моңнарны таратырга
Биек тауга менеп басам,
Башка борчулар кирәкми –
Мин теләмим, тизрәк качам.

Тау итәгенә төшкәч тә
Яшьлек моңы ишетелә,
Быргы, барабан тавышы –
Безнең чорның күбесенә.

Туган як җыры яңгырый
Күңелләр соң нигә моңлы,
Яшьлек узып киткәнгәме –
Мин яратам моңлы җырны.

## НЫК АТЛАРСЫҢ

Еракларга язмыш ташласа да
Туган як ул һәрчак якында,
Бу якларга кайткан вакытларда –
Тизрәк китәм! – диеп, ярсынма.

Туган җирдән читтә яшәсәң дә
Якын булсын туган якларың,
Бу якларга төрле караш булса –
Син ачарга тырыш – акларын!

Ак тарихын аның белгән саен
Син ачарсың юлның агын да,
Горурланып басып, нык атларсың –
Туган якка кайткан чагында.

## ИХТЫЯР КӨЧЕ

Яшьлек бит килә ул бер генә
Гармун да моң суза кичләрен,
Без аннан егәрлек алганбыз –
Гел сиңа талпына хисләрем.

Ал нурын очырган йолдыздай
Яшьлек ул – килә бер гомергә,
Тапламый, намуслы үткәреп –
Кирәк тик, кадерен белергә!

Яшьлектә кабына ал нурлар
Барачак юлларны яктыртып,
Нык басып киң юлдан атлыйбыз
Син дә бар уңышны нык тотып.

Яшьлектә алган бу тәрбия
Көч бирә безгә гел җиңәргә,
Без бердәм бик кыю атларбыз –
Ихтыяр көче бар иңнәрдә.

## ЯШӘҮ РӘХӘТ

Авырлык килсә дә түзәбез
Намусны саклыйбыз – эшлибез,
Тормышка бары бер килгәнбез
Балалар хакына – яшибез.

Дөнья да үзгәрер – яктырыр
Каралган күңелләр чистарыр,
Дөреслек, гаделлек ачылып –
Бар кеше күңеле таң калыр.

Яшәү дә кешенең үзгәрер
Йөрмәс ул бир диеп, гел хәмер;
Тормышлар чистаргач дөньяда –
Яшәүләр рәхәт бит, гел хәзер!

## КУАНДЫРА

Намуслы һәм шөкерана кылган
Һәр хезмәтнең күркәм була яме,
Гаиләдә, эштә үрнәк булып –
Бер-беребезгә бүләк булыйк әле!

Һәр укучы балалар язмышы
Киләчәктә ышанычлы булса,
Шатланып, гел бәхетле яшәрбез –
Уңышлары шулай ташып тулса.

Һәр укучы якын, үз балаңдай
Аларның язмышы – уйландыра,
Тормышта нык басып атласалар –
Аларның уңышы куандыра.

Гел шулай нык булып, укымышлы
Туган тел һәм илне яратыгыз,
Шулай зур уңышларга ирешеп –
Үрнәк сыйфатларны таратыгыз!

## ҖӘЙГЕ БӘЙРӘМ

Җәйге бәйрәм – сабантуйлар уза
Борынгыдай шулай куелган,
Атлар чаба – бар җирдә матурлык
Дугаларга сөлге уелган.

Эленгән бу – сөлге бизәкләре
Нидер сөйли, нидер аңлата;
Сабантуйлар гөрли – матур бәйрәм
Ал таңнар да ашыгып ата.

Бәйрәмнәр дә уза, халык туза
Таралалар кайту ягына,

Батыр җилкәсендә ап-ак тәкә
Ул аптырап карый – барына.

## КАЙЧАН КАЙТЫР

Нинди ил бу безнең, нинди тәртип
Акыл белән эшләү тыела,
Алдым-бирдем эшкә генә рәхәт –
Авырлыклар артта җыела.

Ел беткәндә генә мәгълүм була
Күпме акча безгә куела
Булганы да ремонт эшләренә
Файдалануларга тыела.

Югыйсә бит, бирелгән акчаны
Кирәк изге эшкә тотарган,
Һәр ел килгән тикшерү сынавын
Штрафсыз җиңел отарга.

Кайчан кайтыр икән, бу тәртипләр
Кайчан килер намус, дөреслек;
Кайчан кайтыр кеше күңеленә –
Дөрес аңлау изге хиреслек.

## КАБАТ КӨТӘ

Кояш чыга – җиргә коя
Үзенең ал нурларын,
Сабый көлә – барысын күрә
Суза йомшак кулларын.

Кояш менә, күтәрелә
Бар табигать сусаган,
Шуңа да, ахры, шауламыйлар
Барысы да тынып калган.

Кояш бата, ә ай калка
Бар тереклек йокыда,
Син дә, тукран, йокла – ял ит
Бераз гына тукы да!

Кабат – табигать уяна
Яңгыр да явып үтә,
Тереклек яшәрә бара –
Яңгырны кабат көтә.

## ФӘРЕШТӘЛӘР

Ап-ак күлмәк кигән килеш
Матур гына ярәшсәләр,
Намуслы бул, бәхет өстә –
Иңнәреңдә фәрештәләр.

Уң ягында – уң фәрештә
Уңай юлны күрсәтүче,
Сул ягындагы фәрештә –
Изге эшләргә дәшүче.

Аларның яхшылыкларын
Һәрвакытта тоя белсәң,
Күңелең гел чиста булыр
Кешелекле булып йөрсәң.

Уң ягында – уң фәрештә
Сул ягында – сул фәрештә,
Аларның изге теләге –
Зур таяныч безнең囗эштә.

## ЯШЬЛӘР ТАМА

Шаулап ага чиста сулар
Кая коя соң бу елга,
Яраткан хезмәт булмаса –

Гүзәл булмас иде дөнья.

Шул сулар күк безнең тормыш
Һич туктамый гөрли-ага,
Кисәк-кисәк ургып куеп
Биек ярга килеп кага.

Әгәр ярлар булса төзек
Ул китә алмас инде чыгып,
Яңа юл ачасың килсә –
Җибәрергә кирәк ерып.

Тормыш гөрли аккан судай
Кайчак тына – туктап кала,
Бик озак туктап ул калмасын –
Күзләрдән бит яшьләр тама.

## КУАНДЫРА

Матурая бара дөнья
Син һәр эштән юанасың,
Хезмәтең – бәхет китерә
Чын күңелдән куанасың

Башкарган изге эшләрең
Булсын һәрчак юанычлар,
Ил күләмдәге уңышлар –
Китерерләр куанычлар.

Бәхет китергән бар хезмәт
Куандыра кешеләрне,
Моны белми, сизми торган –
Дөньялыкта кеше бармы?

Изге эштән читенсенми
Син һәрвакыт тырыш, эшлә;
Хезмәтең бит куандыра –
Беркайчан да түбән төшмә!

## МАТУР ТАВЫШ

Матур тавыш ишетелә
Яңгырый ул сайрар коштай,
Күңелләрне җилкендерә –
Гармун сайрый сандугачтай.

Кайчак түбәнәеп китә
Аның моңлы тавышлары,
Сузыла һәм нык көчәя
Әйтерсең, моң ярышлары.

Бу моңнарда халкыбызның
Күп гасырлык яшәү көче,
Кояш нурында балкып та
Һич уңмаган намус төсе.

Шул моңнары һәм намусы
Күп меңнәрчә еллар үтә,
Тарихның бик зур йомгагын –
Әкрен генә җайлап сүтә.

## МАЯК АЧЫЛА

Менә тагы җәйләр җитте
Менә бүген бәйрәм дә була,
Дус ишләрнең дә күбесе –
Шатланышып, монда җыела.

Кайт син, кайт син – үзең кайт
Бар борчуны тот та утка як,
Кайт син, кайт син – үзең кайт
Яшьлеккә бит ачыла маяк.

Язгы хисләр – җәйге көндә

Сулганнармы әллә боегып,
Саулык булгач, яшим мин дә
Тормыш уңышына коенып.

Бу мәйданда – карыйм сезгә
Бик күбегез таныш безгә,
Матур гына ял итегез –
Кызыллык китерми йөзгә.

## ЯРАП ТОРА

Түгәрәк йөз, матур күзләр
Алар тора елмаеп,
Син үзең дә бик зирәк бул
Егыла күрмә, һич таеп.

Бер тапкыр инде абынгач
Атла син карап кына,
Ашыкмый башкарган эшләр
Хәзергә ярап тора.

Кеше бит ул – үзе шундый
Ялгышып та куйгалый,
Бик яхшы барган эшләрне
Кирегә дә боргалый.

Әй, кешелек, аңыңа кил
Тоз салма керсез җанга,
Гомер ул – бер генә килә
Уйлап кыл, шуны аңла!

Ашыкмый, сөеп башкарсаң
Һәр эшең булыр уңган,
Барыр юлың һәм гаиләң –
Бәхеттән генә тулган.

## ВЕНЕРА НӘБИУЛЛОВНА

Нәбиулла – гарәпчә илче
Ходайның пәйгамбәре,
Аның кызы Венера да
Изгелекнең тиңнәре.

Нәбиулланың кызында
Моның ачык мисалы,
Кешегә биргән саулыкның
Юктыр исәп-хисабы.

## ТАБИБӘ – ӘДИЛӘ

Бүген килеп җитте
Кышның да нәкъ уртасы,
Хастаханәгә мин кердем –
Кирәкми һич куркасы.

Шәфкать туташлары кереп
Бирәләр даруларны,
Махсус аппаратлар белән –
Алалар аруларны.

Аяклар да безнең ныгыр
Тамырлар да терелер,
Монда алган сәламәтлек
Яши-яши беленер.

Рәхмәтебез сезгә бик зур
Табиблар – табибәләр,
Сезнең арагызда эшли –
Шәфкатьле Әдиләләр.

Зур бәхетләр алып килсен
Бу хезмәтегез сезгә,
Бәхетле тормышта яшәп –
Яшегез җитсен йөзгә!

## ВЕНЕРА ЛОТФУЛЛОВНА

Лотфулла бик матур исем
Шатлык бирә бар якка,
Ходайның шәфкатен һәм дә
Мәрхәмәтен аңлата.

Аннан туган балалар да
Бәхет бирә кешегә,
Бик зур рәхмәтләргә лаек
Алар бар да эшендә.

Лотфулла кызы – Венера
Моның ачык мисалы,
Кешегә биргән саулыкның –
Юктыр исәп-хисабы

Венера ханым, мин дә сезгә
Телим олы саулыкны,
Башыгызга гел бик матур
Ябылган ак яулыкны.

## ФӘРИТ-ФӘРИДӘ

Гарәпчә Фәрит – Фәридә
Күп мәгънәләргә ия:
Энҗе бөртеге, бриллиант
Тиңдәшсез һәм бердәнберем –
Ул исемнәргә тия.

“Исемендә – җиселе!” – дип
Юкка әйтмәгән халык,
Эшен яратып башкарган –
Фәридә моңа лаек!

Эшеңдә һәм тормышыңда
Бәхет бирсен юлларың,
Авыруларны терелтсен –
Шифалы бу кулларың!

## ВЕНЕРА РАМАЗАНОВНА

Һиҗри елның тугызынчы
Ураза ай исеме,
Шуңа да бит Рамазанга –
Туры килә җисеме.

Чынлыкта бу айда туган
Изге була балалар,
Киләчәк буыннар аны –
Үрнәк итеп баралар.

Венера – Рамазан кызы
Яз – матурлык билгесе,
Саулык, бәхетләр бирүче –
Чисталыкны өлгесе.

Шәфъкать туташы, Венера,
Саулык белән эшләгез,
Зур уңышлардан куанып –
Бик бәхетле яшәгез!

## РЕЗЕДА

Тиздән яз җитәр, Резедә
Зәңгәр чәчәген атар,
Ул биргән шифаны алган –
Нык басып, алга атлар.

Хуш исле чәчәккә ия
Французча исеме,

Бик төгәл дөрескә килә –
Исеменә – җисеме.

Гел шулай, ул палатага
Килеп керә елмаеп,
Мондый уңган табибәләр –
Мактауга һәрчак лаек.

Уңышлар сезгә, Резедә,
Тормышта-эшегездә,
Сезгә гел бәхет китерсен –
Бар белгән кешегез дә!

## ТАБИБ-ТАБИБӘЛӘРГӘ

Җитте гыйнвар аеның да
Инде соңгы атнасы,
Хастаханәдә терелеп –
Калды өйгә кайтасы.

Бу клиник хастаханә
Республикага карый,
Анда алган саулык һәм көч
Бар кешегә дә ярый.

Нык белә эшен табиблар
Сөйкемле табибәләр,
Зур уңышлар булмас иде –
Тырышмасалар әгәр.

Хастаханә җитәкчесе –
Ул Рөстәм Фаяз улы,
Аны ныгыту, үстерү –
Бу аның тоткан юлы.

Бар катта да һәр палата
Чистара-җиһазлана,
Авыруны терелтергә –

Мөмкинлекләрне таба.

Урынбасарлары уңган
Йөгерәләр-чабалар,
Тырышып, бар авырлыктан –
Чыгу юлын табалар.

Авыруларның теләге:
Бик рәхмәтлебез сезгә,
Кешеләргә саулык биреп –
Яшегез җитсен йөзгә!

## ҖӘЕЛЕР

Күңелдә уйный, тибрәнә
Чәчәк ата киләчәк,
Изгелек кенә кылганны –
Намуслылар беләчәк.

Син дә ач чиста битләрен
Шул гомернең китабын,
Бар яхшылык искә төшәр –
Хәтерләрсең син барын.

Күңелкәйләрең дә шулай
Ачылыр һәм яктырыр,
Бар изгелек һәм яхшылык –
Кояштай балкып торыр!

Изгелек һәм яхшылыклар
Тишелерләр, үсәрләр;
Аларның нык тамырлары –
Җәелерләр, күчәрләр.
Бар да искә төшәрләр!

## ӨЕЛЕП ТОРЫР

Табигать – бик сәер
Кисәк ул үзгәрә;
Я тына, я шаулый –
Карамый сүзгә дә.

Кешегә тик аны
Кирәк бик аңларга,
Иң якын кешеңдәй –
Яратып, саннарга.

Иртәнге чык юа
Аның да битләрен,
Актарма, пычратма –
Нык сакла читләрен.

Кадерләп сакласаң
Ул матур – шат булыр,
Өстәлләр нигъмәттән –
Өелеп гел торыр.

## РӘШИТ

Рәшит кода, бүген бәйрәм
Сиңа тулды илле биш,
Якын итеп, тәбрикләргә –
Килде туган һәм дус – иш.

Исемең дә гарәпчәдән
Баручы туры юлдан,
Икенче варианты бар –
Ул кыю, зирәк, уңган.

Бар авырлык калсын артта
Мәшәкатьтән юабыз,
Бары саулык, бәхет теләп –
Ике бишле куябыз!

## ӘЙ ЮЛЛАР, ЮЛЛАР

Әй юллар, юллар
Кая чабасыз,
Барып җиткәч тә –
Тагы ташлама.

Уйлап карасаң
Һәр юл башы да,
Ныклы адымнан –
Шулай башлана.

Әй юллар, юллар
Сез гел чабасыз,
Барып җитәсез –
Сез бик өлгерме?

Барган урында
Бәхет көтәме,
Әллә әйтмәслек –
Бу бик зур серме?

Әй юллар, юллар
Чыгарма читкә,
Кайчан булса да
Авыр атлавы.

Киң юлларыңнан
Җибәрмә бер дә,
Дошманнар каршы –
Килсә дә безгә!

## МАТУР КАРАШ

Елмаеп син уянасың
Җылы карашны тоеп,
Дөнья матур, күңелләр киң –
Куйгандай, барысын коеп.

Әй елмаю, елмаю
Җилкендерә-үстерә,
Тырышып, матур эшләргә –
Безгә һәрчак көч бирә.

Якты елмаю астында
Җылы кояш нурлары,
Шул нурлар кебек тарала –
Халкымның моң-җырлары.

Һәр елмаюның үз сере
Кайчак кинәт кабына,
Матур караш, нурлы йөзләр –
Насыйп булсын барсына!

## ҮЗЕҢ БЕЛ!

Менә шулай – еллар үтә
Менә шулай яшьлек югала,
Язгы кичләр, язгы хисләр –
Әкрен генә шулай юл ала.

Бел син, бел син – үзең бел
Яшьлекне югалту – бик җиңел,
Бел син, бел син – үзең бел
Әлегә – соң түгел!

Һәр елның бар – үз ялкыны
Якын килеп, ялгыш пешмә;
Йөрәк җылысын суытмый –
Каударланмый, шулай эшлә!

Бар эшемне – барлыйм кабат
Хезмәтеңне сөй син, ярат;
Намус белән башкарылса –
Киләчәккә бирер канат.

## РУЗАЛИЯ

Рузалия – латинча һәм
Яхудча көчкә ия,
Аның мәгънәсе дә шулай –
Иркә кыз гөлгә тия.

Тәрбиядә якыннарың
Әтиең һәм әниең дә,
Алар сезнең игътибарга –
Лаеклы бит хәзер көн дә.

Сездән алган ихтирамны
Алар зурлар һәм үстерер,
Бар кешегә сезне мактап –
Матур мисаллар китерер.

Үзегезнең балалар да
Үзегез күк булыр үрнәк,
Оныкларыгыз да уйнар –
Әттә, әннә – диеп, гөрләп.

Гаиләгез, эшләрегез
Гел китерсен зур куаныч,
Ирешкән бар уңышлар да
Тормышта булсын юаныч!

## РУШАНИЯ

Рушания – исемегез
Фарсыча нур иясе,
Нур сибүче, яктыртучы
Кирәкми һич тиясе.

Шуңа да син башкарган эш
Чиста, нурлы һәм якты,
Олы сыйныфлар бинасы –
Ниһаять сине тапты

Сиңа телибез гомернең
Тынычлыгын озынын,
Гел бәхет, шатлык бирсеннәр –
Малаең белән кызың!

Алдагы тормышта да гел
Авырмыйча эшләгез,
Гомер буе яхшылыктан –
Кешелектән төшмәгез!

## ФӘРИДӘ ИСЕМЕ

Фәридә ул – бик тиңдәшсез
Бердәнберне аңлата,
Гарәпчәдән кергән исем –
Шуңа матур таң ата.

Икенче бер атамасы
Ул – бриллиант, энҗе дә,
Ышанмасаң барып кара
Син үзеңне көзгегә!

Барысы да туры килә
Үзегез дә беләсез,
Кешеләргә яхшылык кылып
Яшәүне өстен күрәсез!

Авыр чакта төзәсез.

## МӨНИРӘ

Мөнирә – матур исем ул
Гарәпчә – яктыртучы,
Якты йөзле һәм бик нурлы
Кешегә – аң тукучы.

Син башкарган барлык эшләр
Чиста, нурлы һәм якты;
Шуңа да, хөкүмәт йорты –
Сине үзенә тартты.

Сиңа телибез тормышта
Төнлә дә гел айларын;
Гел бәхет, шатлык бирсеннәр –
Айдарың, малайларың!

Тормышта гел бәхет белән
Авырмыйча яшәгез,
Озын гомер, саулык теләп –
Мөнирә! – дип дәшәбез...

## НӘСИХА ЗӘКӘРИЕВНА

Гарәпчәдән исемегез
Изгелеккә бәйләүче,
Матур киңәш, теләк белән
Яхшылыкка өндәүче.

Әтиегезнең исеме –
Алланы хәтерләүче,
Борынгы яһүд – гарәпчә
Изгелек хәзерләүче.

Исемнәрегез бик уңган
Ходай кушкан сакларга,
Авырганга саулык биреп –
Ышанычлы атларга.

## ЛӘЙСӘН

Ләйсән – матур, күркәм исем
Гарәпчәсе – юмартлык,
Шифалы яңгыр буларак
Бирегез җиргә шатлык.

Сирия календарында
Буласыз апрель ае,
Сезне күреп сөйләшкәндә
Җиткән күк язның мае.

Кәрим кызы булуыгыз
Гарәпчә ул – намуслы,
Хөрмәтле, асыл зат булу –
Монысы бик тә отышлы.

Без телибез сезгә бәхет
Бишенче палатадан,
Үзебез дә шат булырбыз
Терелеп өйгә кайтудан.

## НАДЕЖДА

Надежда – ул зур ышаныч
Була авырлык – сирәк,
Сезнең кебек табибәләр
Кешеләргә бик кирәк.

Кулларыгыз да саваплы
Бик нурлы йөзләрегез,
Авыруларны терелтә –
Елмайган күзләрегез.

Йөзләрегез, күзләрегез
Гел елмаеп торсыннар,
Авыруларны терелтү
Планнарын корсыннар.

## ИЛСӨЯР

Илсөяр – ул күркәм исем
Үз илен яратучы,
Кешеләргә шатлык биреп
Борчуны таратучы.

Иптәшегез дә пар килгән
Барасыз туры юлдан,
Ходай саулык, бәхет биреп
Эшегез булыр уңган.

Тормышта булган борчулар
Ул узар, бетәр, китәр;
Парлашып һәм саулык белән
Яшәрлек көннәр җитәр.